1926–1991 ЕЛЛАРДА АЗАТ ХАТЫН

2019 МАЙ № 5

СӨЕМБИКӘ

ISSN 0869-1398



ЯБЫГАБЫЗ
максат – бер, юллар – төрле

НӘФЕС
хатын-кыз нигә нәфеслерәк


МИН МӘХӘББӘТТӘН ТУГАНМЫН
әти яратуы – башка

Альбина НАСЫЙРОВА:
ҺӘР БАЛА ЯРАТУГА КОЕНЫП ҮССЕН!

Минем өчен син һаман да – 17 дә!..

Минем өчен син һаман да – 17дә!..

Бу фотосурәтләр еракта калган кабатланмас мизгелләргә – Яшьлеккә алып китә...
...Шундый зур галәмдә меңнәр арасыннан бер-береңне эзләп табу – үзе үк могҗиза!
Аны күргәч кабынган хисләр – иң саф, иң ихлас, иң садә... Йөрәктәге сагышы да – якты, татлы, моңлы... Беренче очрашу... Аның кебек башка берәү дә юктыр! Дөнья – матур, яшәү шундый рәхәт! Очар өчен канатлар кирәкми дә!.. Ярату, йөрәккә генә сыялмыйча, җанда шигырь булып бөреләнә... Һәм мәңгегә Син – Шагыйрь, Ул Илһамчың булып кала...



Мөхәммәт МИРЗА

* * *

Кинәттән ачылган йолдыз
Йөрәгемә кадалса,
Очкан җанымны озатып
Җиде адым баралсам –
Кайтарырга Җанны тәнгә
Шунда куәт табармын,
Яшәр өчен Синең белән
Мин яңадан яралып...

Рәсемдә: шагыйрьнең хатыны Раушания ханым. 1970 нче еллар.

Сөй гомерне, сөй халыкны, сөй халыкның дөньясын!



© «Сөембикә» 2019

1926 елдан башлап «Азат хатын» исеме белән чыкты. 1991 елда «Сөембикә» итеп үзгәртелде. Хатын-кызларның бөтентатар айлык әдәби-нәфис журналы 1913–1918 елларда чыккан «Сөембикә» журналының дәвамчысы.

Ежемесячное литературно-художественное и культурно-просветительское электроннное периодическое издание на татарском, русском языках для женщин и семьи.

Территория распространения: Российская Федерация, зарубежные страны

Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендәге күзәтчелек буенча Федераль хезмәтендә (Роскомнадзор) 2015 елның 18 маенда «Сююмбике» дип теркәлгән. Теркәү таныклыгы Эл № ФС 77-61814

Язмалар авторның тулы адресы күрсәтелеп, паспорт мәгълүматлары, пенсия иминияте таныклыгы, ИНН таныклыгының ксерокс күчермәләре белән бергә җибәрелгәндә генә кабул ителә.

Кулъязмаларга бәя бирелми, алар кире кайтарылмый.

05’2019



Фото: Ксения Богданова

Баш мөхәррир вазыйфаларын вакытлыча башкаручы Л. Н. Маликова

Редколлегия:
Зилә Вәлиева, Нурия Вәлиева, Искәндәр Гыйләҗев, Нәбирә Гыйматдинова, Айрат Зарипов, Эльмира Зарипова, Кадрия Идрисова, Сәрия Сабурская, Нурия Һашимова, Гөлназ Шәйхи, Рафаэль Шәвәлиев, Равилә Шәйдуллина, Лотфулла Шәфигуллин.

Редакциянең гомуми телефоны 222-09-77

Җитәкче урынбасары 222-09-78
Рәмзия Кашапова
Баш мөхәррир урынбасары 222-09-78
Гөлнур Хәсәншина
Җаваплы сәркатип
Лариса Маликова
Әдәби мөхәррир
Эльмира Закирова
Сайт мөхәррирләре:
Сөмбел Гаффарова
Камилә Димөхәммәтова

Автор фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.

Реклама текстлары аны бирүчеләр җаваплылыгында.

Редакциянең язмача рөхсәтеннән башка материалларны «Сөембикә»дән күчереп басу тыела.

Тышлыкта:
Альбина Насыйрова
Фото: Анна Арахамия

Верстка:
Лариса Маликова

Бүлек мөхәррирләре:
Чулпан Галиәхмәтова
Лилия Гәрәева
Эльмира Закирова
Ландыш Әбүдәрова
Фотокорреспондент
Анна Арахамия
Корректор
Фирдәвес Исмәгыйлева
Гамәли хезмәткәрләр:
Нәфисә Әскәрова
Олег Сердюк

Формат: 225х290 мм
Күләме 64 бит

Басарга кул куелды: 24.04.2019 ел
Заказ О-1116
Тираж 5570

Учредитель: Акционерное общество «Татмедиа»



ТР «Татмедиа» Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр республика агентлыгы ярдәме белән чыгарыла.

Редакция адресы: 420066, Казан, Декабристлар урамы, 2 нче йорт.
www.syuyumbike.ru
E-mail: suumbike@tatmedia.com
ssuum@yandex.ru
тел./факс: (843) 222-09-77

Язылу индексы:
П2204 (ПАП рәсми каталогы буенча)
73002 («Роспечать» каталогы буенча)

Банк реквизитлары:
Филиал АО «ТАТМЕДИА»
«Редакция журнала «Сююмбикэ»
Расч/счет 40702810600020010309
кор/сч 30101810000000000805
в ПАО «АК БАРС» БАНК г. Казань
ИНН 1655144950
БИК 049205805
КПП 165802002




ПАШУНИН
Николай
Петрович
БЕССМ



http://president.tatarstan.ru

9 МАЙ — БӨЕК ҖИҢҮ КӨНЕ

Резеда ВӘЛИЕВА

Җиңү килгән көн

Идел-ярга ярсып-ярсып
Чал дулкыннар каккан чакта,
Ерак-ерак юллар гизеп,
Кошлар илгә кайткан чакта,
Куе кара болытларны
Ярсу җилләр таратканда,
Төн карасын ярып җирдә
Якты-аяз таң аткандай
Килде ул көн, балкып килде,
Кояш көлде, дөнья көлде.
Шаян җилләр, ашыга-ашыга,
Тупылларга чуклар элде.

Яшь бөреләр, бәбкәләрдәй,
Талпынышып куандылар.
Умырзая чәчәкләре
Елмаешып уяндылар.

Җырчы кошлар матур сайрап
Шатлык хәбәр итте җиргә:
Ул көн меңнәр зарыгып көткән
Бөек Җиңү килде илгә...

Безнең тышлыкта



Улым Аяз гел әйтә: «Минем әни шундый бәхетле, ул Бала-Ситины ярата», – ди. Алар сизә: уңышлы һәм бәхетле әнине яннарында күрү баланы да бәхетле итә.

14

«Уйларымны космоска юллыйм!»
Эльмира Закирова

Заман һәм без

6 Замана шаукымы: ябыгу хакы күпме тора?
Чулпан Галиәхмәтова

№112 10
Гөлнур Сафиуллина



18 «Мин үзем бренд»
Хәмдүнә Тимергалиеваның тормыш кагыйдәләре
Ландыш Әбүдәрова әзерләде



22

Хәерле эш
Лилия Гәрәева


Татар дөньясы



«Без гадәти түгелләр...» 28
Чулпан Галиәхмәтова

32 Сагына сине Үрәзмәт...
Эльмира Закирова

Мәдәни тормыш



36 Үксү
Гүзәл Әдһәм

Яшәеш

Феялар җирдә яши 42
Лилия Гәрәева



46 «Мин мәхәббәттән туганмын...»
Гөлнур Сафиуллина

Хатын-кыз галәме

58 Ландшафт дизайны



60 Үзбәк самсасы

ЗАМАНА ШАУКЫМЫ: ЯБЫГУ ХАКЫ КҮПМЕ ТОРА?

Кояш матур итеп карый башлауга ешрак елмаябыз, сипкелләребез дә, ябыгырга диган теләк тә уяна. Кыш буе җыелган май катламыннан бер дә җәфаланмыйча, тиз арада гына котыласы килә. Социаль челтәрләрдә хатын-кызлар өчен могҗизага тиң «ашыгыч ярдәм»нәр бик күп. Ябыктыру клиникалары, төрледән-төрле диеталар, тиз арада сылу гәүдәле итә торган сихри коктейльләр, порошоклар… Акчаң гына җитсен. Хәер, ике дә уйламый кредит рәсмиләштерергә мөмкин дип, үзләре үк хәлгә кереп тора бит әле. Ә иң мөһиме – ябыгасың да, башка беркайчан да тазармыйсың, дип вәгъдә итәләр. Йә, кем кызыкмас?! Бармак та селкетмичә нәфис гәүдәле бул әле син!



Чулпан ГАЛИӘХМӘТОВА



Зифа гәүдәң өчен акчаңмы, җаныңмы?

Нәфис гәүдәле булу теләге ни генә эшләтми хатын-кызны. Баллы, майлы, камыр ризыклары ашамаумы, кичке алтыдан соң өстәл янына якын килмәскә тырышумы (ә нәкъ шушы вакытта никтер һаман капкалап торасы килә), фитнес залларга йөрүме… Тиз арада ябыгырга кирәк була калса, бөтенләй баш бәласенә әйләнә. Социаль челтәрләрдә «ярдәм итәргә теләүчеләр» сектасына Гөлназ әнә шулай килеп каба. Ябыктыра торган коктейльләр сату белән шөгыльләнүче, хәзерге вакытта бик популяр булган челтәрле маркетингны ул шулай атый.

Кайгыртучан менеджерлар Гөлназны тиз генә үз төркемнәренә ала. Бер ябыгасың да, бу проблемадан бөтенләй котыласың, дип вәгъдә бирәләр. Тиз арада башта организмны чистарту, аннан ябыктыру өчен махсус препаратларга «утырталар». Диета түгел бу, һәр теләгән әйберне ашап була, безнең коктейльләр сезнең майлы котлетларыгызны да, өреле шулпаларыгызны да алыштыра, диләр. Хәтта конфеттан баш тарта алмаучыларга махсус мармеладлар тәкъдим итәләр. Бары тик компания продуктларын гына ашарга кирәк. Хәтта чәйне дә аларныкын гына эчәргә… Әнә шулай итеп бәйләп тә куялар. Сатып алучыларга мотивация ясау өчен кэшбеклар кайтару, лотереялар уйнату ише акцияләр уздыралар. Дөрес, Гөлназ ике айда артык авырлыгыннан котыла. Тик могҗизалы коктейльләрне эчүдән туктауга могҗизага да нокта куела… Артык килограммнары, ике тапкыр артып, кире кайта. Суга ташлаган 15–16 мең акчасы гына кире кайтмый.

– Кемнеңдер бакчасына таш атарга да, гаепләргә дә җыен-



мыйм, – ди Гөлназ. – Үземнең сансызлыгым, аңсызлыгым аркасында гына эләктем. Ә алар эшли белә. Һәм, әйтергә кирәк, нык эшлиләр: төрле очрашулар, семинарлар үткәрәләр, мотивацияләр... «Командага кушылсагыз, бизнеска кереп китеп, безнеке кебек кыйммәтле машиналарга да утыра аласыз», – диләр. Тәвәккәлли алмый торсаң, әрләп ташларга да күп сорамыйлар. Әрсезрәкләр каладыр ул челтәрле маркетингта. Мин киттем. Алдандыммы? Әйе. Миңа ябыгасың да башка тазармыйсың, диделәр. Шул сүзләр кешенең аңын томалыйдыр да инде. Үзең түгел, кесәң ябыга икән шул...

Тычканга – үлем, мәчегә – көлке, диләр. Тиз арада ябыгырга теләүчеләр хакында сөйләгәндә әлеге мәкаль искә төшә. Гөлназ акчасын гына югалта, ә менә ябыктыру клиникасына килгән 50 яшьлек Ирина Афонина гомере белән хушлаша. Казанда булган әлеге фаҗига бөтен илне шаулатты. Аңа да тиз арада артык килограммнардан коткарабыз дип вәгъдә итәләр. Гадәти маркетинг алым: бушка белгеч киңәше тәкъдим итеп яки махсус аппаратта түләүсез диагностика үтү мөмкинлеге белән җәлеп итеп, клиентларның «авыруларын табалар». Пациентларның кесәсендә акча булмау да киртә түгел мондый клиникаларга: кредит алып була бит! Ирина Афонина үлгән клиникада клиентны кыйммәтле процедуралар алырга ышандыра торган җентекле инструкция таба тикшерүчеләр.

Роспотребнадзор киңәш итә...

Татарстан буенча Роспотребнадзор идарәсенә ябыктыру клиникаларында сыйфатсыз ярдәм күрсәтелү хакында өч кулланучы мөрәҗәгать иткән (Росздравнадзорның Татарстан буенча идарәсенә дә бу уңайдан махсус сораулар җибәрелгән иде. Тик алар, идарә башлыгы ялда диган сылтау белән, җавапсыз калды). Ә ябыктыру чаралары буенча шикаятьләр килмәде, дип хәбәр итте безгә Роспотребнадзорның



Венера АВЕРКИЕВА,
Татарстан Сәламәтлек саклау министрлыгының штаттан тыш баш диетологы, югары категорияле табиб

«Бөтендөнья сәламәтлек саклау оешмасы мәгълүматларына караганда, кешенең сәламәт булуы 15 процент – генетикага, 15 процент – медицина хезмәтенең оештырылуына, ә 70 проценты яшәү рәвеше һәм ашауга бәйле. Ябыкмы, тазамы икәнеңне аңлау өчен, гәүдә массасы индексын ачыклау мөһим. Ә ул гади генә исәпләп чыгарыла:

ГМИ = авырлык (кг) : {буй (м)}^{2}

Индекс 18,5 – 24,9 аралыгында булса, нормаль авырлык;

5,9 – 29,9 – артык килограммнар барлыгын күрсәтә;

30 дан артса, тазару диган сүз;

Артык авырлыкны, гадәттә, косметологик дефект буларак кабул итәләр. Ә ул иң элек сәламәтлек өчен зыянлы. Тазаруның төп сәбәпләре: энергетик дисбаланс һәм гиподинамия (аз хәрәкәтләнү). Энергетик дисбаланс – энергияне алганга караганда азрак сарыф итү. Ә аның артык булуы май катламы җыелуга китерә. Кагыйдә буларак, кешеләргә 2000–2500 килокалорий җитә. Соңгы 70 елда без энергияне 1000 килокалорийга кимрәк сарыф итәбез. Сәбәбе: аз хәрәкәтләнү. Эштә утырып эшлибез, көнкүрештә алга киткән техникадан файдаланабыз.


Ябыгу әкрен темплар белән барырга тиеш. Бу – бер атна эчендә 0,5–1 килограмм ташлау диган сүз. Ябыгу ике этаптан тора: 3–6 ай буе авырлыкны киметү һәм 6–12 ай буе нәтиҗәне ныгыту. Әлбәттә, вакыт кирәк. Дөрес туклансаң, ябыгу берни тормый. Иң мөһиме: кабат тазарма!»

матбугат хезмәте. Бары тик дәгъвалар булганда гына алар тикшеренүләр үткәрә ала. Ведомство лабораториясендә ябыктыру препаратларының төрле сыйфатларын ачыклау шулай ук катлаулы. Чөнки күп очракта препаратларның җитештерүчесе, составы хакында мәгълүмат юк. Андый продукцияләр биологик актив кушылмалар рәвешендә дә, дару буларак та теркәлмәгән. Шуңа күрә маркировкада актив компонентлар язылса да, аларның оригинал булу-булмавын ачыклау өчен тикшеренүләр үткәрү мөмкин түгел. Роспотребнадзор артык авырлык проблемасын табиблар күзәтүе астында гына хәл итәргә, үзлектән дәваланмаска киңәш итә.

Диета – яшәү рәвеше?

Рекламаланган диетаны, ябыктыру порошок-таблеткаларын үз итүләренә гаҗәпләнәсе юк. Беренчедән, реклама (әле аны син яраткан шәхесләр рекламаласа, эффекты тагын да зуррак) дөнья белән идарә итә; икенчедән, тәкъдим иткән чаралар бик кыска вакытка исәпләнгән. Билгеле бер ризыкларны ашамау гына шарт. Ә ашаудан тыелсаң (бигрәк тә төнгә каршы), ябыктыру чараларыннан тыш та ябыгып була. Дөрес, аңа вакыт күп кирәк. Ә рекламаланган компанияләр тиз арада ябыктырырга вәгъдә итә.

– Тиз ябыгу зыянлы. Тагын шунысы бар: кыска вакытлы диеталар май катламын бетерә, әмма диета тотмый башлагач, ул элеккедән дә күбрәк җыелырга мөмкин, – ди диетолог Венера Аверкиева. – Сәбәп шунда: ашаудан тыелып торган вакытта организмда матдәләр алмашы 10–30 процентка әкренәя. Бу – калорийлар әкрен яна дигән сүз. Диета бетүгә, ябыктык дип шатланып, элеккечә ашый башлыйбыз, ә организм әкрен эшләвен дәвам итә. Ашаганның артыгы, билгеле, май катламына китә. Менә шушындый диеталарны әледән-әле тоткан саен, ябыгу авырлаша бара. Медицина тикшеренүләренә караганда, ябыгучыларның 98 проценты кабат



Өлкән фитнес-тренер Әсхәт ШАМИОНОВ: *«Ябыктыра торган препаратлар, нигездә, ашыйсы килү теләген генә баса. Бу исә организм өчен бик зыянлы. Шуларны эчеп кенә артык авырлыктан котылырга теләүчеләр – үзләрен хөрмәт итмәгән ялкаулар ул!..»*

тазара. Шуны аңларга кирәк: диета кыска вакытка гына була алмый. Тотарга уйлыйсыз икән, ул гомер буена барырга тиеш. Ләкин ул инде диета түгел, яшәү рәвешен үзгәртү булачак. Ә тиз генә ябыктыра торган диеталар авыруга әйләнергә сәбәпче дә була ала.

Интернеттагы диеталар, ябыктыру чаралары бөтен кешегә туры килә дигән сүз түгел. Даруханәдән дару алганда да иң элек табибта тикшеренәбез, ул дарулар билгеле. Диета да – дәвалану курсы.

– Ябыктыра торган БАДлар төп дәвалануга өстәмә генә. Һәм аларны табиб кына билгеләргә тиеш. Гомумән, ябыктыру өчен беренче могҗизага тиң чаралар булышмый! Алар дөньяда юк. Бу – халыкны алдау. Кешеләр мәгълүматлы гына түгел. Интернетка язганнарга сукырларча ышанганчы, белгечкә бару күпкә дөрес адым булыр, – ди Венера Аверкиева.

Ябыгу плюс фитнес

Фитнес-тренер Әсхәт Шамионов бодибилдинг буенча ярышларга әзерләнгәндә үзе дә май «яндыра» торган төрле препаратлар кулланган. «Аларны эчеп кенә ябыгып булмый. Нәфесеңне тыя алмыйча ашасаң, ябыктыру препаратларын вагоны белән куллансаң да, авырлык югалта алмыйсың», – ди ул. Ел саен төрле исемнәр белән чыккан мондый препаратлар – бизнес, ә тәвәккәлләргә ялкаулар хисабыннан акча эшләргә менә дигән сәбәп. Тир түкмичә генә, төймәләр генә йотып, коктейльләр эчеп кенә зифа гәүдәле булырга теләүчеләр бик күп. Мәгълүматсыз кешеләрне кармакка эләктерү җиңел шул. Фитнес-тренер да, ябыктыру комплекслары аз калорияле, аз углеводлы диеталарга өстәмә генә була ала, дигән фикердә.

Ябыгу дигән медальнең икенче ягы да бар бит әле. Артык күп килограммнарын «яндыручылар» картаеп киткән кебек була. Тулышып торган бит алмалары суырыла, җыерчыклар барлыкка килә, тире салынып төшә. Мондый хәлгә калмас өчен мускулны тонуста тотарга кирәк. Дөрес, спортзаллардан чыкмыйча, фанатикларча тренажерларда шөгыльләнү дигән сүз түгел бу. Тренер фикеренчә, атнасына ике тапкыр фитнес белән шөгыльләнү дә җитә. Гомумән, ябыгырга теләүчеләр озакка сузылган диетаны физик күнегүләр белән ныгытып барырга тиеш. Тикмәгә генә, хәрәкәттә – бәрәкәт, димиләр.

Әйе, могҗизаларга ышанып яшибез. Ләкин, балалардан аермалы буларак, аны тудыру өчен бик күп эшләргә кирәклеген дә аңлыйбыз. Кырыкалдардар кесәсенә акча салу гына түгел бу, билгеле. Дөрес туклану, физик күнегүләр ясау өчен (ахыр чиктә бик күп җәяү йөрү өчен) һәр кешенең ихтыяр көче җитәрлек. Юк, дип әйтүчеләр гап-гади ялкаулар гына. Ә матурлык ялкауларны яратмый ул! Үз өстендә эшләгәннәр генә камилләшә.

ФОТОБӘЙГЕ: «ОБЪЕКТИВТА – ӘНИ»



Фото: Анна Арахамия. Казан.

«Объективта – әни» бәйгесе дәвам итә. Аның оештыручылары – «Сөембикә» журналы редакциясе һәм «Казан Кремле» музей-тыюлыгы. Фотосурәтләрегезне 31 октябрьгә кадәр җибәрә аласыз.
Исегезгә төшерәбез: иң уңышлы дип тапкан эшләр журнал битләрендә дөнья күрәчәк, ә көзгә – Әниләр көнендә – Казанда, «Манеж» күргәзмәләр залында алардан күргәзмә оештырылачак.
Җиңүчеләрне планшет, кесә телефоны кебек кыйммәтле бүләкләр көтә.
Конкурсның нигезләмәсе һәм шартлары белән сайтыбыздан таныша аласыз: www.syuyumbike.ru.




Фото: Анна Арахамия



Гөлнур САФИУЛЛИНА

№112

Ул тынып калып, күңеленнән хатирәләрен барлый торган арада, аның шул чагын күз алдына китерергә тырышып карыйм. 1943 ел. Германия. Виттенберг шәһәре тирәсендәге концлагерьларның берсе. Аның өстендә үзе белән бергә күпне күргән иске гимнастеркасы, шинеле. (Туган авылына да ул шул киемнәреннән кайтып керәчәк. Тик әле үзе бу хакта белми, моңа инде өметләнми...) Аягында... И-и, безнең – сугышны китаптан укып, кинодан күреп кенә белгән буынның күзаллаулары чынбарлыктан шундый ерак бугай ул...

...Сугыш башланган көнне мизгелләренә кадәр хәтерли Мөхтәрәмә апа Хәертдинова. Алдагы көнне аларда – Азнакай районы Кәкре Елга авылында Сабантуй була. Икенче көнне яшьләр атларга төялеп, авыл урамын җырлап әйләнәләр дә, район Сабан туена чыгып китәләр. Кайбер егетләр өчен бу кузгалуның бөтенләйгә – мәңгелеккә икәнен ул иртәдә әле кем белсен?! Сәгать уннар тирәсендә багана башындагы тәлинкәле радиодан кинәт, йөрәкләргә шом салып, Левитан тавышы яңгырый: «Внимание! Говорит Москва! Передаём важное правительственное сообщение!

Граждане и гражданки Советского Союза, сегодня в четыре часа утра без всякого объявления войны германские вооружённые силы атаковали границы Советского Союза! Началась Великая Отечественная война...» Мәйдандагы бөтен халык багана тирәсенә җыела. Тын да алмый тыңлыйлар. Елаш, кычкырыш, тавыш башлана... Ул арада чабышка киткән атлар кайта... Тик аларда инде берәүнең дә гаме юк... Атлар инде бөтенләй башка дөньяга – сугышлы, хәсрәтле дөньяга кайтып керә...

Барысы да шундый тиз була – куркыныч төштәге кебек. Кемнәрнедер эзләп, инде мәйданга ук авыл советларыннан кешеләр килә башлый: «Сезне Хәрби комиссариатта көтәләр...»

– Сабантуйга өч кыз бергә барган идек. Мин, ахирәтем Оркыя... Без кечкенәдән аның белән бергә үстек, бик дус идек, авылда да безне «ахирәтләр» дип йөртteләр. Өченчебез – Сания... Яшь чак бит – егетләребез дә бар. Алар, өйгә дә кайтып тормыйча, өчесе дә Сабантуй мәйданыннан ук туры военкоматка китте. Без дә ул көнне военкомат янында кундык. Иртән аларны сугышка озаттык та, унбиш чакрым җәяүләп, урман аша авылга кайттык. Елый-елый...

Шәймулласының ул иртәдә җырлаган җыры да истә:

Исән-сау бул, туган авылым,
Кызыл ярларың белән.
Без кайтканда каршы алырсың
Сөйгән ярларым белән.

Шәймулла... Беренче һәм соңгы мәхәббәте... Укытучы егетне Башкортстаннан Кәкре Елгага юллама белән җибәрәләр. Иң беренче тапкыр күзләре очрашканда Мөхтәрәмә алтынчы сыйныфта гына укый торган була әле. Читләрдән мондый серне озак яшереп буламыни?! «Башлангычлар укытучысы сине ярата, күзләрен синнән алмый!» – дип, классташлар үрти башлый... Ә берничә көннән, 25 июньдә, Шәймулла Уфага диплом якларга китәргә тиеш була. Сабантуй мәйданы читендә егет кызга үзенең планнарын сөйли: «Диплом яклагач, Уфада эшкә урнашам. Аннан сине дә үземнең яныма алам. Башта пионервожатый булырсың. Читтән торып, Уфа педагогика институтына укырга керерсең. Бәлки минем кебек үк физика факультетын сайларсың...»

«Күзләрең сөрмәле, матур синең», – ди үзен елмаеп тыңлап торган Мөхтәрәмәгә карап, аннан икесе генә ишетелерлек итеп җыр суза:

Күзләреңне күзләремә
Күз дә салма, күзләмә.
Минем серле күзләремнән
Яшерен серләр эзләмә.

Шәймулладан нибары бер хат килә. «Ленинград ягына алып киттеләр. Көт, җиңеп кайтырбыз...»

– Фронтка барып та җитә алмаганнардыр. Эшелоннарын бомбага тотканнардыр. Аның артыннан ук бертуган абыемны алдылар, ул да шулай бетте...

Монысын 100 яшьлек Мөхтәрәмә әйтә. Күзләре яшьле килеш әйтә...

Илдә калганнарга да җиңел булмый. Кызны комсомол башлангыч оешмасының секретаре итеп куялар. Көндезләре эштә – МТСта уза, төннәрен кичке сменага ашлык суктырырга йөриләр. Боларына түзәргә була әле: иң авыры – агитатор булып халыкка заемга кул куйдырырга йөрү. Ит, сөт, йомырка җыю буенча авылга задание килә. Бер тиенсезгә эшләгән фронтовик хатыннарына шул йөкләмәне үтәргә кирәк. Өйләренә керәсең: сәкедә өч-дүрт бала ачлыктан шешенеп ята. Ә әниләре кулыңны ут кебек пешергән шул кәгазьгә кул куярга тиеш. Озакламый районнан вәкил килеп төшәсен, «Имзаң тора, риза булгансың, нигә хәзер түләмисең, димәк, җиңүне якынайтырга теләмисең?» – дип, җанны үрти-үрти җавап көтәсен белгән килеш... Авыз ачып сүз әйтергә юк – халык дошманына әйләнәсең. «Ул заем кәгазьләре өстенә күз яшьләрем шактый тамды», – ди Мөхтәрәмә апа.

Әнинең догалары саклап йөрткәндер: ут эченнән, меңәрләгән кеше ятып калган җирдән исән кайттым.

1943 елның 10 гыйнварында аларны районга – Хәрби комиссариатка чакыртып алалар һәм... «Иртәгә китәргә», – дип, повестка тоттырып җибәрәләр. Кәкре Елгадан сугышка моңарчы кызларның киткәне булмый әле. Алар – беренче.

– Әни мәрхүмә төне буе йокламыйча сохари киптерде. Эчендә нинди утлар янганын үзе генә белгәндер... Олы абыйның хәбәрсез югалганы турында хәбәр алган идек инде. Инде мин... Мин китүгә үк җизнинең «һәлак булды» дигән хәбәре килгән. Фронтка китүче ирләр кебек Оркыя ахирәтем белән без дә иртән атта урам әйләндек һәм Бөгелмәгә чыгып киттек. Аннан – Казанга... Эшне тапшырып торулар да булмады: бүлмә ачкычын әниләргә генә калдырдым да китеп бардым. МТС директоры: «Мөхтәрәмә – минем уң кулым, аның урынына ун кыз бирәм», – дип тә караган булган...

Казанда өч ай укыйлар. Инде фронтка китәр сәгать тә җитә... Тимер юл вокзалында ахирәте белән юллары аерыла: кызларны вагоннарга исемлек буенча утырталар. Оркыя Баһаветдинова исемлекнең башында, Мөхтәрәмә Хәертдинова исә – ахырында. Икесе дә аерылышуны авыр кичерә... Алгарак китеп булса да әйтим: Оркыя да туган авылына исән-сау әйләнеп кайта. Аңа сугышны күрергә дә туры килми: кызны запастагы офицерларга аш-су әзерләргә куялар. Ә Мөхтәрәмәнең – санинструктор кызның – урыны беренче көннән үк алгы сызыкта була.

– 4 нче Украина фронтының танкка каршы артиллерия полкына эләктем, 3 нче батарея. Андагы хәлләрне үзе күрмәгәннәр аңлый алмый... Һәр көнне күз алдында күпме кеше юк була – алар урынын яңа килгәннәр алыштыра. Һәм... барысы да яңадан кабатлана. Кайчак атналар буе ризык күрмисең: килеп җитмиләр, юлда бомбага эләгәләр...

«Мин һәрвакыт табын яныннан тамагым туймыйча кузгалдым – озак яшәвемнең сере шундадыр», – ди ул.



Әмма сынауларның иң авыры алда көткән икән.

Киевны дошманнардан азат иткәннән соң, аларның батареясы шәһәрдән ерак түгел Михайловка дигән авыл тирәсендә туктый. Окоп казып керергә генә өлгерәләр – һөҗүм башлана. Немец самолетлары санаулы минутлар эчендә Михайловканы җир белән тигезли. Алар окопларны пуля яңгырына коендырып узуга, тузан, төтен арасыннан танклар калка...

– Танклар безне боҗра кебек чорнап алды. Бервакыт бөтен дөнья тынды, атышлар туктады. Исән калган, аякта булганнарны окоплардан тартып чыгара башладылар. Бөтен батареяга җиде-сигез кеше җыелдык. Калганнар... Танклар алар өстеннән окопларны тигезләп узды... Тезеп куйдылар да, җәяү алып киттеләр. Караңгы төшкәч, бер сарайга яптылар. Атлар янына... Кем кайда урын тапты, шунда чүгәләде. Иртән тагын тезеп алып киттеләр. Берничә көн бардык шулай. Һәр тукталган җирдә безгә яңа кешеләр өстәлә торды – шактыйга күбәйдек. Ниһаять тимер юл станциясенә барып җиттек. Безне товар вагоннарына төяделәр. Тагын атлар янына! Дөресрәге, вагон киртә белән өчкә бүленгән иде: бер киртә артында – атлар, икенчесендә – без, өченчесендә – сакчылар. Ашарга бирү юк – сакчылар үзләренең калдыкларын гына аткалый. Кем көчлерәк – шул эләктерә. Әмма күршең кулына бер кабым ризык эләксә, ул аны синең белән бүлешмичә калмый иде. Бик хәлсезләндек... Үлүчеләр дә булды. Аларны вагоннан атып кына калдырдылар... Берәр атна барганнан соң, немец җиренә аяк бастык... Лагерьда инде күпмедер җиңелрәк иде. Беренчедән – ятып торырга урын бар, икенчедән – аз булса да ризык бирәләр. Ачка үлмәслек... Опилка кушылган ипи, кәбестә шулпасы, ул шулпада кайчак кабыклы бәрәңге дә булгалый...

Бертөсле соры көннәр башлана.

– Лагерьда кем беләндер дуслашып йөрдем дип әйтә алмыйм. Сатлыкҗаннар бик куркыта... Беркемгә дә үзем хакында берни сөйләмәдем. Кайдан икәнемне дә белмәделәр...

Хатын-кызның урыны сугышта түгел инде анык. Төрле чагыбыз була бит... Урманда яфрак куллана идек инде, шулай чистарына идек. Лагерьда да рәхәтләнеп тотарлык су күрмәдек. Кеше саен көнгә нибары ярты литр су бирәләр. Әллә ул су белән юынырга, әллә эчәргә...

Немецлар артык җәберләде дип әйтә алмыйм. Бәрү-сугуны гына җәберләүгә санамадык... Исемебез «русиш швайн» иде. Ягъни рус дуңгызлары...

Концлагерь тимерчыбык белән икегә бүленгән: бер ягында – хатын-кызлар, икенчесендә – госпиталь. Мөхтәрәмәне һәм тагын ике кызны безнең яралы әсирләр яткан шул госпитальгә эшкә билгелиләр. Сакчылар аларны иртән кереп ала, кич белән кире озатып куя.

Беркөнне ниндидер йомыш белән госпиталь территориясенә чыккач, ашханә янындагы чүплектә казынучы бер ир-атка игътибар итә ул. Өстендә ертык шинель, билендә котелок, шуңа, чүптән аралап, кәбестә яфраклары, бәрәңге кабыклары сала... «МТСта бергә эшләгән Мәсәлимов абый лабаса бу! Кәтем авылыннан!» Кыз шатлыгыннан кычкырып җибәрә яза. Әмма таныш икәнеңне берәүгә дә белгертергә ярамый! Бер-берсенә ерактан карап бермәл басып торалар: икесенең дә күзендә яшь... Ашны ашханәдән чиләк белән алып кайтып авыруларга өләшергә туры килгән чакта, Мөхтәрәмә якташ абыйсына гел күбрәк өлеш чыгарырга тырыша. Үзенә дигән ипине дә аңа биргәли. Мәсәлимов абый туган якка кыздан иртәрәк кайта. Якыннарына: «Мөхтәрәмә аркасында гына исән калдым», – дип сөйли... Кайткач, ул озак яшәми, әмма ике авыл арасы өч кенә чакрым булса да, алар бер тапкыр да очрашмыйлар. Әлеге дә баягы – ярамый. Икесен дә көне-төне күзәтәләр: кем белән аралашалар, ни сөйлиләр...

1945 елның апреле. Лагерьдагы барлык хатын-кызларны яланга чыгарып тезәләр.

– Бөтенебез бик курыктык, атарга алып чыктылар дип уйладык... Каршыбызда сакчылар йөреп тора, хәрби киемнән булмаган кешеләр дә байтак. Алар да әрле-бирле йөри. Аннан кызларны берәм-берәм сайлап, рәт алдына чыгара башладылар. Миңа да чират җитте... Юан гына аксак бер немец хатыны килеп итәгемнән тартты. Үзләренә хуҗалыкта булышырга кеше алырга килүләре икән. Авылга кайтып төштек. Өйдә карт белән карчык бар. Алар көннәр буе баскычта, кәнәфидә утырып тора. Киленнәренең ике кечкенә баласы йөгереп йөри. Әтиләре фронтта. Сугышта әсир итеп алган

яшьләрне үзенең өенә хезмәтче итеп озаткан: поляклар да бар, белоруслар да. Мине кечкенә генә бүлмәгә украин кызы янына урнаштырдылар. Ике пар аяк киеме, капрон оек (анысын ничек кияргә икәнен белмәдем), өстемә хуҗа хатыннан калган йон кара күлмәк бирделәр. (Соңыннан сеңлем шундый ук тукыма алып, шундый ук фасонда ак якалы күлмәк тектерде – икәү пардан кичәләргә йөрдек.) Бер генә көн эшкә кырга чыктым да, кухняга ярдәмче итеп куйдылар. Кер юарга куштылар. Азрак тамак та туйды... Кырга барганда үзләре ясаган консерваны ипи өстенә ягып бирделәр.

Кояшлы матур бер көн иде. Кинәт авылга танклар килеп керде. Американлылар! Шулкадәр көтмәгәндә! Алдан бернинди тревога булмады... Бөтен тарафта бәхетле тавышлар, шатлык-сөенеч, котлаулар... Хуҗалыкларда эшләүче хезмәтчеләр авыл кибетен таларга кереште. Безне – хәрби әсирләрне җыеп алып, кабат лагерьга алып киттеләр. 9 майга кадәр шунда тордык. Аннан Виттенберг шәһәренә күчерделәр. Сорау алулар, тикшерүләр башланды... Һәрберебезне табиблар баштанаяк карады. Киемнәребезне кызу камерада тоттылар, үзебезне мунча керттеләр. Эльба елгасы аша чыгуыбыз истә. Күпер шартлатылган, аның урынына су өстендә тирбәлеп торган вакытлыча күпер төзегәннәр. Безне дүрт рәт итеп тезделәр. Кулга «на родину» дигән документ бирделәр... Чикне чыккач, Маруся исемле кыз белән икебезне Мәскәү янына – Калуга шәһәренә хәрби госпитальгә эшкә җибәрделәр. Чикне июнь аенда чыккан идек, сентябрьгә кадәр шунда эшләдем. Авылга егерме алтысы көнне кайтып төштем...

«Мөхтәрәмә Хәертдинова чолганышта калды», дигән хат укытучы булып эшләүче сеңлесе Әдибә кулына килеп эләгә. Ул аны әнисенә дә, туганнарына да күрсәтми. Беренчедән, Мөхтәрәмә, бәлки, әсирлектәдер дигән сүз чыкса, «хыянәтче туганы» дип аны шунда ук эштән чыгарачаклар; икенчедән, аның исәнлегенә өмет барыбер бар бит әле – нигә барысын да хәсрәткә салырга...

– Кайткач әни: «Әдибә эштән кайтышлый бакчага керә иде дә, сирень агачын кочаклап елый иде. Ә мин аннан яшеренеп өйдә елый идем», – дип сөйләде...

Иң авыры илгә кайткач башлана. Мөхтәрәмәне бер җиргә дә эшкә алмыйлар. Алсалар да, ике-өч көннән артык тотмыйлар – куып чыгаралар. «Яшисем килмәс чиккә җиттем...» Бу сүзләрне әйткәндә әле дә күзләренә яшь тула... Ялга кайткан бер укытучы кызга ияреп Урта Азиягә чыгып китә. Сәмәрканд өлкәсендә бер кышлакта балалар укыта. Ике елдан соң ялга кайткач, әнисе аны инде кире җибәрми. Шуннан соң калган бөтен гомерен ул элеваторда бухгалтер булып эшли. Лаеклы ялга чыкканчы. «Кадрлар бүлеге чакырса да, директор дәшсә дә, «куалардыр инде» дип уйладым. Белделәр, билгеле. Артымнан чыш-пыш күп булды, «немецлар кулына төшкән, алар яклы булган, аларда эшләгән» дип сөйләделәр, тик мин ишетмәмешкә салыштым...»

Тормышка ул бик соң – кырык дүрт яшендә генә чыга. Бәйрәкәдән Мәсгуть Газизовка димлиләр. Үзе кебек үк фронттан кайткан, хатыны белән алты ел элек аерылышкан. Теләмичә генә ризалаша: «Ялгызлыгым белән килешкән идем инде... Кайчан да булса кияүгә чыгармын дип уйламадым да...» 46 яшендә үле бала таба. Малай... Бу югалтуны бик авыр кичерә. 47 (!) яшендә кызын алып кайта. Гөлнарасын! Дөньядагы иң зур шатлыгын!

Ялгызлыгым диде дә... Шәймулласы гел янәшә, гел уйда була лабаса. «Кайтыр кебек иде... Көттем...» – ди.

Клубларда кызлар җырлый,
сандугачтай телләре.
Бөреләнде, чәчкә атмады
безнең яшьлек гөлләре.
Агымсуларда акмады,
ахак салдым, батмады,
Яшьлегемне сынап гөлләр сиптем –
ул да чәчәк атмады.

Әллә кайчандыр күңелгә сеңгән җыр сүзләре, әллә үзе язган шигырь юллары...

– Ирем белән торганда оныткан күк булган идем, аны озаткач, кабат күз алдыма килеп басты... Мәсгутьнең сеңелләре мине абыйларына димләргә килер алдыннан төш күрдем. Шәймулла тәрәзәмә капланган. Толып ябынган. «Берәүгә дә чыкма!» – ди... Торып утырдым да: «Монда андый кеше юк та бит әле», – дим. Нигә шулай әйткәндер, белмим... Ирем белән әйбәт яшәдек. Аз сүзле, әмма бик тырыш кеше иде ул. Совхозда куркынычсызлык кагыйдәләре буенча инспектор булып эшләде. Бу кадәр озак яшәрмен дип беркайчан хыялланмадым. Башта: «Кызым 7 нче сыйныфны бетергәнче генә торсам ярар иде, азрак үз-үзен йөртер иде ичмаса», – дип теләдем. Аннары: «10 нчы сыйныфны тәмамлаганын күрсәм ярар иде», – дидем. Мәктәп тәмамлаганын да, югары белем алганын да, кияүгә чыкканын да күрдем. Оныкларымны үстерештем! Алай гына да түгел, Регинаның кызы Раяналы да күрү насыйп булды миңа... Әтиләре үлгәч (без аның белән нәкъ 30 ел яшәдек), Гөлнаралар Чаллыдан минем янга – Ютазыга күчеп кайттылар. Кызым белән киявем мине сабый бала урынына тәрбиялиләр, рәхмәт...

Кая ул читләргә, Мөхтәрәмә апа хәтта иренә дә сугышта булганлыгы, әсирлек газаплары турында сөйләми. Ире исә, бу хакта белсә дә, сүз кузгатмый. Сугыш ветераннары файдаланган бернинди өстенлектән файдаланмый Мөхтәрәмә апа, ташламаларга өметләнми. Бары тик 1995 елны гына сеңлесе Хәрби комиссариаттан аның документларын эзләтеп ала. Шуннан соң ул да халык арасында «сугышта булган» исеме күтәрә башлый.

Мөхтәрәмә апага апрель башында 100 яшь тулды. Ютазының иң олы әбисе ул. Зиһененә шаккатырлык! Алай да, бер кызның исемен искә төшерә алмады. Сугышка киткәнче Казанда бергә укыган мишәр кызын. Икесе дә әсирлектән котылгач, чик буенда очрашалар. Кочаклашып елашалар, рәхәтләнеп татарча сөйләшәләр...

P. S. 112 – Мөхтәрәмә Хәертдинованың концлагерьда күкрәгенә тагылган номеры бу.

PRESSA

«УЙЛАРЫМНЫ КОСМОСКА ЮЛЛЫЙМ!»

Эльмира ЗАКИРОВА

Альбина бүген минем героем булачак. Әллә кайчаннан – мәктәп елларыннан ук таныш, күз алдыбызда үскән Альбина… Төрле чакларын күргәнем бар аның. Бәхете ташып торган көннәрен, шатлыктан очып китәрдәй булып йөргән вакытларын… Яшьтәшләре аны «Тамчы», соңрак «Мәдәният дөньясында» тапшырулары аша ярата. «Ялкын» журналы тышлыгыннан күреп таный. Ш. Мәрҗани исемендәге татар гимназиясе укучысы Альбина Мөхәммәтшинаны белмәү мөмкинме соң! Ул – «Татар кызы» конкурсы җиңүчесе, ул – «Сәләт»тә, «Сөембикә варислары»нда, «Алтын каләм»дә. Журналга әзерләгән язмалары гына да бит нинди! Әле Чулпан Хаматовадан, әле җырчы Алсудан интервью ала. Журнал юбилеен алып барыр өчен… соңгы көнне тектереп өлгерткән кызыл күлмәге дә күз алдында. (Хәзер дә кызыл күлмәкләр – гардеробы түрендә!) «Сөембикә» журналының туташларга тәгаенләнгән иң зур бүләге – Сөембикә ханбикә сурәте төшерелгән көмеш муенса да аңа тапшырыла. Мәктәп елларында күпләр аны йә журналист, йә актриса булып китәр дип фаразлый…

Кай арада үсеп җиткән дә, театр училищесында укыган, Казан университетында рус теле һәм әдәбияты белгечлеге алган! Күренекле ханымга әйләнгән – Альбина Насыйрова булган. Хәзер инде Альбина Мөнир кызы Татарстанда бердәнбер булган Кембридж халыкара мәктәбен һәм «Бала-Сити» полилингваль балалар бакчасы челтәрен оештыручы бизнес-леди, «Бала-Сити»ның генераль директоры. Мәктәп Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының инновацион мәйданчыгы булып тора. Казан федераль университеты, Пекин Халыкара мөнәсәбәтләр институты, Бостон мәгариф идарәсе белән хезмәттәшлектә ул. Әлеге укыту үзәген тәмамлаучыларга дөньяның теләсә кайсы университетына барып керә алырлык халыкара сертификат тапшырылачак. «Бала-Сити» бакчаларына 500 бала йөри. Мәктәптә 100 бала укый. «Бездә театр мәктәбе дә, телевидение проекты да эшләп килә. Боларны үз балачагымны искә төшереп кертеп җибәрдем, – дип елмая Альбина. – «Актерлык осталыгы» дәресләрен Миләүшә Шәйхетдинова алып бара. Ул матур сөйләргә, сәхнәдә үзеңне дөрес тотарга өйрәтә. Телевидение белән дә элемтәмне югалтасым килмәде. Балалар стендап нәрсә икәнен дә, кайсы кулга микрофон тотып интервью алырга кирәген дә белә», – ди ул балкып. Хыяллары турында да әйтми калмый. Әле күптән түгел Чулпан Хаматова кабат очрашканнар. Альбинаның да хәйриячелек белән шөгыльләнәсе, махсус проект ачып җибәрәсе килә. «Әйдәгез, әлеге проектка бергәләп тотыныйк» дип тәкъдим ясаган ул яраткан актрисасына. Тагын… Ул бик күп балалар бакчаларының тәҗрибәсен өйрәнгән. Австрия, Германия, Италия, Америка, Төркия, Сингапур… Иң яхшы үрнәкләрне җыеп, аларны Казанда булдырырга тырыша. Әңгәмәбез балаларга, укыту-тәрбия эшләренә барып тоташа. Шулар хакында сөйләшәбез. Һәм, әлбәттә, уңыш серләре, гаилә кыйммәтләре, хатын-кыз бәхете турында да…



Мине, булдырасың, дип үстерделәр!

Альбина, син чая, тәвәккәл, ут уйната торган позитив һәм креатив кеше. Каян килгән ул сыйфатлар сиңа, кемнән йоккан?

– Дәү әти дә, әти белән әни дә: «Син булдырасың!» – дип, гел кабатлап, үсендереп тордылар. Зур хыяллар, максатлар куярга кирәген дә әйттеләр. Мине дәү әти тәрбияләде. Әти белән әни гел эштә. Дәү әти заводта эшләп пенсиягә чыкты да, бөтен барлыгын миңа һәм энем Булатка багышлады. Кечкенәдән татарча сөйләшеп үстем. Татар гимназиясендә укыдым.

Мәктәп елларында тормышымны телевидение, театр, сәхнәдән башка күз алдына да китерә алмый идем. Болар мине күп нәрсәгә өйрәтте. Балаларны да шулай үстерергә кирәк: бернәрсәдән дә куркып тормасыннар! Кем беләндер сөйләшәсе килә икән, әйтик, Джулия Робертс белән – бүген ул мөмкин! Инстаграм аша табасың да язасың! Мин шундый-шундый кыз, сезгә әйтер сүзем бар дип... Теләсә кем белән аралашырга була шулай!

Хыялыңда ничек итеп күрәсең килә эшеңне?

– Ел саен Америкага барам. Анда кече яшьтән балага «Син булдырасың!» дигәнне сеңдерәләр! Һәм, беләсезме, нинди сорау бирәләр? «Син башкалардан кай ягың белән аерылып торасың? Дөньяны ничек яхшыга үзгәртә аласың?» диләр. Университетка керер өчен 100 баллың булса да, шул сорауны барыбер бирәчәкләр һәм сиңа үз фикереңне әйтергә кирәк булачак. Бала уйланырга тиеш... Мәктәптә дә балалар белән шушы хакта сөйләшергә тырышам. «Робототехника» фестивале уздыруыбыз – шуңа бер адым. Без аны «Роботосабантуй» дип атадык. Башлангыч сыйныф укучылары һәм бакча балалары өчен андый инженерлык проектлары юк. Балаларда креатив инженерлык фикерләвен үстерергә кирәк. Инструкция буенча эшләүчеләр күп, миллионнар! Ә нәрсәдер уйлап чыгарып, креатив фикер йөртүчеләр бик аз. Балаларны кечкенәдән шуңа өйрәтергә кирәк. Балалар бит алар шундый фантазерлар! Ниләр генә уйлап тапмыйлар! Шул сәләтне кечкенәдән үстерергә генә кирәк! Алар булдырачак!

Без җәйгә Америкагамы, Канадагамы, Финляндиягәме – кайсына булса да берсенә балаларны алып барып, «Бала-Сити» сменасы ачарга планлаштырабыз. Гаиләбез, дуслар белән башка илләргә ял итәргә барганда да шул билингваль бакча-мәктәпләр турында уйлап йөрим. «Безнең отельдән ерак түгел бер мәктәп күрдем. Әйдәгез, барып киләбез», – диюемне гадәти күренеш итеп кенә кабул итәләр һәм артымнан ияреләр.

Әни булгач, супер көч барлыкка килә!

«Бала-Сити» тормышыңда аерым урын алып тора...

– Мәктәпне ачканда аны гади мәктәп кенә итәсебез килмәде. Безнең буын балалар көндәшлеккә, дөнья күләмендә конкурентлыкка сәләтле булу өчен күп телләр белергә, креатив фикер йөртергә, максатлар куя белергә тиеш. 5 кенә елга түгел, 10-15, 20 елга исәпләнгән җаваплы проект бу. Әти-әниләр миңа балаларын 100 процент ышанып алып килә икән, минем яктан да баланың киләчәге өчен 100 процент җаваплылык дигән сүз ул. Моны бизнес дип тә әйтеп булмый. Бу – социаль проект. Ә ничек башланып китте дисәгез... Әни булгач, ниндидер супер көч барлыкка килә икән хатын-кызда! Минем дә фикерләрем, тормышка карашым үзгәрде. Илһамланып менә шушы проектка алындым. Бу проектым шулкадәр кирәкле, аның ахыргы нәтиҗәсен күреп, тоеп була! Мәгариф өлкәсенә кереп китүем әнидәндер. Генетика барыбер үзенекен итә. Ул гомер буе булачак укытучыларны әзерли, хәзер дә шул эшендә. Педагогика фәннәре докторы, КФУ профессоры. Бу эшемне башлап җибәргәндә шундук хуплап алды. «Әлбәттә, булдырасың! Әйдә, мин сиңа ярдәм итәм!» – диде. «Бала-Сити»да да һәрчак аның ярдәмен тоям.

Әни буларак, үземнең балам өчен нәрсә телим, нәрсә булдырасым килә, эшемне шулай оештырырга тырыштым. Бик күп галимнәрнең фикерләрен өйрәндем. Алар менә нәрсә ди: телләр өйрәнү өчен иң яхшы вакыт – 2 яшьтән 4 яшькә кадәр! Шушы яшьтә алар бөтенесен сеңдерә! «Абау, сез кытай телен сайладыгызмыни, бик авыр тел бит!» – ди кайчак өлкәннәр. Әлбәттә, өлкәннәр өчен авыр. Ләкин балалар өчен андый кыенлык юк. Теләсә нинди телне дә өйрәнә алалар.

Үзебездә татар телен өйрәнүне мәҗбүри итеп ясадык. Бала никадәр күбрәк телләр белсә, шулкадәр яхшырак, алар математик мәсьәләләрне дә тизрәк чишә, фикер йөртү сәләте дә көчлерәк. Татар телен укытырга университет тәмамлаган яшь, сәләтле, бик ачык, эмоциональ укытучыларны сайлап алам. Бездә шундый кагыйдә бар: инглиз теле укытучылары – бары инглизчә генә, татар теле укытучылары татарча гына сөйләшә! Хәтта әти-әниләр белән дә! Аңламыйлар икән, сорыйлар, тәрҗемәчене чакыралар. Ә балалар аңлый!

Кешеләр белән аралашырга яратам!

Кыен чакта кемнәргә таянасың?

– Кешеләр белән аралашырга гел ярата идем. Ә монда 200 проценттан да арта ул аралашулар! Кемнедер илһамландырырга, кемнедер тынычландырырга, кемгәдер җылы сүз әйтергә кирәк... Үзегез беләсез, хатын-кызлар коллективы бит.

Университетлар, укытучылар әзерләүче факультетлар белән эшлибез. Укытучыларны үзебез әзерлибез. 11 нче сыйныфка кадәр укытырга уйлыйбыз. Мәктәп өч ел элек ачылды. 6 нчы сыйныф укучыларын чыгарабыз киләсе елга. 2 яшьтән «Бала-Сити»га килгән балаларны бүген инде укучылар итеп күрү бик күңелле. Мин алар белән горурланам. Әти-әниләрнең күбесе белән дуслашып беттек. Кайбер әниләргә карыйсың да... Дүрт бала үстерәләр! Һәркайсының үзе эше, фирмасы, заводы, медицина үзәкләре челтәре... Шундый активлар, матурлар, янып торалар, булдыралар!.. Миңа ошый андый хатын-кызлар белән аралашу! Хәзер хатын-кызлар төрле регионнардан, шәһәрләрдән

Фото: Анна Арахамия





килә башлады. «Минем дә шундый бакча ачасым килә, ләкин куркам», «Ирем хупламый», «Кайдан башларга?», «Нишләп минем барып чыкмый?» – диләр. Хатын-кызларча аңлау, психологик ярдәм кирәк аларга. «Син булдырасың, әлбәттә, булдырасың!» – дип үсендереп тору кирәк. Миннән гел сорыйлар. «Уңышларыңның сере нәрсәдә?» – диләр. Бездә бик көчле команда: 120 кеше. Укытучылар, тәрбиячеләр мине аңлый, мин – аларны.

Ул Бостонда тәкъдим ясады!

Син карап торуга ук бәхетле хатын-кыз булып күренәсең. Динар белән ничек таныштыгыз?

– «Мәдәният дөньясы»нда эшләгәч, премьераларны карап бара идем. Ул көнне минем монтаж булырга тиеш иде, вакытын күчерделәр дә, Тинчурин театрына чаптым. «Мәхәббәт чишмәсе»н карарга. Гел билетсыз гына керәм бит инде «служебный ход»тан *(көлә)*. Динар басып тора. «Сәләт» аша бер-беребезне белә идек. Сәлам бирештек. «Кем белән килдең?» – ди. «Үзем генә», – дим. «Кайда утырасың?» – ди. «Кайда туры килсә шунда», – дим. «Әйдә, минем янга утыр», – дип чакырды. Спектакль мелодрама булып чыкты, елап беттем. «Син бик дулкынландың, әйдә, чәй эчеп тынычлан», – дип кафега дәште. Шуннан аралашып, сөйләшеп йөри башладык. Аннары ул Америкага Бостон шәһәренә ике елга магистратурага китте. Җәйгә, әйдә, кил, Американы күрерсең, дип чакырды. Һәм менә шунда, Бостонның иң биек бинасы Prudentialның иң соңгы катында романтик бер кичтә ул миңа тәкъдим ясады! Бу – 2008 елның җәе иде.

Насыйровларның яраткан киленедер син, әйеме?

– Динарның әти-әниләре бик яратып кабул итте мине. Әнисе белән берникадәр охшаш та без. Темпераментларыбыз да туры килә. «Бала-Сити»ны оештырып җибәргәндә бик булышты. Ул – бухгалтер-икътисадчы. Хәзер дә гел ярдәм итә. Рәхмәт аңа.

Үзебезнең балалар да «Бала-Сити»га йөри. Аязга – 9 яшь, Азимга – 4 яшь. Икесе дә өч телдә сөйләшә: татарча, русча, инглизчә. Испан телен өйрәнәләр. Биш яшь аерма булгач, кызыксынулары төрлечә. Берсенә – машиналар, икенчесенә геройлар турында укырга кирәк. Бездә бер кагыйдә бар: өйгә кайткач, телефоннарны читкә алып куябыз. «15 минут булса да, бернәрсә турында да уйламыйча, баланы гына тыңларга тырыш», – ди Динар. Дөрес әйтә: бала белән сөйләшергә, аны тыңларга кирәк!

Балаларны яратырга кирәк!

Хәзер бит шундый төшенчә бар: баланы яратып үстерергә кирәк, диләр.

– Баланы яратуның чиге юктыр аның. Әлбәттә, яратырга кирәк! Гел мактарга кирәк! Мин үзем шулай үстем. Ул мактаулар хәзерге замана балаларына аз әләгә, минемчә. Шуңа күрә бакча, мәктәпләрдә шәфкатьле, мәрхәмәтле кешеләр генә эшли ала... Безнең балалар икесе ике төрле. Азим бик актив, күп сөйли, тик тормый, җырлый, бии. Ә Аяз – тыныч. Робототехника белән мавыга, фантастик китаплар укый. Кем буласың дигән сорауга, бизнесмен буласым килә дип җавап бирә. Аналитик фикерле: әтисенә охшаган. Бизнес-планнар язып шаккататыра. «Миңа шуны-шуны эшләргә, шуны-шуны планлаштырырга кирәк», – ди. «Әни, балалар бакчасы өчен агачтан уенчыклар ясыйм. Ничә сумнан аласың?» – ди. Әтисе моны күреп, «Әйдәле, Яшел Үзән фанера фабрикасына барып килик», – диде. Анда калдык-постык такта кисәкләрен капчыклап бушлай биреп җибәрәләр икән. Шулардан кечкенә-кечкенә шакмаклар ясый миңа Аяз. Ә Азим бүген – космонавт, иртәгә – супер герой... Бик хыялый әле ул...





Фото: гаилә архивыннан

Арып кайтып, үзеңә дә ял ясарга, гаиләгә дә җылылыкны түкми-чәчми җиткерергә кирәк. Ничек тиз генә шул халәткә күчә аласың?

– Динар бик булыша. Бөтенесе үз җилкәмдә генә булса, авыр булыр иде, әлбәттә. 5 яшьтән соң малайлар күбрәк әтиләренә тартыла икән. Уртак темалары күбәя... Мин аларны ясмык ашы белән сыйлыйм. Төрекчә, лимоннар салып... Бик җиңел аны пешерүе. Камыр ашларын да яраталар. Бергәләп пешерәбез. Алар кухняда кайнашырга ярата. Пычак тотып кисәләр, турыйлар. Мин һич тә тыймыйм – безнең кухняда ирек.

Малайларны тәрбияләүнең дә үз сере бар икән...

– Малайларны хәзер... тәрбияләмиләр. Шундый тенденция. Бала инде мәктәптә укый, ә әни кеше һаман әле улының ботинка шнурын бәйли. Малай кеше бөтенесен үзе эшләргә өйрәнсен! Әнигә генә салынмасын, үзе хәл итсен, барьерларны үзе үтсен. Мөстәкыйльлеккә өйрәтергә кирәк. Иркәләнеп беткән малайлар беркемгә кирәк түгел. Кызларны иркәләргә ярыйдыр әле...

Әгәр депутат булсам...

Мин оптимист дияргә яратасың...

– (*Көлеп җибәрә*). Әйе, шулай! Кайсы сыйфатлар эшләргә ярдәм итә дисәләр, оптимизм, кешенең көчле ягын күрү дип санап китәм. Хатын-кыз интуициясе көчле миндә. Соңгы вакытта үз-үземә шакката башладым. «Их, менә миңа хәзер шундый кеше кирәк: музыканы да, инглиз телен дә белә торган!» – дим. Уйлап йөрим. Уйларымны космоска юллыйм. Һәм үзеннән-үзе юлыма килеп чыга шул мин эзләгән кеше.

Син «Бердәм Россия» партиясенең праймеризында катнашасың. Сайлау алды платформасында хатын-кызларга ирләр белән тигез социаль гарантияләр булдыру мәсьәләсе, Татарстанда полилингваль педагоглар әзерләү системасын тудыру зарурлыгы әйтелә. Хатын-кыз, әни, бизнес-леди буларак, хатын-кызларны яклап, зур эшләргә алынырга җыенасың...

– Тәрбиячеләрнең, укытучыларның имиджын күтәрү, эш хакларын арттыру хакында сүз әйтәсем килә. Гомумән, билингваль мәктәпләр, бакчалар өчен укытучыларны ничек табарга, аларны ничек әзерләргә – менә шул турыда әйтәчәкмен. Социаль эшмәкәрлеккә юл ачасым, хатын-кызларга мөмкин кадәр ярдәм итәсем килә: үзләрен табып, үз эшләрен булдырсыннар. Миңа калса, социаль эшмәкәрлек мәгариф өлкәсендә аеруча кирәкле юнәлеш! Бөтен дөнья буенча алып карагыз: шәхси белем бирү учреждениеләре ил үсешендә зур роль уйный. Шәхси университетлар, шәхси мәктәпләр һәм балалар бакчалары – барысы да социаль проектлар бит! Һәм алар дөньяны яхшы якка үзгәртә. Безнең республика ул яктан бик алга киткән. Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Миңнеханов «Бала-Сити»га килгәч бу хакта аермачык әйтте: «Шәхси балалар бакчасымы ул, муниципаль бакчамы – максатларыбыз бер үк: балаларга тәрбия бирү, конкурентлыкка сәләтле балалар үстерү», – диде. Әйе, хөкүмәтнекеләрнең дә, безнең дә максат уртак – балаларга яхшырак эшлисебез килә. Социаль эшмәкәрлек мәгариф өлкәсендә үсеш мәйданы булырга тиеш. Мәгариф министрлыгы булыша, дәүләт булыша. Субсидияләр бирәләр, биналар белән тәэмин итәләр, каршылыклар юк – эшлә генә! Президент булыша – һәртөрле проектларны хуплый. Безгә берләшеп эшләргә генә кирәк!



Тулысынча сайтыбызда: www.syuyumbike.ru

«МИН ҮЗЕМ БРЕНД»



Татарстанның халык артисты Хәмдүнә ТИМЕРГАЛИЕВАның тормыш кагыйдәләре

БЕЗНЕҢ НӘСЕЛДӘ БАРЫСЫ ДА ҖЫРЧЫ. Әнкәйнең Ленинград блокадасын үткән бертуган сеңлесе Мәрьям апаның татар халык җырларын җырлаганын тыңлаган кеше аны оныта алмый иде.

Мин – әткәйнең яраткан кызы. Биш кыз, бер малай идек без. Кулак балалары булып үстек. Зурәткәй староста булган, барлык мал-мөлкәтен Совет властена тапшырып, гаиләсен Себергә сөрүдән алып калган. Әмма **КУЛАК БАЛАСЫ ДИП, МИНЕ СӘХНӘГӘ МЕНГЕРМИЛӘР ИДЕ.**

«Кайда күрсәң, шунда калсын», – диләр иде. **БЕЗНЕҢ ӨЙДӘ ГАЙБӘТ СӨЙЛӘҮ ИҢ ТЫЕЛГАН ГАМӘЛ БУЛДЫ.** Бала-чага алдында сүз сөйләүнең ярамаган эш икәнен бик яхшы аңлаган әткәй белән әнкәй. Бала кешенең авызында сүз тормый бит аның.

СҮЗНЕ СӨЙЛӘГӘНЧЕ УЙЛАРГА ӨЙРӘНГӘНБЕЗ. Кулак баласының авызыннан чыккан сүз бит ул!

ТУРЫ СҮЗЛЕЛЕГЕМ – ӘНКӘЙДӘН. Әнкәй үзен-үзе якларга өйрәнгән хатын булган. Әткәйне сугышка хәтле дә, сугыштан соң да төрмәдә тилмертәләр. Икесендә дә нахакка. Сталин портретының күзен чокыды, дип әләкләләр. Беренчесендә әткәйне гаепләгән прокурорның үзенең кырын эшләре билгеле булып, котылып кала. Икенчесендә күрше Варҗитамак дигән авылда бер гаилә ачтан шешенеп үлгәндә, чәчүлек орлыктан өлеш чыгарган өчен кулга алалар. Әнә шундый шартларда әнкәй, әгәр аңа кагылсалар, икенче кагылмаслык итеп җавап бирә торган булган.

Ничә еллар эшләү дәверендә гел үземне якларга туры килде. **ҖЫРЛАУГА КАРАГАНДА, ЯКЛАР ӨЧЕН КҮБРӘК КӨЧ САРЫФ ИТТЕМ ХӘТТА.**

ҖЫРЛАНМАГАН ҖЫРЛАРЫМ КҮП. Ходай гомер бирсә, җырлармын әле!

«Җомга көе» – минем җыр ул. Минем әти Сәетгали җырлаган халык җыры. Мин аны эшкәртеп, сәхнәгә күтәрдем. Утыздан артык халык җыры гына чыгардым. Хәзер минем шул җырыма кызыккан җырчылар бар. Ул җырны алганчы, минем җанымны алсыннар! **МИН ҮЗЕМ БРЕНД!**

РЕПЕРТУАРНЫ ЭЗЛӘНЕП, ЭШЛӘП ТӨЗЕРГӘ, ИПИНЕ ТИР ТҮГЕП АШАРГА КИРӘК. Халык җыры дигән булып, тоталар да кеше репертуарыннан җыр алып җырлыйлар. Халык җырын да кемдер эзләп табып эшкәртеп чыгара. «Галигә барам әле» гади җыр иде ул мин эшкәрткәнче.

ҮЗЕМ ЭШКӘРТКӘН ХАЛЫК ҖЫРЛАРЫН ҮЗЕМ ҖЫРЛЫЙ АЛМЫЙЧА ИНТЕККӘН ЧАКЛАРЫМ КҮП БУЛДЫ. Гомерем буе кара шәл шикелле артымнан сөйрәлеп килде ул минем.

ГОМЕРЕМДӘ ДӘ ЧИЛЕ-ПЕШЛЕ ҖЫР ҖЫРЛАМАДЫМ. Һәрбер җырым мәгънәле минем, тормышчан. Һәрбер кешенең күңеленә ята торган сүзләр, көйләр. Шуңа халык күңеленә кергәнмендер дә инде.

ИСЕМЕМ ГЕЛ ҮЗЕМНӘН АЛДА ЙӨРДЕ. «Сәетгалинең Хәмдүнә исемле бик яхшы җырчы кызы бар икән» дигән сүз авылдан ук ияреп килде.

ТАБИГАТЬНЕ ЯРАТАМ. Урманнарга чыгып китсәм, кайталмыйча интегәм. Бәләкәйдән үк урман тирәсендә үскәч, шәһәр ыгы-зыгысы миңа ятрак. Шәһәр урамнарында ял итеп йөргән кешеләргә: «Болар нишләп йөри икән?» – дип шаккатып карап торам. Мин урманда шулай йөрим.

Безнең авыл кешеләре барысы да шулайдыр дип уйлыйм, чөнки безне урман яшәтте, урман ашатты. Гомумән, **БЕЗНЕҢ ХАЛЫК УРМАН БЕЛӘН ЯШИ.** «Карурман» бер дә юктан гына халык күңелендә үз урынын алмагандыр.

Мин гомер буе Казанда яшим булып саналдым. Ләкин **МИН ИЛДӘ ЯШӘДЕМ – ГАСТРОЛЬЛӘРДӘ**.

Ни өчен Казанмы? Өйдә Тукай китабы, әти алып кайткан 78 «оборотлы» патефонда Гөлсем Сөләйманова, Зифа Басыйрова, Әлфия Афзалова, Илһам Шакиров булганга. **АБЫЙ** Кукмараның урман хуҗалыгы техникумыннан **ҖИБӘРГӘН ОТКРЫТКАДА СӨЕМБИКӘ МАНАРАСЫ СУРӘТЕ БУЛГАНГА**.

Һай, ул патефон! Без бит үзебез дә белмичә **БАХНЫҢ «ТОККАТА И ФУГА РЕ МИНОР»ЫН, ШТРАУСНЫҢ «ВЕНСКИЙ ВАЛЬС»ЛАРЫН ТЫҢЛАП ҮСКӘНБЕЗ!**

Миңа охшарга тырышучылар бар. **МИНЕ КАБАТЛАУ ӨЧЕН ЯҢАДАН ТУАРГА КИРӘК ШУЛ.** Кеше тормышта ничек, сәхнәдә дә шулай булырга тиеш. Мин беркайчан да кыланмадым.

Артист турында гайбәтне халык чыгармый. **ҖЫРЧЫ ТУРЫНДА НАЧАР ХӘБӘРНЕ АРТИСТЛАР ТАРАТА.** Халык арасында гайбәт шулай тарала. Мин әнкәй кебек: үзем турында теләсә нәрсә сөйләргә урын калдырмыйм.

Минем турында да шулай сүз таратып караганнар иде. Бер-ике артистны стенага терәп «тешләргә» туры килде. Нечкә урыннарыннан тешләдем: **ҺӘРКЕМНЕҢ КЕШЕГӘ БЕЛГЕРТМИ ТОРГАН СЕРЕ БУЛА.**

КАРТЛЫКТАН КУРЫКМЫЙМ. Җиңел-җилпе уйлаган кеше өчен картлык куркыныч нәрсәдер ул. Бу бит табигать законы: әле берәүнең дә җир йөзендә калганы юк. Шуңа да күңелең белән, җаның белән үлемгә әзер булырга кирәк.

Теге дөньяда оҗмах та бар, диләр бит әле. Мин аңа да ышанам. Һәрхәлдә, ниндидер көч безнең белән идарә итә. Мин иртә белән кояшка карап теләкләр телим. **ИХЛАС СОРАГАЧ, ТЕЛӘКЛӘР КАБУЛ БУЛА.**

Фото: Анна Арахамия

PRESSA

Казанда яшәсәм дә, мин барыбер авыл кешесе булып калдым. Шуңа бакча алдым бит инде. Ләкин читкә китсәм, Казанны сагынып кайтам. Авылны искә төшкәндә сагынам. **КАЗАНДА МИН ҮЗЕМНЕ ҮЗЕБЕЗНЕҢ АВЫЛДАГЫ КЕБЕК ХИС ИТӘМ.**

Мин бакчада ял итәм. Су буенда кызынып ятуны ялга санамыйм. Бакчада киенеп-ясанып йөрисе юк. Иң яратмаганым – бизәнү, киенү. Ләкин сәхнәгә бизәнмичә-ясанмыйча чыгарга ярамый. **МАТУР КИЕНЕП ЧЫГУ – ТАМАШАЧЫҢА ИХТИРАМ БИЛГЕСЕ УЛ.**

ЭШСЕЗ ТОРА АЛМЫЙМ. Минем кебек кешене эштән аерсаң, көне-сәгате белән үләчәк.

МАТУРЛЫКНЫ ЯРАТАМ. Матур кешеләр, матур әйберләр яратам. Матур хатын-кызларга сокланып карыйм, чөнки мин артистлар арасында чибәрләрдән саналмадым. Матур күлмәк кияргә яратам.

ФИГУРАЛЫ ШУУ БЕЛӘН КЫЗЫКСЫНАМ. Аңа хәтле хоккейны яратып карый идем. Берара мотоцикл ярышлары белән кызыксындым. Дустым Нәзифә Кадыйрованың ире Габдрахман Кадыйров 6 тапкыр – дөнья, 12 тапкыр Европа чемпионы булган чаклар иде.

Яшь чагында очучы булам дип хыялландым. Балериналарны күргәч, балерина буласым килде. Авылда үскән кешегә нинди балет та, нинди тимераяк инде? Әнә, бакчада чүп утау буенча спорт мастеры без! Печән чабу, утын әзерләү. Күрше авылга йөреп укыйбыз: көн саен алты чакрым теге якка кросс бирәбез, алты чакрым – бу якка. Авылдан чыккан җырчыларның сулышлары шуңа киң ул, беләсегез килсә! **ЧЫН ҖЫРЧЫНЫ АВЫЛ ҮСТЕРӘ.**

Мәхәббәт турында сөйләшергә бик яратмыйм. Үземнең мәхәббәтне бәхетсез дип әйтә алмыйм, чөнки гомерем буена бер генә кешене яратып яшәдем. Бөтен барлыгым белән гашыйк булып яраттым мин аны. Ул да яратты. **ГОМЕРЛЕК МӘХӘББӘТ БӘХЕТСЕЗ БУЛА АЛМЫЙ.** Ләкин без бергә була алмадык. Хәзер инде ул гүр иясе.

Бергә булыр өчен миңа җырны ташларга кирәк булачак иде. Дөресрәге, гастрольләргә йөрүемне. Гастрольләргә йөрмәгән җырчы җырчымыни инде ул? Шул вакытта мин җырны сайладым, чөнки **ҖЫР – УЛ МИНЕМ КҮҢЕЛ ХАЛӘТЕ**. Җырны ташлап бәхетсез булмадым. Шул ук вакытта аны ягатуым белән бәхетле дә булып яшәдем.

Безнең халыкның гадәтенә сеңгән: хатын-кыз ничек булса да ирле булып яшәргә тиеш, диләр. Кагылса да, сугылса да, түзә. Ләкин бит **ИР ЯГЫННАН ДА, ХАТЫН ЯГЫННАН ДА ИХТИРАМ БУЛЫРГА ТИЕШ**.

ХАТЫН-КЫЗНЫ МАЛ УРЫНЫНА ТОТКАН ИРЛӘР БАР. АНДЫЙЛАРДАН КАЧАРГА КИРӘК. Бигрәк тә җенси яктан йомшак яки ориентацияләре дөрес булмаган ирләр хатыннарын газап чиктереп яшәүчән була. Хатыны үзенә караганда «грамотныйрак», рухи яктан югарырак икән, ире аны җәберләп яши.

ЧЫН ИР КЕШЕ БЕРКАЙЧАН ДА ХАТЫНЫН КИМСЕТМИ, УЛ ХАТЫНЫН СӨЕП ЯШИ. Баламның анасы бит дип яши. Чын ир кеше ничек итсә итә, ул тормышның авыр башыннан күтәреп бара.

ХАТЫН-КЫЗНЫҢ ДА ТӨРЛЕСЕ БАР. Азрак яхшы тормыш күрсә, аза башлый ул. Каян чыкканын оныта.

Мин ялгызмын. **ЯЛГЫЗЛЫГЫМ БЕЛӘН БӘХЕТЛЕМЕН ДӘ**. Минем кебекләр дә бар, алар да бәхетле була ала.

Кайвакыт мин дә баласыз калдым дип уфтанам. Кайвакыт ярый әле балам булмаган, дим. Бер бөртек бала үстереп, аның йә бандит, йә наркоман, йә кеше үтерүче булып китүен күргән ата-аналар да бар. Мин бит артист кеше, һәрвакыт юлда. Шуңа да **МИНЕМ БАЛАМ ҮЗЕМНӘН ЧИТТӘ ҮСЕП, КЕМ БУЛЫР ИДЕ БИТ?**

АНЫҢ КАРАВЫ, ГАСТРОЛЬЛӘРГӘ ЧЫККАЧ, БӨТЕН КЕШЕ БЕЛӘН ТУГАНЛАШЫП ЙӨРЕП КАЙТАМ МИН.

Иң начар гадәтем: **АЧУНЫ ОЗАК САКЛЫЙ АЛМЫЙМ.** Шуннан файдаланалар. Юләр дип тә уйлыйлардыр инде.

Акча надан, саран кешеләрне боза. Наданнарны акчага сатып алып була. Ә чын кешеләр ул кәгазьгә генә сатылмый. **МИНЕ БЕРНИНДИ АКЧАГА ДА САТЫП АЛЫП БУЛМЫЙ.** Мин гөнаһтан куркам.

ГОМЕР-ГОМЕРГӘ ИР КЕШЕЛӘР БЕЛӘН ДУС БУЛЫП ЯШӘДЕМ. Ә хатын-кызларның бик сирәге генә сиңа тугры булып кала.

Исем-дәрәҗәләргә беркайчан да исем китмәде. **ҖЫРЧЫНЫ ИҢ БЕРЕНЧЕ ХАЛЫК ЗУРЛАСЫН.** Әллә ничә катлы исемнәрең булып, халык сине белмәсә, танымаса, ул кәгазьләрдән, мари әйткәндәй, ни «пайда»?

Халык мине беркайчан да чит итмәде. Мин бит кыңгыраулы булдым. Минем турыданиләр генә сөйләп бетермәделәр. Халык моңа ышанмады. Шуңа татар халкы алдында башымны иеп рәхмәт әйтәм. **АРТИСТ БӘХЕТЕ – ХАЛЫК ЫШАНЫЧЫ.**

Татар халкы – бик эшчән халык ул. Татар халкы – батыр халык. Безнең халыкны чоры-чоры белән кырып торганнар, әмма ул үзен-үзе саклап калган. **ТӨПТӘН ЮАН ЧЫККАН ХАЛЫК БУЛГАНГА ИСӘН КАЛГАН УЛ.**

Ландыш ӘБҮДӘРОВА әзерләде.



Тулысынча сайтыбызда: www.syuyumbike.ru

КЕШЕЛӘРГӘ ЯЗГАН ХАТЫМ БУ!



Дөресен әйтим: мин гомерем буе әтиле балалардан эчтән генә көнләшеп, алар бәхетенә кызыгып яшәдем. Әтисез... Димәк, син таянычсыз, яклаучысыз, киңәшчесез. Әтисез... Димәк, син кимсенүле: сыңар канатлы гаилә баласы. Әтисез... Димәк, син – көчсез: аталыларның сүзе өстен.

Үз гомеремдә мин бер генә тапкыр да «әти!» дип әйтә алмадым. Кайнатам да булмады. Нурулламның әтисе дә сугыш корбаны иде. Бер тапкыр да күрмәгән, белмәгән әтием һәр көнне исемдә. Инде күптән өлкәнлек яшенә кергән ике баламны кочып алам да: «Әй, бабайларыгыз исән булып сезне күрсәләр, башлары күккә тияр иде», – дип юанып куям...

Алар да бер тапкыр да «бабай», – дип әйтә алмады. Бабай мәхәббәтен тоеп, алар киңәшен тотып үсә алмады...

Ә үзем барыбер әтиемә хат язам:

Күпме юллар, еллар узылган,
Исәпсез күп хатлар язылган...
Сиңа дигән бу хатымны, әти,
Башладым мин сабый чагымнан.

Һәм мин язам аны гомерем буе,
Сүзләремнең сайлап назлысын;
Беләм, юкса,
Син бит беркайчан да
Барыбер миңа җавап язмыйсың.

Әтием Исмәгыйль улы Мөхәммәтзакир Исмәгыйлев 1899 елда (ул чакта Балык Бистәсе) хәзерге Теләче районы Шәтке авылында Исмәгыйль бабаем белән Мәргубә әбием (әбием Балык Бистәсе районы Күки авылыннан) гаиләсендә төпчек бала булып дөньяга килә. Шук, шаян Закирны Казан мәдрәсәсенә укырга бирәләр. Ул шәһәрнең алдынгы фикерле яшьләре белән аралаша. Һәм... «рус-татар мәктәбе»ндә укый башлый. Ә инде 1918 елда хәрби хезмәткә чакыралар. Татар, урыс телләрен әйбәт белүен, гарәп, латин, урыс шрифтларында укуын-язуын искә алыптыр, аны Урта Азиягә җибәрәләр. Ул отряд командиры булып Бишкекта, кавалериядә хезмәт итә. Урта Азиядә совет власте урнашканчы шунда була. Әллә ничә тапкыр яралана. Дошман кылычы сөягенә үк җитеп, сул кулы беләзәгендә тирән җәрәхәт ясый. Нәтиҗәдә, ул кул зәгыйфь булып кала.

Әти, ниһаять, 1926 елда туган авылы Шәткегә кайтып төшә. Утны-суны кичкән, солдат тормышының әчесен-газабын татыган егет, өйләнеп, үз тормышын корып җибәрә. Иң беренчеләрдән булып колхозга керә. Аны колхозның мал табибы итеп билгелиләр. Тик кулындагы, тәнендәге сугыш яралары төннәр буе сызлый. Җилкәсендә дә аркылы-торкылы кылыч яраларының җөйләре сузылган иде, дип сөйли иде әни.

Саф һаваның шифасы тимәсме диптер, әтине урманчылыкка чакыралар.

Тик бу тынычлык озакка бармый – тагын сугыш! Әти тагын кулына корал ала. Фашист Мәскәүгә ыргыла. Дошман Калуга өлкәсенә җиткән. Юхнов районы Тотеево авылы өчен каты сугышлар бара. Яз сулышы бөркеп торган апрель көнен әледән-әле фашист самолетлары айкый. Авыл өстенә бомбалар яудыра. Бар тереклекне юк итеп, сытып «тигр»лар килә. 17 нче укчы дивизиянең 1314 укчы полк солдатлары шушы мәшһәр көчне туктатырга, фашистны ничек тә алга җибәрмәскә тиеш. Авылдашлары Мәүлә Әбҗәлилов, Миңлегали Сәлахиев белән Закир да шушында. Авылдашлар гына түгел, алар урамдашлар, күршеләр дә әле. Совет сугышчылары әллә ничә танкны яндыра. Солдатлар «Ур-ра» кычкырып атакага күтәрелә. Шунда немец самолетлары бомба яудырып китә... Авылдашлар өчесе дә үлем яңгыры астында кала. Миңлегали абый бер кулын калдырып, Мәүлә абый сыңар аягын өздереп кайталар. Ә әтинең бот төбеннән үк ике аягы да өзелә. Бу көн – 1942 елның 17 апреле...

Әти сугышка авылдашлары белән бәхилләшеп киткән. «Төшемдә атым белән тирән елгага кердем, чыга алмадым», – дигән. Әмма ул төшне әнигә – Фатыймасына сөйләмәгән. Әни гомере буе әтине теленнән төшермәде. «Әтиегез болай эшләр иде», «Әтиегез риза булмас», – дип, эшкә өндәп, яман юллардан сак булырга киңәш итеп үстерүе. Бәлки, шуңадыр, әтине белмәсәм дә, аны белгәнмен шикелле... Күз алдыма китереп, аңа хат язам.

...Ялгыз калып,
Синсез калып, әти,
Җан җылыткан җанны әйт әле!
Ул бит – Әни!
Һәм ул – һәммәбезнең
Бәхетенең олы һәйкәле!

Синнән калган иң зур мирас, әти,
Тугрылыкка безне өйрәтте.
Шуңа күрә сүзнең иң олысын
Нәкъ үзенә әйтү кирәктер.

Синең гомер, синең язмыш, әти –
Сүз әйтергә минем хакым бу!
Сине уйлап, ил сулышын тыңлап,
Тик бер сиңа түгел,
Кешеләргә язган хатым бу!

Сәйдә ЗЫЯЛЫ

Фото: Шәтке. Сугыш башланыр алдыннан. Фотода булган ирләрдән сугыштан дүртесе генә әйләнеп кайта. Әти беренче рәттә унда.

ХӘЕРЛЕ ЭШ







Лилиля ГӘРӘЕВА

«Әле ярый ул вакытта эштән китәргә мәҗбүр иткәннәр. Кайчандыр аяк чалган кешеләргә хәзер рәхмәт әйтеп бетерә алмыйбыз. Җай чыкса, чакырып кунак та итәр идек әле», – диләр Рәзимә һәм Радик Бариевлар.

Бу идея аларга моннан ундүрт ел элек, йорт хуҗасы эшсез калгач килә. Кичке ашны ашаганда табын артында үзара сөйләшәләр, киңәшләшәләр дә, Радик ишегалдына агачтан әрҗә ясарга чыгып китә. Төнгә каршы «сигезле» «Лада»га шушы әрҗәне тагып, Бариевлар юлга да кузгала. Питрәч инкубаторына төннән торып чиратка басасы икән.

...Авылның язгы пычрагын ерып, артына әрҗә тагылган җиңел машина килеп керә. Урам башында ук машинадан бер хатын-кыз төшеп кала. Аягында – сүчинкә, кулында – таяк. Рәзимә үзе инде бу. Йорттан йортка йөреп ишек кага: «Апа, яшь тавыклар алып килгән идек, алмыйсызмы?» Кемдер ала, кемдер куып ук җибәрә, кемнеңдер капкасыннан ыжгырып эт чыга, кемнеңдер ата казы ысылдап кала... Ул беренче көнне бер дә онытасылары юк. «Көне буе йөреп, 10 тавык саттык. Бензин хакын да капларлык түгел. Юк, булмый икән бу бездән, дим, сата белмибез». «Тукта әле, беренче көнне үк булмас инде ул синә», – дип тынычландыра аны Радик. Бүген көненә 200 чебеш сатса, Рәзимә эшләрен «бишле»лек дип бәяли. Ә теге вакытта... Сатылмый калган чебешләрне сарайларына алып кайтып бушаталар. Икенче көн тагын юлда уза... Өченче көнне дә чыга алар, дүртенчесендә дә... Казан базарларында да саталар. Икенче елны инде аларны халык үзе көтеп ала: «Теге елны сез йөргән идегез бит, бигрәк яхшы булып үсте чебешләрегез», – диләр. Бизнесменнар теле белән әйтсәк – клиентлар базасы туплана. Теләсә-кайсы бизнеста иң мөһиме шул бит.

Рәзимә сөйли: «Без халыкка яхшы чебиләр сатарга тырыштык. Питрәчтән, Чаллыдан, хәтта Пермьнән үк барып алып кайта идек. Иртәгә үк партиясе белән кырыла торган чебиләрне бары бер генә тапкыр сата аласың, халык сине танып кала да, башка алмый ул. Хәзер әнә безнең исемнән әллә кемнәр сатып йөри икән. «Соң, безне таныйсыз бит инде, теләсә кемнән алмагыз», – дибез. Моңарчы тын гына утырган уллары Булат та сүзгә кушыла: «Әнидән башка гына чыксам, миннән дә алмыйлар, «Рәзимәдән генә алабыз», – дип борып җибәрәләр».

Яшьләр шәһәргә ыргылганда, югары белем алып авылга кайта Булат. Быел аның магистр дипломы яклый торган елы. Әмма киләчәген һич кенә дә шәһәргә бәйләп карамый ул.

Булат сөйли: «Мәктәптә укыганда минем дә тизрәк шәһәргә китәсем, шәһәрчә яшисем килә иде. Имеш, анда кинотеатрларга йөрисең, кафелар, төнге клублар бар. Нәкъ өч елга җитте ул эйфория. Шәһәрнең ыгы-зыгылы тормышы, чиратлар, бөкеләр туйдырды. Кино карыйсың килсә, анда авылдан да барып була бит. Бассейн кирәкме – ул Арчада гына да бар. Укуны тәмамлагач, эти планнарны сораган иде, авылга кайтам, ферма салабыз, дидем. Кемдер биргән 20–30 мең сум акчага йөргәнче, үземә үзем эшлим мин».



Фото: Анна Арахамия





Нәрсәдер син теләгәнчә килеп чыкмаса, бер дә хафаланасы түгел икән. Димәк, монысы хәерле булмаган, алда тагын да яхшырагы көтә.

10 яшеннән бирле чебешләр арасында инде бу егет. Дуслары мәктәптән соң уйнарга чыгасыларын сөйләшеп кайтканда, ул эшлисе эшләрен барлап кайта. Аның уйнап йөрергә вакыты юк: тавык карыйсы бар.

Эшеңнең син уйлаганча гына бармавына пошынырга кирәкми Минеке түгел, Рәзимә һәм Радик Бариевларның сүзләре бу.

Икесе дә Биектау районының Коркачык авылыннан. Яшь аралары бер генә ел булып, бер мәктәптә укысалар да, танышуын Казан–Арча электричкасында танышалар. Улларына бер яшь тулганда Арчага кайтып төпләнә яшь гаилә. Хәтта фатирда яшәгәндә дә, сарай салып, мал-туар асрыйлар – авыл тормышы каннарына сеңгән. Аннары йорт сатып алалар. Бизнесны үстерү өчен акча кирәк булгач, аны сатарга булалар. Сатып алучысы тиз табыла үзе, документлар да әзерләнә, теркәү палатасына да тапшырыла, икенче көнне йортны саткан акча счетларына күчәргә тиеш була. Ләкин... иң соңгы көнне банк йортны алучыларга әҗәт бирүдән баш тарта. Акчасы түләнмәсә дә, документта йорт бит инде сатылган. ...10 көннән аларның кәгазьләрен кире боралар – хата калган була. Теге сүзләрнең хаклыгына алар әнә шул чакта тагын бер инана. «Ул көнне сатылган булса, без бу эшкә тотына алмый идек. Яңа йорт төзи башлаган вакыт, шунда кирә иде дә бетә иде», – ди Рәзимә ханым. Җитмәсә, шуннан соң озак та үтми, йорт бәяләре дә нык кына артып китә. Менә бит!



2017 ел – тормышларының зур борылыш алган елы – Рәзимә Бариева исеме белән крестьян-фермер хуҗалыгы булып теркәләләр. Хуҗалык булгач, аның биләмәсе, корылмалары да кирәк бит инде, гаражда гына чеби асрап, әллә ни кыра алмыйсың. Апрель аеннан үзләренә ярардай җир эзләргә тотына Бариевлар. Хуҗалыкны Коркачык тирәсендә төзиселәре килә, ни әйтсәң дә, туган авыллары, ә авылны эш урыннары яшәтә. Ләкин аларга насыйп җирләр Арча районының Якты Көн авылында булган икән. Әле монда да уйлаган ниятләре беренче омтылыштан ук барып чыкмый. Дөресен әйткәндә, аның барып чыкмавы тагын хәерле була.

Радик сөйли: «Теге йортыбызны кабаттан сатып, Якты Көннең җимерек ферма бинасын алырга булдык. Иртәгә документларны тапшырып, кул куешабыз дигән көнне Арчаның аксакалы Әгълиев Илдус Котдусович белән киңәшәсе иттек. Тәҗрибәле, күпне күргән кеше бит. «Ашыкмагыз!» – диде ул. Әле ярый шалтыраткканбыз, әле ярый киңәшен тотканбыз, шуның белән «каба» да идек. Авылга 300 метрдан якынрак килеп, ферма төзергә ярамый икән. Элек төзелгәннәрен дә сүттерергә мөмкиннәр».

Бүген ике цехта 15 мең бройлер үстерелүче бу тавык фермаларын алар басу уртасындагы тигез җирдән күтәрә. Читтән карап торучыларга ул, бәлки, төн эчендә җенпәриләр көче белән торгызылган булып та тоеладыр. Монда да чәчне агартырдай хәлләр була әле.

Рәзимә сөйли: «Апрельдә эзли башлаган җирне көз ахырында гына рәсмиләштерә алдык. Моны Аллаһы Тәгаләнең ярдәме дими, ни дисең: ул елны безнең бәхеттән кыш соң килде. Ноябрь ахырында да кар ятмаган иде әле. 28 ноябрьдә беренче цехның нигезен күтәрдек, икенче көнне 20 сантиметр калынлыгында кар яуды. Яңа күтәргән нигезне салам белән чак күмеп өлгердек. Өшетмәдек! Бетон туңса, яз көне барысын да җимереп, өр-яңадан төзисе була иде». Беренче елны монда казлар, үрдәкләр үстереп саталар. Икенче цехны узган ел 56 көн (!) эчендә төзеп бетергәннәр. Монысында дәүләт ярдәме дә тигән – миллион ярымлык грант откannар. «Аның артыннан йөрүе бик кыен, бик күп документ җыясы, дип, без кул салындырган идек инде. Районның авыл хуҗалыгы идарәсе җитәкчесе Гатиятов Ринат Мансурович үсендерде. «Дәүләт бирәм дип торганда, кирәкми дип ятмыйлар инде», – дип, сүзе белән дә, эше белән дә ярдәм итте. Ул булмаса, ярты юлда туктала идек», – ди фермер Бариевлар. Чынлап та, ул ярдәм бик урынлы булып чыккан, 800 квадрат метрлы икенче цехны да эшләтеп җибәрә алганнар. Хәзер фермада үзләре белән бергә җиде кеше эшли. Җиде кеше эшле булган диган сүз бит ул. Зөлфәт, Ленар, Васил, Бильгуслар Казанбаш авылыннан ук килеп йөри. «Бу егетләр турында берүк телгә алыгыз, – ди ферма хуҗалары. – Андыйларны башта табарга кирәк әле. Ферманы төзергә дип килгәннәр иде, инде менә үзебез эшлибез, дип, эшкә дә калдылар». Егетләрнең эшеннән бик канәгать алар. Якында гына эш булуына тегеләр үзләре дә шат.

Шушы урында тукталырга җыенмый әле Бариевлар. Болары – зур проектның башы гына. Тагын ким дигәндә ике цех төзергә кирәк, ди алар. Булатлары инкубатор эшләтеп җибәрергә хыяллана. Алай да ниятләренең иң зурысы: Арчада кош ите эшкәртү комбинаты ачу. Тагын бер-ике елдан кибет киштәләрендә Арчада җитештерелгән кош ите күрсәгез, тәгаен, Рәзимә һәм Радик Бариевларныкы булыр ул.

ЧӘЧӘКЛӘР ДӨНЬЯСЫНДА



Чәчәкләр яратмаган хатын-кызлар юктыр ул. Кулыбыздан килсә, әйләнә-тирәбезне матур гөлләмәләргә күмәр идек тә, шул гүзәллеккә генә сокланып яшәр идек. Безнең героебыз Камилла БАҺАВЕТДИНОВА исә бу хыялын чынга ашырган – флорист һөнәрен сайлаган. Чәчәкләр сату белән шөгыльләнгән әнисен уздырып та җибәрмәкче була әле (балалар әниләренә караганда камилрәк була диләр бит!). Ә тәҗрибә тупларга аңа WorldSkills эшче һөнәрләр хәрәкәте ярдәм итә. Ул Бөтенроссия ярышларында Татарстанның җыелма командасында флористика компетенциясендә көч сынашачак.

Шундый кызыклы, тылсымлы дөнья ул флористика! Әнә, Камилланы да үзенә бөтереп алып кереп китте. Никадәр белем, мәгълүмат туплады инде ул. Япония флористиканың ватаны санала. Анда чәчәкләр – культураның бер өлеше. Күпчелек илләрдә флорист булып ир-атлар эшли, чөнки ул физик яктан авыр хезмәт. Ә безнең илдә ул һөнәр – хатын-кызларныкы. Матурлык белән нәфис затлар гына эшләргә тиеш кебек. Флористлар матур гөлләмәләр генә ясап калмыйлар, кешеләргә яхшы кәеф тә бүләк итәләр. Камилла әнә шул матурлык дөньясында үсә. Әнисе Гөлнара Баһаветдинова инде 24 ел буе чәчәкләр белән эшли. Кечкенә сату ноктасында башлаган эш бизнеска әйләнә. Флористика салоны ача. Камиллага 10 яшьләр булганда әнисе кызын эшенә алып килеп, чәчәкләр дөньясына алып кереп китә. Үсмер кыз вакыты булган саен, әнисе янына ашыга. Ярдәм дә итә, иҗат белән дә шөгыльләнә: уйларында йөрткән гөлләмәләрне ясый, сатып алучылардан мактау сүзе ишетеп, күңеле тагын да канатлана. Тугызынчы сыйныфтан соң укуын урта һөнәри белем бирү йортында дәвам итәргә карар кыла ул. Нинди һөнәр сайлыйм икән дип аптырыйсы юк: флорист булачак. Тик Казанда әлеге һөнәр буенча белем бирмиләр. Камилла Халыкара хезмәт күрсәтү көллиятендә татлы эшләнмәләр кондитеры булырга укый. Ә чәчәкләре һаман илһамландырып, күңелен алгысытып тора. Елларда әнисенә булыша, ә пешергән тортларын тере чәчәкләр белән бизәп, әйләнә-тирәдәгеләрне таң калдыра. Узган ел WorldSkills хәрәкәтенә кушыла кыз. Иң элек укыган һөнәре буенча ярышып карый. Беренче урын ала алуын, тик нидер җитми кала аңа. Күңеленә якын компетенция – флористика буенча да көч сынашып карыйсы килә. Гөлләмәләр ясый белә. Иң мөһиме – зәвыгы бар. Тәвәккәлләп, көллияттә узган ярышларда катнаша һәм... җиңә. Төбәк чемпионатында да беренче урын алып, Татарстанның җыелма командасына эләгә. «Чәчәкләр белән эшләү тәҗрибәм булгач, ярыш авыр тоелмады, – дип искә ала Камилла. – Минем бик тә җиңәсем килә иде».

Хәзер узачак WorldSkills эшче һөнәрләр буенча Бөтенроссия ярышларында катнашырга әзерләнә. Мәскәүгә барып, флористика мәктәбендә дә укыйлар, Казанда экспертлар белән дә шөгыльләнәләр. Төрле гөлләмәләр ясыйлар: кәләш букеты, өстәл бизәге булган такыялар, композиция... яңа техник алымнарга өйрәнәләр. «Җиңү генә көтәм, – ди ул ярышлар хакында сөйләшкәндә. – Мин ясаган матурлыкны карап сокланачаклар, үз бәяләрен бирәчәкләр. Бу горурлык та, үзенә күрә имтихан да».

Камилланың уңышларына барыннан да ныграк әнисе сөенә. Чәчәкләр дөньясына ул җитәкләп алып килде бит, беренче гөлләмәләрен ясарга, флористика серләренә төшенергә ул ярдәм итте! Ә Камилланың максаты зурдан: эшче һөнәрләр ярышының Европа чемпионатына барырга җыена. Аннары инде көллиятне тәмамларга да күп калмый. Ярышларда катнашып, тәҗрибә туплаган флорист кыз үз бизнесын булдырырга хыяллана. Казанда гына түгел, Россия буенча флористика салоннары ачарга тели ул. Матурлык дөньясында кайнаган, көн саен тере гөлләрдән букетлар ясаган Камилладан чәчәкләр хуш исе, яз исе килә.

– Мин үзем сизмим дә инде, – ди ул, яраткан чәчәге альстромерия кебек, тыйнак кына. – Бары шуны гына төгәл беләм: чәчәкләр – минем тормышым, киләчәгем...

Чулпан ГАЛИӘХМӘТОВА


Фото: www.pixabay.com

ГОМЕРЛЕК БҮЛӘК
ЯКИ КАБАТ ИСЕМНӘР ТУРЫНДА



Альбина ГЫЙЛЬМЕТДИНОВА

Бәби көткән вакытым. Инде соңгы айга кердем... Табибтан чыктым да, җәяү генә өйгә кайтып барам. Беркая ашыкмыйм – тирә-юньне күзәтә-күзәтә әкрен генә атлыйм.

Минем алдан оныгы белән сөйләшә-сөйләшә бер әби атлый. Балалар бакчасыннан кайтулары бугай. «Кара, татарча ничек матур сөйләшәләр!» – дип уйлап кына бетергән идем, әби кеше оныгына: «Вилена», – дип дәште. Вилена... Исеме шулай булып чыкты кызчыкның. Менә сиңа мә, бигрәк сәер исем, бер дә безнеңчә түгел бит бу. Кызык булып китте... Бәлки бу исемнең мәгънәсе бик тирәндер дип, өйгә кайтуга тизрәк интернетны ачтым. Вилена исеме килеп чыгышы белән В. И. Ленинга «бурычлы» икән. Икенче бер версия буенча, Вилена – алманнарда очрый торган Вильгельм исеменең хатын-кызларга кушыла торган формасы. Шуның белән шул... Ни кызганыч, исемнең мәгънәсе бер дә әллә кем булып чыкмады.

Безнең кызыбыз туарга да санаулы атналар гына калып бара бит дигән уй йөгереп узды башымнан. Дөньяга яңа кеше килә! Әлегә кадәр әллә ни хисләргә бирелеп утырырга вакыт булмады. Кичкә кадәр эштә идем, фатирыбызда ремонт бара, ирем командировкага йөри... Тәгәрмәчтәге тиен кебек әйләндем генә. Инде иркен сулыш алсам, хыяллансам да ярыйдыр: кызымның күзләре, чәчләре нинди төстә булыр, холкы? Ә тавышы? Әтисенәме, миңамы күбрәк охшар ул? Ә исеме, исеме нинди булыр соң аның? Баланың бөтен кирәк-ярагы инде әзер, тик исеме һаман юк лабаса!

Белгәнебезчә, баланы ислам динендә тәрбияләү һәм балигъ булгач, аны никахлаштыру белән беррәттән, мәгънәле исем сайлау һәм исем куштыру да ата-ананың

бурычы. Исем кушуга зур җаваплылык белән карарга кирәклеге турында миңа әбиләрем гел әйтә килде. «Балага гомерлек бүләк ул», – дия торган иде бер әбием. Элек-электән исем куштыруга алдан әзерләнгәннәр, бу көнне кунаклар чакырып, табын корганнар – исем туе дип мәҗлес җыйганнар. Хәзер инде бөтен туган-тумачаны җыеп, яңа туган баланы киезгә салып, мулланы өйгә чакырып исем куштырулар сирәгәйде. Күбрәк мәчеткә барып, шунда гына куштырып кайталар. Кызыбызга исемне без үзебез бала тудыру йортыннан чыккан көнне үк куштырдык. Бары иң якын туганнарыбыз гына безнең белән булды.

Бәби көткәндә барлык исемнәргә игътибар итә башлыйсың, баш миендә аерым папка «ачып», кайбер ошаганракларын шунда туплый барасың икән ул. Ә инде «иң-иңнәрен» махсус блокнотка яза бардым. Шактый озын исемлек килеп чыкты... Ирем белән уртак фикергә исә бәби туар алдыннан гына килдек. Хәзерге интернет заманының бер бик уңай ягы бар: исемне ишетүгә, глобаль челтәрдән аның килеп чыгышы, мәгънәсе турында мәгълүмат алырга була. Безнең әниләр заманындагы шикелле китаплар эзләп, актарып, кешеләрдән сорашып йөрергә кирәк түгел.

Әлбәттә, исем сайлаганда аның еш яки, киресенчә, сирәк очравы мөһим әйбер. Бөтен кеше дә бертөрле күлмәк киеп йөрсә, аның матурлыгы сизелмәгән кебек, һәр икенче бала да бер үк исемне йөртсә, аның кабатланмаслыгы югала, минемчә. Моннан 15 еллар элек, без мәктәптә укыганда, Айгөл һәм Гөлназ исемнәре бик популяр иде. Әлбәттә, матур исемнәр. Тик шулай да, бер сыйныфта укучы җиде кызның дүртесе Гөлназ булса, кызык түгел икән. Кеп-кечкенә авылда бит бу!

Элегрәк кызларга да, егетләргә дә бер үк исем кушу гадәте бар иде. Илсөяр Чулпанович ничегрәк сезгә? Ә бит шундый исемле ир-атлар бар. Мәсәлән, безнең якта Айназ исемен егетләргә кушалар. Казанга килгәч, Айназ исемле кызларны очрату баштарак кызык та, сәер дә булып тоелды миңа.

Кызыбызга исем эзләгәндә, интернеттан Татарстандагы популяр исемнәр рейтингын карап чыгарга булдым. Чөнки һәрвакыт ниндидер тенденция күзәтелә. Әйтик, без бала чакта Ләйсән, Лилия, Румия, Эльвира, Алсу, Ленар, Ренат, Айрат, Айдар, Илшат кебек исемнәрне еш кушалар иде. Бераздан аларны Әдилә, Камилә, Эмильләр алыштырды.

ЗАГС Идарәсе мәгълүматларына караганда, узган елның иң популяр ир-ат исемнәре – Әмир, Кәрим, Тимур. Татарстандагы ир-ат исемнәренең алтын өчлеге дияргә була аларны. Кызлар исемнәре арасында иң популярлары – София (соңгы елларда Сафия вариантын бик еш куша башладылар. «Чиста», «саф» дигәнне аңлата), Ясминә, Алисә. Әминә исеме күп еллар дәвамында лидер булып килсә, узган ел бу исем беренче бишлекне генә тәгәлләгән. 2013–2014 елларда Азалия, Самира, Ралиналар киң таралган булса, хәзер – Алисә, Ясминәләр күбрәк. Егетләргә берничә ел элек Камил, Артур, Самир исемнәрен күп кушканнар: хәзер балалар бакчасындагы группаларда берничә Әмир, берничә Азалия... Әлеге исемнәрнең матур мәгънәгә ия булулары да сөендерә. Ә менә элегрәк бик гади кебек тоелган Гөлчәчәк, Гөлсем, Җәмилә, Раиф, Шәүкәт кебек исемнәр бүген, киресенчә, сирәк исемнәр рейтингында урын алган.

Чып-чын татар фамилиясе белән чит ил исемнәре шулкадәр сәер яңгырый, минемчә.

Бүгенге татарлар куша торган исемнәрдә ике вектор ярылып ята. Берсе – алда аталган татар исемнәре булса, икенчесе – Европадан кергән, татар колагына ят исемнәр. Оливия, Олесия, Сати, Леонард – шундыйлардан. Глобальләшү чорының йогынтысы исемнәрдә шул рәвешле чагылыш таба. Оливияне, гомумән, шулкадәр еш кушалар, хәтта аны татар исемнәренә кертергә вакыт җитте бугай. Шаяртам, әлбәттә. Бу исемнәр дә тиздән татарда ныклап урнашырмы икәнни? Диана, Карина, Марсель кебек исемнәргә күптән исебез китми ләбаса.

Исем кушарга килгәч, кайбер муллаларның, ата-ана сайлаган исемне ошатмыйча, алыштырырга сораган очраклары бар. Шулай бер мулла танышларыбызның кызына Диләрә дигән исемне кушарга каршы килде. Әти-әнисе тиз арада Динә исеменә тукталды. Икенче бер танышларыбызның кызларына мулла Лилиана исемен кушарга теләмәде. Алар исә исемне түгел, ә мулланы алыштырдылар... Мондый очраклар булмасын өчен, алдан ук исем кушасы мулла белән сөйләшеп, исемне килешеп кую хәерле. Үз тәҗрибәмнән чыгып әйтә алам, күңелгә ошаган исемне сайлау бик җиңел түгел (әле бит аның үзеңә генә түгел, баланың әтисенә дә ошавы кирәк).

Инде сабыебызга нинди исем сайлавыбызны да әйтим. Кыз бала көтүебезне белгәч, нәфис яңгырашлы, йомшак исемнәргә игътибар итә башладык. Кызларга нәфис исемнәр килешсә, егетләргә, киресенчә, көчле, яңгырау исемнәр туры килә кебек. Бигрәк тә «Р» хәрефе ныгыта егетләрнең исемен. Миңа шулай тоела. Кызлар нечкә күңелле, нәфис, ә егетләр ышанычлы, көчле булырга тиеш. Кызыбызга Айлин дигән исемне сайладык. Ай яисә Гөл сүзләре кергән исемнәрне яратам – милли төсмер өсти кебек алар. Яңгырашы да, «ай нуры», «илһам» дигән мәгънәсе дә ошады безгә. Мөселман илләрендә Айлин шактый киң таралган исем, бездә исә сирәк очрый. Һәрхәлдә, әлегә.

Әлбәттә, әлеге язмам белән беркемне дә үпкәләтәсем, бер исемне дә кимсетәсем килми. Иң мөһиме: баланың исеме матур мәгънәле булсын, әти-әнисенә ошасын. Балалар бакчасында йөзенче Әминә булса да, сезнең өчен бит ул – берданбер. Исем кешене түгел, ә кеше исемне бизәгәнен дә онытмыйк. Балаларыбыз киләчәктә үзләренең исемнәрен эшләгән эшләре, кылган изге гамәлләре белән танытсын.

PRESSA









«БЕЗ ГАДӘТИ ТҮГЕЛЛӘР...»

Чулпан ГАЛИӘХМӘТОВА

Кирәк, дип, икең бер якка карап яшәгәндә генә гаилә тормышың түгәрәк буладыр ул. Сөенеч-көенечләр генә түгел, теләк-максатлар да уртак. Тауларга карап, тау була алмаганны да аңлыйсың, икең тапкан малдан канәгать булып яшисең. Ә ул күктән төшми. Җиде кат тиреңне чыгару гына җитмидер, бәхет эше дигән әйбер дә бардыр, мөгаен. Әллә һәр туган сабыйның култык астына Ходай икмәк кыстырып җибәрә диюләре хак микән?! Оныклары белән кечкенә уллары уйнавын сөенеп күзәтеп утырганда Рәйхан апа белән Малик абый ӘХМӘТОВлар үзләре бу хакта уйлый микән?! Хисләргә бирелеп яши торган кешеләр түгел алар, бу дөньяда нәрсә кирәген белеп, нык басып гомер итәләр. Бәлки парлы тормышның сере дә шундадыр?

Хатыны да, ире дә сокланырлык үҗәтлек белән көтә дөньяны.

Эш сөйгәннәр

Яңа Чишмә районы Тубылгы Тау авылындагы шәһәр фатирларыннан да купшырак ремонт ясалган зур йортка аяк басканда хуҗабикә аш-су тирәсендә кайнаша иде, кайдадыр эчтә чыр-чу килеп балалар уйный. Рәйхан апаның өлгерлегенә күз иярми: әле генә бәлешен карый, шул арада шулпасын тәмләп алырга өлгерә. Токмачны нәзек кенә итеп кискәненә сокланып, ни өчен килгәнемне дә онытып карап торам. Олы улларын ияртеп кайтып кергән гаилә башлыгы, ипле генә исәнләшеп, хатынына мәхәббәтле караш ташлап алды да өй эченә кереп китте. Ә без Рәйхан апа белән серләшәбез...

– Безнең бит исемнәребезгә кадәр гадәти түгел, – ди ул яшь кызлар кебек иркә елмаеп. – Хатын-кызларга Рәйханә кушалар, ә минеке – Рәйхан, Малик та безнең яклар өчен ят исем. Икебез дә шушы авылда туып-үстек. Безнең әби аларның терәлеп торган күршеләре иде. Әбиләргә аш пешерергә килә идем. Маликның апа-абыйларын хәтерлим, тик аны хәтерләмим. Күрәсең, күзгә-башка күренмәгәндер. Ул армиядән кайткач кына таныштык без. Анда да утсыз караңгы төндә. Шуннан йөреп киттек инде. Бер ел дигәндә өйләнештек. Көзнең иң караңгы ае – ноябрь иде ул. Пычрак, яңгыр... Кем бу вакытта өйләнешә инде, диләр. Кызыл туй көнне кичен кар ява башлады. Ә иртән ЗАГСка

Фото: Анна Арахамия









ап-ак кар түшәлгән ак юл буйлап атлап бардык. Миңа – 18, аңа 21яшь иде...

– Бигрәк яшь булгансыз икән бит өйләнешкәндә, – дим безнең янга чыккан Малик абыйга.

– Әйе, Рәйхан яшь иде. Алай гына түгел, гаиләдә – төпчеге, авылда беренче чибәр иде әле ул. Ә мин инде ул вакытка тормыш арбасын тартып, утны-суны кичкән кеше. 10 яшемдә әнием вафат булды. Әти белән генә үстек. 7 нче сыйныфтан бирле авыл агайларыннан калышмый эшләдем. Армиядән кайтканда да юлда көтүчеләр янына төшеп калып, көн буе көтү көтеп, авылга кич белән генә кайтып кердем. Тормыш арбасын ялгызың гына тартып бару күңелсез, өйләнергә кирәген белә идем. Менә шулай итеп авылдагы чибәрне дә үземә караттым.

Яңа Чишмә яклары эшкә нык, тырыш халык! Колхоз салып биргән йортта яши башлаган яшь гаилә дә нык-лап җигелә тормыш арбасына. Кирәк дип яшәгән Малик өйгә кайтып керми – колхозда эшли, ә Рәйхан игезәкләр үстерә. Дөрес әйтмим, балалары белән бергә үсә. Айгиз, Айгөл белән бергәләп утырып елаган чаклары еш була аның. Ике елдан Илгизләре туа. Анысы бигрәк наян була. Куркусыз, гәүдәгә абыйсыннан күпкә зуррак булса да, төпчек төпчек инде, аны кечкелдек дип йөртәләр. «Минем малайларның теле әле юньләп ачылмаган иде, ә ат өстендә утырып йөри беләләр иде инде», – дип горурланып искә ала әти кеше. 7 яше тулгач, Илгизләре, рәсми рәвештә колхозда теркәлеп, әтисе белән көтү көтә башлый.

– Ике малай арасында иркәләнеп кенә үскәнсеңдер инде? – дим Айгөлгә.

– Иркәләндем, ди, 3 нче сыйныфта укыганда әни сыер саудыра башлады. Дүрт сыерны иртән – әни, кич мин саудым.

Бу гаиләдә балаларны эш белән тәрбияләгәннәр. Шуңа да бәхетнең күктән төшмәвен, аның өчен тырышырга, хезмәт куярга кирәклеген белеп үскәннәр. Төпле, нык басып торган тәүфыйклы балалар. Ә бәхет тәүфыйкка иярә шул. Айгөлләре мәктәпне – медаль, институтны кызыл диплом белән тәмамлый. Бүген инде ул үзе әни. Ире Динар белән ике кыз үстерәләр. Ике малай үстергәннән соң кызлар тәрбияләү бөтенләй авыр түгел икән үзе... Төп йортка кунакка кайткач, дүртәүләп тәгәрәшеп уйнауларына Айгөлдән битәр, бабай – яшь әти сөенәдер, мөгаен...

Гаилә бизнесы

Сату-алу эшләренә хирыслык Малик абыйның канында. Элек әниләре дә Чистайга йомырка сатарга йөргән. Абзар тутырып мал асрый башлагач та, итне урнаштыру юлын таба хуҗа. Соңрак якын-тирәдәгеләр дә сугымнарын сатып бирүне сорый башлый. Шулай итеп, алып сату эшенә кереп китә. Җир кешесе бит, колхозда эшләвен дә туктатмый: маллар карый. Балалар исәйгәч, Рәйхан апа клуб мөдире булып эшкә керә.

PRESSA

Аны Рәйханы да хуплый. Ә ир-атны хатын-кыз үсендереп торса, таулар күчерергә дә әзер ул.

Шул вакытта Алабуга мәдәният агарту училищесында укып алырга да җай чыга. Чәчрәп чыгып, җырлап-биеп тормаса да, оештыру эшләренә сәләте була аның. Авылда аның тырышлыгы белән оештырылган «Ак калфак» өлкәннәр ансамбле бүген дә эшли әле. Аларның уңышларын ишеткән саен, горурланып куя ул. Үзе дә аларга бер кушылыр әле... тик соңрак.

Тупланган хәләл маяларын кая урнаштырырга дип, ун ел элек баш вата башлый Әхмәтовлар. Уллары буй җитеп килә, фатир алу да комачауламас дип уйлашалар. Үзләре дә һаман төзелешләрен туктатмый анысы. Төзү эшләре вакытында кадак бетсә дә район үзәгенә чыгып китүләр җелегенә төшә йорт башлыгының. Ә нигә әле төзелеш материаллары кибете ачып җибәрмәскә, дигән уй керә аңа. Күрше Ленино авылы читендәге гаражны сатып алалар да гаиләләре белән барып җыештыралар. Машинасына арба тагып, Малик абый материаллар ташый, салкын гаражда Рәйхан апа сату итә. Бүген инде аларның заманча итеп эшләнгән зур кибетләре, зур-зур складлары бар. Техникалары да җитәрлек. Авылдашларына да эш урыны булдырганнар. Башланган эш гаилә бизнесына әйләнгән. Уллары – дәвамчылары. Айгиз – кибеттә бар яктан да пөхтәлек саклаучы, Илгиз партнер-клиентлар белән уртак тел таба. Киленнәре Эльзираның да хезмәт урыны шунда. Авыл тормышын төптән тартып үскән егетләр туган җирләрен ташлап чыгып китү хакында уйлап та карамыйлар, мәктәпне тәмамлау белән кибеттә эшли башлыйлар. Авыл – безнең киләчәк, дип яшиләр. Узган ел гына өйләнгән Илгизгә зур йорт тергезгәннәр.

«Аларны җитәкләп йөргәндә горурланам...»

Ә Ходай аларга ике малайны уйламаганда бүләк итә. Үсеп җиткән балаларга сөенеп яшәп ятканда Рәйхан апа кинәт авырый башлый. Ашказанында җәрәхәт табалар. Нинди генә дарулар эчеп караса да, дәвасы тими. Аптырагач, шифаханәгә китәләр. Анда өлкән яшьтәге профессор ханымга күренергә керә Рәйхан апа. УЗИ аппараты белән бик озак тикшерә аны табиб. Үзе кабат-кабат сөйләнә: «Первого вижу, второго вижу, третьего не вижу...»

– Минем эчемдәге шешләрне саный инде бу дип, гомерем белән хушлашып беттем ул минутларда, – дип искә ала Рәйхан апа. – Авыруым да бетми, җитмәсә, соңгы вакытларда хәлем дә юк. Миндә яман чир инде дип нәтиҗә чыгарып куйдым. Күңелемдә өермә уйный. Торып киенгәч, табиб каршыма килеп басты да: «Будем рожать?» – ди. Аптырап басып торам. Үземнең күзләремнән яшь ага. Мин бит әле һаман шеш хакында уйлыйм. Ә ул: «Меня мать в 57 родила», – дип көлә. Авырлы икәнемне, әле җитмәсә, игезәк көткәнемне Маликка сөйләгәндә генә төшендем бугай. Кочаклашып еладык. Тәвәкәлләдек. Бала чүпрәкләре күптән онытылган бит инде югыйсә. Миңа 42 яшь! Иң кыены – бу хәбәрне буй җиткән балаларга җиткерү. Әтиебез шатлыгыннан нишләргә белмәде инде. Кайткач, өстәл артына җыелыштык. «Өйдә кечкенә бала булуга ничек карыйсыз?» – апа белән миңа карап, әти сәер генә сорап куйды, дип искә ала Илгиз.

– Яхшы, – дибез.

– Әгәр алар икәү булса? – ди.

Бер-беребезгә карашып, аптырап калдык. Димәк, игезәкләр! Ике дә уйламыйча, үзебез карыйбыз, дидек.

– Шатлыктан бөтенебез бергә кочаклашып елаштык. Менә шундый инде без, гадәти түгел инде, – ди Рәйхан апа.

Камил белән Кәримне алып кайткан әниләрен ремонт ясалган, хәтта пәрдәләренә кадәр алыштырылган өйдә каршылый балалары. Чынлап та, бергәләп карыйлар малайларны. Әнисенә караганда, Айгөл кыюрак тота әле бәләкәчләрне. Кияүгә дә малайлар исәйгәч кенә чыга. «Алар безнең улларыбыз кебек инде», – ди апа-абыйлар бертавыштан.

– Малайлар тугач, тормыш бөтенләй башка якка үзгәрде, яшьлеккә кайткан кебек булдык, – ди Малик абый белән Рәйхан апа.

– Олылары үскәнне күрмәдем, балалар бакчасында капканың кайсы якка ачылганын да белмәдем, – ди әти кеше. – Ә боларны үзем җитәкләп алып барам, алып кайтам. Минем белән бергә уллары булырдай егетләр балаларын алып бара. Шул вакытта ничек горурлануымны белсәгез...

Гомер уртасына җиткәч яшь әти булып йөр әле! Горурланырсың да!

– Зурлары эш арасында үсте, ул вакытта тормыш та болай җитеш түгел иде. Ә болары безне биетә, – ди Рәйхан апа, кечкенәләренә яратулы караш ташлап.

Өлкәннәре – терәк, киңәшче. Зур уллары белән сөйләшкәндә ата-аналары аларга ышанып бага. Кечкенәләре дә йөзгә кызыллык китермәс. Аларга үрнәк булырдай апа-абыйлары бар.

Өйнең нурын саклаучы Миннерәхилә әбинең намазда кылган догалары кабул булганга да бу өйдә бәрәкәт хакимлек итәдер. Акъәбинең кулыннан Коръәне төшми. Әкренләп кенә мәчеткә укырга йөрүен дә дәвам итә әле. Бәхетле картлыгында бөтен теләге – балаларының, оныкларының иманлы булып матур тормышта яшәүләре.

Яшьлектәге кирәк һаман кирәк булудан туктамый әле. Хәзер әнә үсеп килгәннәрен аякка бастырырга кирәк. Тигез гомер генә язган булсын. Дөнья көтеп, балалар, туганнар (ә алар бергә җыелсалар, 82 кеше була!) белән кайнашып, 30 ел уртак тормыш сизелми дә үткән инде. Сиздерми генә әнә шулай энҗе туйлары да килеп җитәр. Аларда ясалмалылык та юк, күргәзмә өчен дип тә яшәмиләр, бары тик гап-гади түгәрәк бәхетләреннән тәм табып, тормышның бар асылын балаларында күреп гомер итәләр. Парлы гомер итәләр.

НӘФЕС



Илнар хәзрәт ЗИННӘТУЛЛИН,
«Туган авылым» мәчете имам-хатыйбы

Кеше нәфес белән туамы, әллә ул барлыкка килә торган сыйфатмы?

– Кеше нәфес белән туа. Ул безгә, беренчедән, сынау өчен бирелә. Кешегә нәфесен җиңүгә караганда, тышкы дошманнарын җиңү җиңелрәк. Әйтик, тәмәке тартуны ташлауга караганда, ул урамда кем беләндер сугышуны өстенрәк күрә. Кеше әллә нинди үрләргә үрли, зур-зур эшләр башкара, ә диетага утыра алмый... Иман белән нәфес көрәшә башлагач, кайсысы җиңә, шуңа карап кешенең никадәр иманлы, тәкъва икәне билгеләнә. Аллаһы Тәгалә дә кыямәт көнендә йөрәгебезгә караячак: бу бәндә нәрсәне җиңгән? Нәфесен җиңә алганмы? Пәйгамбәребез дә, «ачуы килгәндә үзен тотып калганнар яки авырлык килгәндә сабырлык күрсәткәннәр көчле», ди. Дошманны түгел, үз-үзен җиңүче! Нәфес белән көрәшә алу – көчлелекнең төп күрсәткече.

Ләкин нәфеснең файдалы яклары да бар. Пәйгамбәребез: «Әгәр нәфесегез мин алып килгән әйберләрне яратмаса, берегез дә иман китермәс», – ди. Ягъни нәфесне шулай итеп тәрбияләргә кирәк, ул яхшы әйберләрне (динне, намазны...) ярата башларга тиеш. Әйтик, ялкаулык, яманлык, азгынлык, комсызлык кебек яман сыйфатлар – барысы да нәфестән килә. Ләкин аларны яхшы якка юнәлдерергә дә була. Кеше, мәсәлән, комсыз, ул мал җыярга, әйбер җыярга ярата. Ә бит аны комсыз рәвештә савап җыюга да әйләндереп була.

Нәфес – ул безнең инстинктыбыз. Җиңеллеккә, үз-үзебезгә рәхәт, ләззәт алырга омтылуыбыз. Хайвани инстинктлар дип тә әйтәләр нәфесне. Мәсәлән, кеше ниндидер ризык күрә һәм шунда ук аңа үрелә. Ислам дине бит алай эшләргә кушмый. Күрдең икән, башта кара: хәләлме ул ризык, әллә юкмы? Шул вакытта гына аша. Ә бәлки синең ашыйсың килмидер, димәк, кызыксаң да, тыел. Чөнки тук килеш ашарга ярамый – бу да комсызлык. Әйтик, кеше менә гел беренче булырга ярата, шуның өчен тырыша. Моңа ирешә алганнардан көнләшә. Пәйгамбәребез исә: «Ике генә очракта кемнәндер көнләшергә мөмкин: уңга-сулга сәдака биргән юмартлардан яки гыйлем алучылардан», – ди. Әйе, нәфесне дөрес итеп куллана белергә кирәк. Югыйсә аның сине гөнаһлы юлга да этәрүе бар. Хатын-кызны ошатасың икән, шунда ук түшәккә әйдәмә – башта кулын сора, никах укыт: шул чакта ул инде сиңа хәләл була. Ислам дине бу әйберләргә тәртип кертә. Ә нәфес, шул кагыйдәләрне урап узып, үз дигәненә ирешергә тели. Шулай итеп, безнең белән шайтан уйный.

Нәфес белән ничек көрәшергә?

– Нәфес белән көрәшү өчен ул яратмаган нәрсәләрне эшләргә тырышырга кирәк. Әйтик, ул күп ашау һәм күп йоклауны ярата. Кеше өчен иң ләззәтле нәрсәләр – шушы. Ничек яхшы булдың дигәч, бер галим: «Мин бөтен нәрсәне нәфесемә каршы эшләдем, – ди. – Йокым килгәндә, торып, намаз, Коръән укыдым. Ашыйсым килгәндә – ураза тоттым. Ярамаган нәрсәгә күзем төшсә, карамадым».

Пәйгамбәребезнең нәфесе шулкадәр идеал була ки, нәфесе аны яхшылыклар кылырга үзе өнди башлый. Аның нәфесе гыйбадәтне яраткан. Намаз укымаган кеше намазлы кешегә шакката: ничек укый, иртүк тора, йокысын җәлләми, ди. Ә без төннәрен дә өстәмә намазга торган кешегә шаккатабыз. Пәйгамбәребез үзе, аның сәхабәләре, галимнәребез дә шулай булган. Кайбер галимнәр ястү намазыннан иртәнге намазга кадәр төне буе намаз укып чыккан. Алар нәфесләрен җиңгән, һәм нәфесләре намаздан рәхәт ала башлаган. Без исә ике сәгать буе концертта утыра алабыз, әмма ярты сәгать Коръән тыңлый алмыйбыз – ардыра, туйдыра, йокы килә башлый...

Нәфесне бары дин-иман юлы белән генә тәрбияләп була. Башка юллар белән тәрбияләсәң, нәфеснең бер чагылышыннан икенче чагылышына кереп китәргә мөмкинсең. Әйтик, тартуны да, эчүне дә җиңдең, күп йокламыйсың, күп ашамыйсың, булган байлыгыңны өләшеп барасың... Бу очракта мин хәзер бөтенесеннән дә яхшырак, өстенрәк, дип, тәкәбберлеккә кереп китүең бик мөмкин. Аллаһы Тәгалә ярдәме, иман белән генә дөрес юнәлеш табарга була.

Ләкин күп кеше барыбер нәфес белән яши. Кемгәдер файда китерәм дип түгел, нәфес белән эшли. Гаилә корам дип түгел, бу кешене үземнеке итәм дип өйләнә. Кемгәдер бәхет китерәм дип түгел, ялгыз калмыйм, дип кияүгә чыга... Күпләр нәфес белән яшәвен үзләре дә белмәскә, аңламаска мөмкин. Кайчак мөселман ирләре килә: «Икенче хатын аласым, савап эшлисем, ялгыз хатынга ярдәм итәсем килә», – диләр. Чынлыкта, кемгәдер кызыкканнар – нәфескә ияргәннәр, хәзер шуны акламакчылар. Әйткәч, моны үзләре дә таный.

Нәфес кемнәрдә күбрәк: ирләрдәме, хатыннардамы?

– Ул аларның икесендә дә бертигез. Әмма нәфескә хатын-кыз җиңелрәк бирелә. Ул бит эмоциональ зат, шуңа күрә аның белән идарә итү дә җиңелрәк. Хатын-кызлар ирләргә тиз ышана. (Гомумән, алар ышанучан.) Ир-ат аларны сүз белән дә бик җиңел алдарга мөмкин. Шайтан да хатын-кызны тизрәк алдалый. Шуңа күрә сихерче-багучылар да күбрәк – хатын-кызлар. Кызганыч, нәфескә дә алар күбрәк бирелүчән. Хатын-кыз дөньяга да күбрәк тартылучан. Гадәттә, ир кешенең тормышын хатын-кыз алып бара. Ләкин моны бөтенләй начар күренеш дип әйтеп булмый. Иң мөһиме – гөнаһка, хәрамгә генә алып кермәсен. Хатын-кыз: «Бөтен кеше баеды, урла инде, ичмасам», дип таләп итә башласа, бу инде хәрамгә керту була.

PRESSA

САГЫНА СИНЕ ҮРӘЗМӘТ...



– Их, Әзһәм абый булсамы хәзер!.. Май бәйрәмнәре алдыннан өмә ясап, зиратны ялт иттертеп куяр иде... Аннан казан асып пылау пешертер, яланда бөтенесен сыйлар иде!
– Сабантуйга быел да артистлар алып кайтыр иде...
Кыр батырларына, көрәшчеләргә бүләкләрен өләшер иде...
– Мәктәп тәмамлаучыларга тагын телефоннар бүләк итәр иде микән...
– Их, исән булса!..

Эльмира ЗАКИРОВА

Үрәзмәтләр шулай юксына авылдашларын. Ә авыл картлары мәчеткә намазга җыелган саен Әзһәм рухына дога кыла. Сабакташлары Сикия буасы буенда Әзһәм оештырган классташлар очрашуын кабат-кабат күңелләреннән үткәрә.

Кем соң ул Әзһәм? Нигә шулкадәр кадерле ул үрәзмәтләргә? Якташлары, авылдашлары сөйләгәннәрдән, яраткан Ләлә апасы хатирәләреннән, апасының кызы Лилия истәлекләреннән, хатыны Нәфисәнең өзгәләнүләреннән, уллары Нәсим белән Марсельнең, оныкларының сагынуларыннан Мөслимнең асыл улы – гади һәм тыйнак, тәвәккәл һәм батыр, ярдәмчел һәм кайгыртучан олы йөрәкле Әзһәм Әзһәт улы Хөсәенов күз алдына килеп баса. Әйтерсең мин кино карыйм.

«...Без Хөсәенов Әзһәт һәм Мәкнүнә гаиләсендә бишәү туып, бәхетле балалар булып үстек. Әткәй – колхозның беренче шоферы, механигы, озак еллар хуҗалыкның профсоюз рәисе булды. Әнкәй – авыл советы секретаре, бухгалтер иде, эшләгән дәверендә аны авыл советы депутаты итеп тә сайладылар. Икесе дә киң күңелле кешеләр иде. Авылда беренчеләрдән булып телевизор алдык та, бөтен урам баласы безгә хоккей карарга җыела башлады. Ә әнкәй аларны сыйлап чыгара иде. Безнең эшләр бүленгән, һәрберебезнең эш планы иртән торуга дәфтәрдә язылган була иде: кызлар өй җыештыра, ашарга әзерли, малайлар ишегалларын чистарта, маллар карый. Укуда да, эштә дә без аларның йөзенә кызыллык китермәдек: барыбыз да югары белем алдык», – дип, Әзһәмнең апасы Ләлә Талипова еракта калган балачак, яшьлек елларына алып кереп китә...

Хөсәеновларның үзләре кебек тырыш, булдыклы балалары Ләлә, Әзһәр, Әзһәм, Әзнәф, Ләйсәнне мин балачакларында – Үрәзмәт урамнарыннан йөгереп уза итеп күрәм. Бу Үрәзмәт малайлары барысы да шук, туры сүзле, үҗәт була микән әллә? Баш бирмәс, дисәләр дә, күңелләре чиста, бунтарь йөрәкле, куркусыз егетләр бит алар. Әзһәмне генә ал! Әзһәт абый белән Мәкнүнә апа: «Ләлә белән Әзһәр укыганда гел президиумнан төшми идек. Ә Әзһәмнең шуклыклары өчен мәктәпкә чакыралар, «кара син бу малайны!» дип шелтәләгәндәй итсәләр дә, ерык авызлы, эчкерсез, төрле кызыклар уйлап чыгарырга әвәс, ялган-хәйләне белми торган чын егет үсеп килгәнен бөтен йөрәкләре белән тоялар.

Чыгарылыш имтиханнары, мәктәп белән саубуллашу. 18 яшьлек егетне армиягә озатулар... Әзһәмнең теләге кабул була: Әфганстанга җибәрәләр...

1980 елның 15 июнендә керә ул Әфган сугышына. Төньяк Кундуздагы 53380 нче хәрби часть, ОБМО батальоны. БТРлар. Сиреналар улавы. Миналар, гранаталар шартлавы, тынлыкны өзеп гранатомет ухылдавы... «Дошман» тозаклары, дуга сыман бормалы тау сукмаклары... Кояш рәхимсез кыздыра, кайнар җил тынны куыра. Палаткада йоклап яткан солдатларны «дух»лар автоматтан ут яудырып кырып чыкканда яшәүнең никадәр кадерле икәнен кабат тоя Әзһәм. Алар берничә солдат кына исән кала. Пуля Әзһәмнең җилкәсенә тияртимәс очып уза. Менә кайда ул чаларган чәчле 18 яшьлек егетләр... Ә дембельгә ерак әле...

– Әфганнан ялга да кайталган әле ул. Клубта яшьләр белән сугыш турында кино карап утырганда, экранда

атышлар башлангач, ут капкандай сикереп торган да залдан чыгып ук киткән... Ике тапкыр кайтып, икесендә дә бүтән күрешә алмабыз дип елап хушлашкан... Әфганстан характерын үзгәртмәгән барыбер дә. Бераз катыланган, ләкин эмоциональ, нечкә күңелле һаман. Әби белән бабайны да иң нык кайгырткан, алар өчен барысыннан да ныграк борчылган кеше ул... – Лилия бүгенгегә кайтара шулай.

Ике ел буена адым саен үлем сагаласын да, ул-бу була калса, үз-үзеңне шартлатырга дип кесәңдә граната йөрт тә, ничек тыныч калмак кирәк? Менә шунда төшенгәндер ул кеше гомеренең кыйммәтенә, яшәү мәгънәсенә, тормыш кадеренә.

...Ә минем «кино»дагы Әзһәм инде Әфганнан да кайтты, җиденчедән бирле яратып йөргән классташ кызы Нәфисә белән гөрләтеп туй да ясадылар. Бәхетле гаиләнең Әлмәттә бер-бер артлы уллары да туды. Әзһәм авыл хуҗалыгы институтын тәмамлап, инженер дипломы алды. Үз шәхси эшен ачып, юл төзү эшләре белән шөгыльләнә башлады. Һәм тирә-юнендәгеләрне үзенең ярдәменә, кайгыртуына күмде.

Менә ул, әтиләре Әзһәт абыйны соңгы юлга озаткач, зиратны тәртипкә китерүне үз өстенә ала. Ел саен авыл халкы белән өмә үткәрү матур гадәткә әйләнә.

Үрәзмәт авылының мәчетен дә үз акчасына ике ай эчендә төзетеп куя Әзһәм һәм аңа әтисе хөрмәтенә «Әзһәт» мәчете дигән исем бирә. Үрәзмәт картлары игелекле бу балага мең рәхмәтле. Алакай нәселеннән булган указлы азанчы Габделваһап, Бохарада дин гыйлеме алып кайтып мәчет салдырган Хөсәен мулла токымыннан бит ул Әзһәм, диләр.

Авылдагы мәктәп, медпункт, клуб коймалары, мәктәпкә ясалган ремонт, Яңа елда «Наз» приюты балаларына бүләкләр, авылда үткән Коръән ашлары, Әфганстанда ятып калган райондашларның исемен мәңгеләштерү өчен ясатылган истәлек такталары – бөтенесен Әзһәм үз исәбеннән эшләтә.

Матур «кино» дәвам итә. Менә Әзһәм бергә укыган сабакташлары белән Сикиядә су керә, көймәләрдә йөзеп таңны каршылый. Менә ул авыл тарихы турында китап чыгару уе белән янып йөри. «Син язсаң, китапны үзем бастырам», – дип, авылдашы Әлфинурны ашыктыра...

Чигүле сөлгеләр белән бизәлгән кыңгыраулы атлар авыл урамнарын урый. Җаннарны актарып җыр яңгырый:

Сагынам сине, сагынам,
Туган авылым Үрәзмәт.
Сиңа кайтыр көннәремне
Саныйм берәм-берәмләп...

Үрәзмәт җыры! Әзһәм Хөсәенов авылдашларына бүләк ясаган: җыр яздырган! Шәмсия Җиһангирова шигырен Зөфәр Хәйретдинов көйгә салган. Җырчы Үрәзмәт Сабан туена махсус кунакка килгән! Әзһәм үзе дә җырга кушыла:

Ата-анам, әби-бабам
Нигез корган төбәгем.
Үзем читтә яшәсәм дә,
Синдә тибә йөрәгем...

– Әзһәм абый Үрәзмәттә йорт салды. Авылның визит карточкасы кебек ул. Кызыл кирпеч йорт, ак тәрәзә рамнары, алсу гөлләр... Ул авылны бик ярата иде шул!.. – Лилия, җырлы «кино»мны бүлеп, тагын бүгенгә кайтара.

Их, шул «иде»ләрне! Үкенүләр белән тулы ул, «кино»дагы матур кадрларны кискәли.

«Авылыбызның алтын баганасы иде», – дип искә алалар аны.

– 15 февральне – совет гаскәрләренең Әфган сугышыннан чыккан көнен ничек көткән иде! Быел сугыш беткәнгә 30 ел була дип, ашкынып, әзерләнеп йөрде...

Әфганчылар янына ашыккан Әзһәм, күчтәнәчбүләкләрен төяп, дулкынланып, тарихка кереп калган ул утлы көннәрне кабат йөрәге аша үткәрә-үткәрә, таң беленгәнче үк юлга чыгып китәр.

– 13 февраль. Минем туган көнем. Әзһәм абый кайда гына булса да, һәрвакыт иртәнге җидедә, «нихәл, апаем» дип, үзебезчә, Мөслимчә котлап шалтырата иде. Ә бу юлы соңарды: аның ягымлы, бик тә якын тавышын ишеткәндә сәгать көндезге 11 иде инде: «Нихәл, апаем? Туган көнең белән котлыйм! Ачуланма, җидедә шалтырата алмадым, биштә йокыңнан уятасым килмәде... Сәламәт бул. Үзеңне сакла. Яхшылыкларың өчен рәхмәт, апаем...» – диде. Мин ул сүзләрне ятлап бетердем инде...

Иртүк Әлкигә әфганчылар белән очрашырга китә... «Иртәгә – Зәйгә, аннан Чаллыга барабыз... Бу юлы Мөслимгә керә алмыйм инде. Башка вакытта күрешербез, Ләлә апа», – дигән әнигә дә. Дүртенче яртыда әни шалтырата: «Әзһәм абыеңны үлгән, диләр...» Әни шок хәлендә, ни ышанырга, ни еларга белми... Соңыннан Әзһәм абыйның температуралы килеш юлга чыгуын, очрашуда әфганчы дусларына бүләкләр тапшыруын, машинада шабыр тиргә батып кайтуын белдек. Табибларга күренәсе килмәгән, туп-туры өенә алып кайтырга кушкан шоферына. Ә өйдә инде дару белән су гына сорарга өлгерә...

– Юк, ул һаман арабызда сыман. Мин аны гел зәвык белән киенгән итеп күрергә гадәтләнгән. Кибетләрдә йөрергә, башкаларны сөендерерлек бүләкләр сайларга ярата. Баһадирдай ир-ат булса да, нечкә күңелле... Белмим, никтер һәрчак «Сөембикә» журналын яратып укый иде ул. Әлмәттә «Пятерочка» кибете киоскыннан гел «Сөембикә» журналлары сатып ала. Монысы да гаҗәп. Тагын бер зур хыялы була аның – дөнья күрү, илләр гизү. Хыяллары чынга ашты. Хәтта бакыйлыкка күчкәндә дә. Үрәзмәтендә соңгы юлга озаттык аны. Хушлашырга килүчеләр кырга сыймаслык иде...

...Лилия тынып калды. Ә минем хыял «кино»сындагы матур кадрлардан һич аерыласым килми. Аның болай моңсу тәмамлануын теләмим. Нишләмәк кирәк: тормыш бу, чынбарлык. Кеше китә, җыры кала, диләр. Әзһәт улы Әзһәмнең дә никадәр игелекле эшләре, якты эзе калды.

Ә Үрәзмәте бик сагына аны!..

PRESSA



ХЫЯЛЛАР – ЧЕЛЛӘДӘГЕ РӘШӘ

Резеда ГОБӘЕВА

***

Син хыял дип йөргән киңлекләр,
Какканда этәреп, кул селтәп,
Җыясың хатирә җепләрен,
Җыясың сак кына, бөртекләп...
Ә җепләр очында – зур төен,
Сапланмый энәләр төеннән,
Ямалмый яралар... Ә бәлкем
Ул шулай яхшыдыр, кем белгән?!.
Зур киңлек сулышны буганда,
Хатирә капчыгы – хуш кына –
Ишелеп төшкәндә хыялы,
Кешеләр үткәнгә ашкына...
Биклисең җаныңны зинданга.
Бер рәхәт – упкынга омтылу,
Газапның була үз ләззәте...
Юк чыгу, зинданнан котылу...
Юк дәва – сагыну зарыннан,
Сәгатьнең комында эре таш...
Борылма икән ул кирегә,
Борылма, инде бер оныткач...

Сагынам...

Еллар үткән саен туган якның
Таңнарына ныграк табынам!
Юлга таңда кузгалганга микән,
Шул таңнарны өзелеп сагынам...

Китәр юллар ашкындырган саен,
Хыял булып таңнар сызыла...
Сүнмәс утлар балкый офыкларда,
Кайтыр юллар һаман сузыла...

Бәхетләргә илтер юллар озын,
Ә хыяллар – челләдәге рәшә...
Киләчәккә чакыргандай итеп,
Үткәннәрдән сине кемдер дәшә...

Кемдер көтә гүя, кемдер эзли,
Таң чыгына манып күзләрен...
Бүгенгедән ерагайган саен
Кадерләре арта сүзләрнең...
Кадерләре арта кешеләрнең,
Үткәннәрдә калган көннәрнең...
Кайтмас язлар булып ярсый күңел,
Иңнәренә ятып көзләрнең...

Офыкларга таң шәүләсе төшсә,
Талпынам да, янә кабынам!
Юллар таңга тоташканга микән,
Туган якның таңын сагынам!

* * *

Рәхмәт сиңа, тормыш! Яңа көнең,
Айлы төнең, татлы сереңөчен...
Кырда шаулап үскән икмәкләрең,
Безне кеше иткән хикмәтләрең,
Маяк булып янар җырың өчен!..
Ташып торган сүнмәс яшәү көчем,
Таулар яулый алыр дәртле хисем,
Җанга якын газиз кешем өчен!..
Сикәлтәле озын юлларымны,
Сынауларга төреп җәйгән чакта,
Шул сынауны җиңәр сабырлыкны
Индергәнең өчен безнең хакка...
Рәхмәт сиңа, тормыш!
Шатлыкларың,
Табышларың, сагышларың өчен!!!
Без утырган көймәләрне
саклап кына
Чайкалдырган агышларың өчен!..
Язлар булып килгән Аккошларың,
Ак кышларың, алкышларың өчен!!!
Матур синең, матур һәрбер төсең!!!
Рәхмәт сиңа, тормыш, барсы өчен!

Балам

Мин бәхетнең күзләренә багам,
Кочагыма алам, иркәлим...
Бу дөньяның бөтен яме, гаме –
Синдә, балам, синдә икән бит!

Зур күзләрен ачып елмая ул,
Бар да әле аңа өр-яңа!
Үз-үзеңә бүләк ясыйм дисәң,
Бала тудыр икән дөньяга!
Әниләрне чынлап аңлыйм дисәң,
Ана булып кара икән ул.
Балаң өчен борчылулар гына
Тирән утка сала икән ул...

Бу дөньядан хаклык эзлим дисәң,
Дөреслекне үзең тудыр икән...
Синнән дә саф хаклык
бармы җирдә?! –
Күзләреңнән фәрештәләр үпкән...

Мин бәхетне кочагымда тоям,
Җавап итеп берни эзләмим...
Бу дөньяда синсез күпме гомер
Ничек кенә, ничек түзгәнмен?!.

* * *

Җир шарын икегә ярам да,
Бер ягын кисәмә яшерәм –
Иң садә чагымны дәлилләп,
Һәрдаим исемә төшерер...

Хисләрне бүләм дә икегә,
Яшерәм күңелем читенә...
Дисбегә тезелгән сәйләндәй
Яшерен хатирә сүтелә...

Гомерне икегә бүләм дә,
Тауларга яшерәм яшьлекне...
Без инде яшьлектән үткәндер –
Күзләрдә әрнүле яшь кипте...

Икегә бүленгән дөньяның
Үткәндә калганы кадерле...
Әйләнеп-бәйләнеп кайтырлык
Сагыну өзгәли бәгырьне...

САГЫШ БЕЛӘН БӘХЕТ АРАСЫНДА



Рифат СӘЛАХ

Кичке Казан

Казан гөрли.
Машиналар күче.
Бу агымнан качып булмады.
Каршы ала фонарь нуры белән
Ташу тулы Казан юллары...

Казан гөрли.
Язны ямьле диләр,
Тәрәзәдән матур тагын да.
Үзгәрешләр күз яшьләрсез булмый
Язларыңның тәүге таңында.

Казан гөрли.
Күпме язмыш монда
Бер урында кинәт туктаган.
Ә шулай да җанга илһам иңә
Кишерсары кичке утлардан.

Казан гөрли.
Ә авылда хәзер
Ташуларсыз килә язы да.
Кыр үрдәге кайта Казансуга,
Аккошы да, киек казы да.

Казан гөрли.
Безнең күңел бозын
Ярсу язы белән эретә.
Таң да туар тиздән урамында,
Ә әлегә безне төн көтә.

Кызым

Май аеның мең кояшы булып,
Бу дөньяга килдең син, кызым.
Өзелеп сине яратканым өчен
Берәр изге дога укырсың.

Күзләреңдә яшел нур бөркелә,
Йолдызлардан якты син бүген!
Мин яратам сине, бердәнберем,
Мин яратам сине, Сөмбелем!

Күзләреңне ачып, бу дөньяны
Күрүеңә әле бер сәгать...
Ә мин сине күрер өчен килдем,
Каршы тора алмас мең сәбәп.

Бик сагынып сине көтеп алдым,
Кулларыма алдым, и кызым!
Мин дөньядан киткәч, оныта күрмә,
Берәр изге дога укырсың.

* * *

Сөйгән ярым булалмадың, җанан!
Кызарыплар калды бит алмаң.
Синең яннан китеп бардым, ләкин
Хатирәләремнән киталмам.

Синең яннан китеп бардым, бәгырь!
Мәңге әрнер сагыш күңелдә.
Без, мөгаен, парлак дөньяларда
Бергә булыр идек, кем белә.

Без һичшиксез бергә булыр идек,
Башка төрле булса иманым.
Синең өчен мин имансыз, бәлки...
Үз кыйблама илтә юлларым.

Синең өчен мәхәббәтсездер мин,
Барыр юлым ерак, багалмам.
Синнән яхшыракны табармын күк,
Синдәйләрне ләкин табалмам!

Яз гүзәлене

Гүзәллеккә карап торган өчен,
Хак түләргә миндә юк алтын.
Аңлый алмыйм, ләкин тоеп торам –
Күзләреңдә нидер югалттым.

Гүзәллектә эреп югалырмын,
«Сөям!» диеп бер сүз дәш кенә.
Иртә язның тәүге чыгы сыман,
Күзләреңдә балкый яшь кенә.

Гүзәллегең, серле күзләреңнең
Бәһасенә мең җыр аз сыман.
Өмет кочагында калдыр мине,
Безне таныштырган яз сыман.

Сагынам...

Сагынам мин сине өр-яңадан...
Элеккечә түгел, башкача.
Син йөрегән эзгә юлыгам да,
Тик күзләрең миннән... Аһ, кача?

Синең арттан йөгерәсе иде,
Белсәм юлың каян үткәнне.
Әкияткә алып кайтыр идем,
Син сагыныр идең... Үткәнне.

Эх, күңелең синең!.. Сөя торып, –
Нигә мине утка ташладың?
Син булмагач, моң да, хисләр дә юк,
Мин башкача яши башладым.

Алларыңнан синең үтәр идем,
Китәр идем, әгәр теләсәң.
Бу дөньяда ничек яшим соң мин,
Синең яшәвеңне белмәсәм?

Яшел күзле яз

Язны эзлим... Түбәләрдә кояш,
Яз сулышын бөрки кояш үзе.
Бер сусаган чагым яшеллеккә,
Яз һәрвакыт була яшел күзле.

Алмагачлар тилмергәннәр язга,
Озак тормас, шытар яшел бөре.
Челтер-челтер тамчы тама өстән,
Сафландырмак булып яшьлегемне.

Күк түрендә фирүзәдәй болыт,
Наратларга тоташ яшел үзән...
Алмагачлар әрнеп миңа карый –
Ниләр көтә алар яшел күздән.

Чагылдыра кояш күзләремне.
Сагындыра офык, билгесезлек.
Язны эзлисеңдер...
Аңлыйм, аңлыйм:
Яз һәрвакыт була яшел күзле.





Гүзәл ӘДҺӘМ

ҮКСҮ

(Хикәя)

«Өянкеләр озак яши микән? Алтмыш... Җитмеш елмы? Әллә аның кебек туксан укмы?»

Һәдиябану карчык моны белми иде. Югары очтан төшеп килүче берәүне шәйләп алуга, өянке ышыгындагы утыргычка тагын да сеңә төште, кулындагы төенчеген кая куярга белмичә бәргәләнде.

«Йа Хода, сизеп алсалар, нишләрмен? Төенчекләр белән кая җыендың, дип сорасалар, ниләр дип җавап бирермен?»

Арык куллары болай да бәләкәй төенчекне тагын да кечерәйтергә теләгәндәй бөтерә-бөтерә күкрәгенә кысты. Нииндидер очлы каты нәрсә, чәнчеп, кабыргасына төртте. Карчык авыртудан чак кына кычкырып җибәрмәде. Шулай да түзде. Якынлашып килүченең сәламен алып, елмаеп җавап кайтарырга үзендә көч тапты:

– Аллага шөкер, олан, Аллага шөкер...

– Көне бигрәк кызу, Һәдиябану апа, май ае димәссең...

– Ие, олан, ие...

Аңа тагын нидер әйттеләр, ул тагын җавабын бирде, куллары исә күкрәкне чәнчегән теге әйберне һаман капшады, кармалады.

«Ни булыр бу? Төенчеккә ике күлмәк белән берничә яулык кына сыйган иде бит югыйсә».

Дөрес, аның күлмәкләре әле тагын да бар, алъяпкыч-яулыклары да җитәрлек, тик бүгенге мәхшәрдә алар турында уйларга вакыты да, теләге дә юк иде карчыкның. Бөрешкән бармак битләре белән теге каты нәрсәне капшады да капшады. «Ни микән ул?» Кинәт, зиһене ачылып, күңеле күтәрелеп китте.

«Гарифҗанның ордены лабаса! Кызыл Йолдыз ордены!»

Инде бармаклары тукыма аша шул орденны иркәләде.

«Зәңгәр чәчәкле күлмәгенең түш кесәсенә салган иде лә. Хәтердән чыгуын күр инде».

Кинәт йөрәге өшеп киткәндәй булды, аннан дөпелдәп тибәргә тотынды.

«Ә медале?.. Медале кайда соң?»

Ашыга-кабалана тагын капшады. Хәлсез бармаклары түгәрәк тимерне эзләп тапкач кына күңеле тынычланып, бушанып калды.

...Күкрәгенә орден-медальләр тагып, Гарифҗанның сугыштан кайткан чаклары хәтерендә яңарды. Үзәкне өзгеч моңсу хатирә, йөрәкне телеп, күзне яшьләндерде. Сытылып кына чыккан сыңар күз яше җыерчыклар арасында буталып адашты. Карчык, үзалдына пышылдап, күңел түрендәге шул берәүгә дәште:

– Га-риф-җа-а-а-а-а-н... Ишетәсеңме мине?

Әллә карчыкның колагына гына шулай ишетелдеме, карт өянке ыңгырашып, уфылдап җавап кайтарды.

Бар иде, бар иде бит аның да яшь, сылу чаклары! Бик күптән, кайчан икәнлеге буталырлык ерак елларда, шул өянке төбендә, төенчеген кочаклап, Гарифҗан белән янәшә басып тордылар... Шахтер Саматка кияүгә бирергә җыенуларын сизгәч, Һәдиябану егеткә ябышып чыккан иде...

– Әйдә, керик инде, Һәдиябану...

– Уңайсыз бит, Гарифҗан... Оялам...

– Нигә ояласың, оялма. Янында мин ләбаса.

– Әллә ничек шунда... Ябышып чыгу оят икән... Комсомолка башым белән, җитмәсә...

– Алайса, ябышып чыкканыңны әйтмәбез. Урладым, диярмен...

Кыз йомшак кына көлеп куйды:

– Ышанмаслар шул...

– Нигә?

Кыз, егеткә сыена төшеп, тагын көлде.

– Син шундый зур булсаң да, бигрәк кыюсыз ла...

– Нәрсә?

Егет кызны төенчеге-ние белән күтәреп алды да чытырдатып күкрәгенә кысты:

– Уенга төшкән җиреннән урладым да кайттым, диярмен.

– Төенчеге беләнме?

Кызның кулындагы төенчеккә шунда гына игътибар иттеләр. Икесе дә көлеп җибәрде. Егет җитез генә төенчекне өянкенең куе ябалдашлары арасына яшерде.

– Әлегә шунда ята бирсен...

Аннары Һәдиябануны кысып-кысып кочаклады. Икесе дә бик яшь, үбешә дә белмиләр иде әле...

Донбасстан күп акчалар эшләп кайткан «бай кияү»гә бирергә әтисе ни хыялланса да, планнары барып чыкмады. Шулай да карт тавышланып-нитеп йөрмичә генә ризалашты: кияүнең монысы да таза тормышлы һәм эшчән иде.

Әнә шулай яшәп киттеләр. Һәдиябану Гарифҗанны яратып торды. Бер дә аерылмаслар, мәңге шулай булыр кебек тоелган иде. Сугыш чыккан елны тупырдатып ике малай сөяләр иде инде...

...Ай, гомерләр... Аккан су икән лә... Гарифҗан вафатына да күпме еллар үткән ләбаса... Уллары да... Ә ул һаман яши. Инде туксанын тутырып килә.

... – Күлмәкләреңне җый да сыпырт моннан! Кеше карау яшем күптән чыккан инде, үземне дә караучы кирәк! Әнә яраткан килененә бар! Бераз ул тәрбияләсә дә ярар...

Килене Нәҗия йөзенә бәргән яулык-күлмәкләрен җыеп, тизрәк чыгып китәргә ашыкты ул. Тегесе исә аның саен төрткәләде:

– Әйдә, әйдә, атла! – дип, йодрыкларын тырпайтып, ишеккә этте. – Бар, әнә, яраткан киленең белән тор!

...Утыргычка чыгып утыруына күпме булды икән? Бер сәгатьме? Әллә ике үкме?

Карчык Нәҗиянең тынычлануын көне буе көтәргә дә риза анысы.

«Тузыныр, тузыныр да бер тынар әле. Элеккечә ягымлы ук булмаса да, чәй эчәргә дәшәр».

Һәдиябану карчыкның үтереп-үтереп чәй эчәсе килә башлады. Авыз эче дә кисәк кибеп китте, ахры, телен көчкә әйләндереп, кипшенгән иреннәрен чәпелдәтеп куйды. Карты Гарифҗан белән самавыр янында кара-каршы чәй эчүләр үзәкләрне өзеп хәтердән узды.

«Дәшмәве, чакырмавы булды, ахры...»

Ә күңел ышанмады, һаман көтте дә көтте.

Карчык уянып киткәндәй булды, як-ягына каранып алды да төенчеген карт өянке куышына атты.

«Шунда ята бирсен. Килене тынычлангач, бер чыгып алыр әле. Өйдән куганнарын күрше-күлән күрә, сизә күрмәсен! Ояты ни тора! Улы Шәрифҗан исән булсамы?! Һәдиябану карчыкны түр башында гына утырта иде дә... Кисәк китте шул Шәрифҗан, бигрәкләр кисәк булды. Әле алтмыш бишен дә тутырмаган иде... Бу гомер дигәннәрен Аллаһы Тәгалә нигә шулай бүлә икән? Берәүләргә үкенерлек дәрәҗәдә аз бирә дә, ә Һәдиябану кебекләргә – кеше үзе дә туярлык күп итеп... Якыннарың китеп беткәч, яшәүләрнең ни яме дә, ни фәтуасы кала соң?!»

Карчык, оеган тәнен язып, кымшанып куйды. Карт сөякләре шыгырдап ыңгырашып алды.

Гарифҗанын хәтерләгән йорт-җир инде күптән юк. Улы Шәрифҗан капка-кура, сарайларны да өр-яңадан төзегән иде. Йортны да калай түбәләрен буяп, тәрәзә наличникларын сырлап-бизәкләп эшләде. Барысы да өр-яңа... һәм ят иде. Теге, үзе килен булып төшкән йорт күпкә кайтыш булса да, күңелгә якынрак иде шул. Әле ярый хатирәләргә бай карт өянке исән: карчыкны ышыклап, күңел юанычы булып тора. Тукта-тукта, онытып җибәргән түгелме соң? Капка баганасына кадакланган тимер чылбыр Гарифҗанныкы лабаса! Әйе, әйе, шул чылбыр! Нәҗия килен карышыпматашты маташуын, имеш: «Өр-яңа капка баганасына күгәреп беткән чылбыр такмасаң!» Улы томырылып бер генә карады: «Әти истәлеге!» Гомер буе атлы эштә йөргән Гарифҗаны әбәткә кай-



тыр иде дә, дилбегә кыршавын шул чылбырга эләктереп куяр иде. И-и-и-и, яратты да соң малкайларны ире! «На-а-а-а!» дип дәшүенә кадәр башкаларныкыннан үзгә, ягымлы, җылы иде аның.

Теге сыңар яшь тагын күздән сытылып чыкты...

Икенче улы Салихҗаны искә төшкәч, карчык кеткелдәп көлеп куйды. Анысының өйләнүләре бик матавыклы булып чыкты, тик ул чактагы борчулары хәзер татлы төш кенә булып тоела.

...Һәдиябануның чишмә суыннан кайтып килеше иде. Берәү ашыга-кабалана артыннан куып тотты. Кем дисә – югары очның Шәмси кызы Сәвия икән. Кызый бик каушаган, күзләре дә кызарган, әллә нинди мескен, калтыравык тавыш белән аңа дәште:

– Һәдиябану апа...

Ананың йөрәге дертләп куйды. («Йа Ходай, хәерлегә генә булсын!»)

Кызый түбән карап сулкылдады да сулкылдады:

– Зинһар, тыңлый күр...

– Йә, сөйлә инде. Ни булды?

– Салихҗан...

Кыз тагын үкседе.

– Йа Аллам, әллә Салихҗаныма бер-бер хәл булдымы? Кайда ул?

– Юк... булмады... – Кыз тотлыкты. – М-м-мин – авырлы...

Һәдиябану Салихҗан белән Сәвиянең озатышып йөрүен белә иде. Кыз бераз җилбәзәгрәк булса да, аның килен булу ихтималы белән ана күңеле күптән ризалашкан иде инде.

«Менә сиңа яңалык! Аның ипле, итагатьле Салихҗаны ни майтарган бит!»

Ул көнне алар яр буенда шактый озак утырдылар. Кыз үкси-үкси үз кайгысын сөйләде. Хәбәрне ишеткәч, Салихҗанның кыздан качып йөрүе, ә туачак сабыйга инде җан керүе дә билгеле булды.

Һәдиябану үзе ике малайдан соң кыз да табармын дип бик өметләнгән иде. Сабыена нинди исем кушу, чәчләрен нинди тасма белән үрү, күлмәкләрен ничек тегүгә кадәр уйланылып, хыялда кат-кат яңартылып килде. Тик көтелгән кыз бәби генә тумады. Сугыш чорында ир-ат хезмәтен җигелеп тартудан имгәнеп калуын Һәдиябану шунда гына төшенде. И-и-и-и, авыр да булды соң! Бөтен күрше-тирә җиде-сигез бала үстергәндә, алар гына ике угыл белән утырып калды. Ул чакта инде Һәдиябану үзе дә тынычланып, күңелдәге матур хыялын бик-бик еракларга яшереп куйган иде.

Бу хәбәрдән имәнеп китте. «Ничек? Аның улы Салихҗанмы шундый миһербансызлык күрсәтә? Булмас! Кыз баланы шулай рәнҗетергә ярыймы?»

Һәдиябану улы Салихҗан белән ни сөйләшкән дә нәрсә әйткән, болары сер булып калды, тик шунысы ачык: ике атнадан йортка килен төшерделәр. Өлкән улларының да әле яңарак кына Нәҗиягә өйләнеп яши башлаган чагы иде. Ата кеше күп уйлап тормады, бакча башында үз чиратын көтеп утырган мунчакеләт бураларын берләштереп, каршыдагы буш нигездә Салихҗан өчен җыйнак кына йорт торгызды. Яшьләр, башка чыгып, күрше булып яши башлады.

Ике йортта да бер-бер артлы балалар туды. Һәдиябану белән Гарифҗан шуларның чыр-чуына, очсыз-кырыйсыз мәшәкатьләренә чумды.

...Гомернең иң-иң рәхәт чаклары шул елларга туры килә бугай.

Кара-каршы ике йортта җиде малай-оның үсте. И-и-и-и, аларның шуклыклары, уенчак мәзәкләре, җор телләре! Җәен йокы урыннары печәнлеккә җәелгән булыр иде дә, караңгы төшкәч, ике килен, кармалана-кармалана, йокы симерткән балаларын барлап йөрер иде:

– Нәҗия-я-яү... Миндә бүген – ик-ә-ә-әү-ү-ү генә-ә-ә-ә! Синдә ничә-ә-ә-әү? – дип, урам аша күрше йорттагы килендәшенә дәшәр иде.

– Би-шә-ә-әү!– дип аваз салыр иде тегесе...

Һәдиябану гомер буе киленнәренең татулыгына куанып яшәде. Киленнәр, үзара дошманлашып, ике бөртек баламны аера күрмәсеннәр, дип, кат-кат теләкләр теләде. Ул чакта киленнәрнең серләре килешә иде, дуслыклары да көнләшерлек булды. Хәзер генә дөньясы әллә нишләп китте шунда. Бер-берсенә йөрешмиләр, керешмиләр, кычкырышырга-талашырга гына торалар. Әллә дошманнарның күзе тиде, әллә берәрсе бозды укмы?

Оныклар үсеп, бер-бер артлы калага китеп урнаша барды, шунда гаилә корды. Башта Гарифҗан, аннан Шәрифҗан белән Салихҗан да дөнья куйды. Патша сараедай ике йортта өч карчык кына утырып калды.

Менә шунда башланды инде Һәдиябану өчен дөньяның мәхшәре. Ике килен бер карчыкны бүлешә алмый изаланды:

– Сине мин карарга тиеш түгел! – дип, икесе дә разбой салды.

Нинди карау ди! Әлегә, Аллага шөкер, Һәдиябану үз аягында. Яше туксанда булса да, киленнәргә бер мәшәкате дә тими, үз артыннан үзе җыеп, үз керен үзе уа. Өйдән куылып, менә шулай капка төбендә утыруларның йөрәген ничек телгәләгәнен берәрсе аңлый микән аларның?

...Кояш кызуына түземе бетте Һәдиябануның. Өй ишегенең эчтән бикле булуын тагын бер кат барлагач, кыштыр-кыштыр сөйрәлеп, урам аша каршы йортка юнәлде. Анысының капкасы ук эчке яктан терәүле булып чыкты.

– Сәвия, Сәвия дим... Кызым, керт әле мине... Ач капкаңны...

Теге якта дәшмәделәр. Кат-кат инәлгәч кенә кече килен аваз бирде:

– Нәрсә? Яраткан киленең кудымы? Мин үзем дә карчык инде, сине тәрбиялисем килеп тормый әле...

«Йа Ходай, бу шул Сәвияме соң?»

«Аяк астында туфрак булырмын, зинһар, мине кире какма! Салихҗан белән кавыштыра күр. Баланы ятим итмик...» – дип ялваручы алданган кыз үземе?»



Рәсем: Наталья Васильева

Ул чакта Һәдиябану аны җитәкләп җирдән торгызды, чәчләрен сыйпап юатты. Соңыннан исә бер генә тапкыр да бу халәтен килененең исенә төшермәде, «корсак белән чыктың» дип битәрләмәде. Оныткан, барысын да оныткан Сәвия. «Син миңа үз әниемнән дә якынрак! Мәңге онытмам!» – дигән антларын да хәтереннән җуйган. Әллә хөсетлек, комсызлык кебек явыз көчләр күңел түрендәге бөтен изгелекне шулай оныттырып, кысрыклап, куып чыгарамы икән?

Карчык ыңгырашып куйды. Тәрәз төбендәге яраннары белән балкып утырган кара-каршы ике йорт Һәдиябануның болай да лепердәп кенә торган йөрәген дөмбәсли-дөмбәсли кыса, сыта башлады. Ул инде бу йортның утыргычына чүмәште, тагын да бөрешеп, кечерәеп тынып калды. Әлҗе-мөлҗе килгән күзләрен каршы яктагы карт өянкегә төбәп, карты Гарифҗанга дәште:

— Гарифҗа-а-а-ан... Никләргә калдырып киттең мине? Бәхетле кеше туксанга кадәр яшиме-е-е?..

Тузан туздырып килеп туктаган машинадан кем төшкәндер, карчык анысын абайларлык хәлдә түгел иде. Күп тә үтмәде, килене Нәҗия җил-җил атлап аңа якынлашты.

– И-и-и, әнкәй җаныкаем! Күпме утырырга була капка төбе саклап. Әйдә, әйдә, өйгә кер. Әнә анда Инсаф улың тәмле җимешләр алып кайткан. Чәй эчәсең дә килеп беткәндер инде...

Килендәше тарафына утлы карашын атты да, Һәдиябануны җилтерәтә-җилтерәтә алып кереп тә китте. Вакыйганың ничек тәмамланасын койма ярыгыннан күзәтеп торган Сәвиясе исә берни аңламыйча калды.

Карчык үзе өйгә кергәч тә, күкрәген тотып, карават читенә сөялү җаен карады, Инсаф белән Нәҗиянең сүзләренә бөтенләй колак та салмады.

Тегеләре:

– Сугыш ветераны... Квартира... Ветеран хатыны... Безгә тиеш... – дип, ни турындадыр кызып-кызып бәхәсләште.

...Ә Һәдиябану исә, Гарифҗаны белән җитәкләшеп, ап-ак чәчәкле яшел болын буйлап атлады да атлады. Ул арада аяклары, җирдән аерылып, зәңгәр болытларга уралды. Алар, бер-берсенә сыенышып, өскә, һаман югарыга күтәрелде...

...Капка төбендәге карт өянке генә үксеп калды...



Кадерле «Сөембикә» редакциясе!

Безнең Хәсән бабай сугыш турында сөйләргә яратмады. Сугыш турындагы фильмнарны караганда да күзләренә яшь тулуын соңыннан әбием Әминә генә белдерде. «Анда болай түгел иде», – дип әйтә торган булган ул.

Ә ничек булган? Боларын инде ул безгә беркайчан да сөйли алмас. Кызганыч...

Хәзер теләге булган кешегә туганнарының тарихын белү өчен мөмкинлекләр бар. Без дә гаиләбез белән вак-вак кыйпылчыкларны бер җепкә тезеп, Хәсән бабабыз узган юлларны барларга тырыштык. Бездә аның хәрби билеты, кызылармеец таныклыгы, медальләре саклана.

Сугышка тәүге тапкыр Белоруссия фронтында керә ул. Моны Бүләкләү кәгазендәге бер юл раслый: «1943 елның 15 маеннан Ватан сугышында катнаша, 1 нче Белоруссия фронты». Шушы ук елның 20 октябрендә беренче хәрби бүләккә – «За боевые заслуги» медаленә лаек була.

1944 елның 31 июленнән 1 нче Белоруссия фронты Варшаваны дошманнан азат итү өчен хәлиткеч көрәшкә күтәрелә. Шәһәр 1945 елның 17 гыйнварында гына тулысынча азат ителә. Бабам «Варшаваны азат иткәне өчен» медале белән бүләкләнә. Соңрак аңа Берлинны алган һәм Бөек Ватан сугышында җиңгән өчен дә медальләр бирелә. Ләкин иң кызыгы әле бу түгел, Хәсән бабам вафатыннан соң 18 ел үткәч, Оборона министрлыгының үзәк архивында без бер документка тап булдык. Ул – Хәсән Галиевның Кызыл Йолдыз орденына лаек булуы турындагы Бүләкләү кәгазе. Анда 1 нче дивизия командиры капитан Смирнов бабам хакында менә ниләр яза: «В боях за нашу Родину проявляет образцы мужества и отвагу. Особенно отличился в боях за город Берлин с 28.04.1945 по 2.05.1945 годы. Батарея была выдвинута на прямую наводку и подвергалась сильному воздействию пулеметного огня. На батареи иссякали снаряды и требовалось быстро подвезти их на огневую позицию. Товарищ Галеев вдвоем с шофером, рискуя жизнью, под обстрелом подвезли снаряды и сгрузили их».

Кызыл Йолдыз ордены – зур бүләк. Аны Ватанны яклаганда зур батырлыклар күрсәтүчеләргә генә бирәләр. Ә бит бу батырлыкны бабам кыла да алмаска мөмкин иде... Сугыш башлангач, ул Суслонгерга эләгә. Кара урман эчендәге бу җирләрнең кара серләре әле күптән түгел генә ачыла башлады. Монда сугышлар узмый, ләкин бу урман – фронтның алгы сызыгында көрәшергә тиеш булып та, анда кадәр барып җитә алмаган тулы бер батальон солдатның мәңгелек йорты. Ачлыктан, суыктан, имгәнүләрдән һәлак булган бу солдатлар әле бүген дә хәбәрсез югалганнар сафында. Безнең бабай да шушы мәхшәргә килеп эләгә. Моннан исән котылуның бердәнбер юлы – качу гына икәнен тиз аңлый ул. Тирә-якны һәм качу юлларын башта җентекләп өйрәнә. Тотылса, җәзаның үлем генә буласын да аңлый. Алай да бер төнне тәвәккәлли. Төнлә юлда булып, көндезләрен печән эскиртләренә, урманнарга качып кайта-кайта, туган авылына кадәр җәяүләп 300 чакрым юл уза. Яңа Чаллыга таң алдыннан кайтып җитә ул. Туган йорты кул сузымында гына булса да, караңгы төшмичә авылга керергә ярамаганын белә бабам. Төн җиткәнне авыл зиратында сабыр гына көтә. Как сөяккә калган улын күреп, Кәшифә әбием телсез кала. Берсән, баласының шушы хәлгә төшүе котын ала; икенчедән, дезертирларны 25 еллык төрмә яки штраф батальонында үлем көтә ул чорда. Әмма бабамның нияте өйдә качып яту булмый, ул фронтка ыргыла. Улын ашатып, урын җәеп яткыргач, Кәшифә әбием авыл советына юнәлә. Барысын да ничек бар шулай сөйләп бирә. 15 кешене сугышка җибәрүләрен сорап, Әлки райвоенкоматына наряд килгән көн була ул. Өр-яңа доку-

ментлар ясап, авыл советы рәисе бабамны да шушы исемлеккә яза. Ул фронтка китә. Аның хәрби бүләкләре илебезнең Җиңү таңын арттыру өчен никадәр күп көч куйганын сөйләсә дә, Суслонгер турында ул беркайчан да онытмады.

Ирада ФАЗЫЛОВА.
Казан шәһәре.

Сүриядә сугыш башланганчы, ирем Фәрһад хәзрәткә анда ике мәртәбә белем алырга туры килде.

Димәшкъ (Дамаск) шәһәрендә Вәли исемле бер татар карты яши икән. Бездән барган татар шәкертләре һәрвакыт аның хәлен белешә торган булганнар. Ике баруында да Фәрһад Вәли бабайда кунакта була. Бабай аңа үзенең гыйбрәтле язмышын сөйли. Мин дә белгәннәремне, ишеткәннәремне сезгә җиткермичә тынычланмам сыман.

...Илдә колхозлашу башлана. Вәлинең әтисе Зәкиулла абзый Һидиятуллин таза тормышлы була. Колхозга керәсе килми. Ләкин ул чагында сорап тормаганнар, телисеңме-теләмисеңме – чыгар да бир! Аларның да мәҗбүри рәвештә бер сыерларын колхозга алып китәләр. Бичара мал, күнегелгән гадәт буенча, көтүдән элеккеге хуҗасына әйләнә дә кайта, әйләнә дә кайта... Урамда сыеры мөгри, өйдә сыерны кызганып балалар елаша. Аннары хәлләр тагын да мөшкелләнә. Башка хайваннарын да китерергә кушалар. Көннәрдән бер көнне дуслары: «Зәки, сине үтерәчәкләр», – диләр. Зәки бик тәвәккәл кеше була. Тиз генә хатынын, өч баласын (Вәлигә – 15 яшь, Әминәгә – 8 яшь, Кәримгә 4 яшь була) алып, «күрше авылга кунакка барабыз», дип чыгып китә. Дөресрәге – качалар. Зәкинең күрше рус авылындагы бер дусты боларны поездга утыртып җибәрә.

Богырысланда туганнары була, башта шул якка таба китәләр. Мең бәлаләр белән Азәрбайҗан якларына җитәләр. Бакуда Зәкине төрмәгә ябалар. Алай да Алланың рәхмәте белән төрмәдән котыла ул. Инде хәзер бик саклык белән генә Төркия ягына качу юлларын белешәләр. Күп кыенлыклар күреп, эзәрлекләүләрдән кача-кача, Төркия чигенә килеп җитәләр. Казаклардан качканда, Әминә биек ярдан тәгәрәп төшә. Аның артыннан әти-әнисе, абыйсы, энесе йөгерә. Арттан атлы казаклар куа килә. Әтиләре, елыйелый, баласының җансыз гәүдәсен күтәреп, бу явызлар илендә калдырмыйм, теге якта җирләрбез, дип аркасына аса да, ашыга-ашыга салкын тау елгасы аша бата-чума аргы якка чыгалар. Атлы казаклар мылтыклардан ата-ата килеп җиткәндә, гаилә Төркия ягына чыккан була инде. Сүгенеп кычкырган тавышлар ишетелә. Әмма атарга ярамый, чөнки алар чит ил җирендә. Кая күмәрбез, дип, аркага аскан баланы сүтеп җибәрсәләр, бала аңына килә. Кочаклашалар, елашалар. Бу – Төркиянең Әрзурум җирләре булып чыга. Аларны бик җылы каршы алалар, җир, сыер бирәләр. Тормышлары җайланып китә. Төрекләр дә үз итә. Ни дисәң дә, мөселман кешеләре бит! Зәкинең гаиләсе дини була. Балалар барысы да Коръән өйрәнә, намаз, уразаны калдырмыйлар.

Төркиядә бераз яшәгәннән соң, дин ирегенә кысынкылык килгәч, Зәки Димәшкъ шәһәренә барып урнаша. Аннары гаиләсен дә үз янына алдыра. Ул вакытларда Сүрия яшәр өчен дә, дин белеме алыр өчен дә бик бәрәкәтле ил була. Кызлары Әминә тиз арада Коръәнне яттан өйрәнә, аны тарикатьче, зур галим, милләте белән төрек булган Шейх Мөхәммәт Назыйм әл-Хакканига кияүгә бирәләр. Ире белән дөнья буйлап бик күп конференцияләрдә, җыелышларда катнаша. Үзе дә күп китаплар авторы.

Вәли бабай чиста итеп татарча сөйләшә. Хатыны – төрек. Әмма өендә бер бүлмәне татар бүлмәсе итеп ясаган, самавыры тора. Әнисенең тәмле-тәмле ризыклар пешерүен хәтерли. «Кайсы яктан булдылар икән алар?» – дим иремә. Ә ул сорашмаган. Самара ягыннандыр, дип фаразлыйм. Анда тимер юл якын. Туган ягым Мөслим ягыннан булса, бер якка да китә алмаслар иде, дим. Бигрәк тә безнең Баек авылыннан. ...Һәм ни дип уйлыйсыз, Вәли бабай – минем авылдашым, Баек авылыннан булып чыкты.

Әминә хаҗия 2008 елның 16 ноябрендә вафат була. Вафатына кадәр балаларына туган авылы Баектан бер уч туфрак алып кайтып, каберенә (Кипрда яшәп, шунда җирләнә) салырга васыять итеп калдыра. Әнисенең соңгы васыятен үтәргә дип, улы Мехмет Әдил Баекка кайта. Шунда мәгълүм була да инде Зәкиулла Һидиятуллиннар гаиләсенең тарихы.

Вәли бабайның әти-әниләре Сүриянең Димәшкъ шәһәрендә шактый озын гомер кичерәләр. Әтисе Зәкиулла – 93 яшенә җитеп, әнисе Гайшә 82 яшендә вафат була. Вәли бабайның хатыны, әйткәнемчә, төрек – Бурса шәһәреннән. Аларның 4 баласы, 25 оныгы бар. Сеңлесе Әминә хаҗия турында әйттек инде: ул – ислам дөньясында танылган кеше, «Белем яктылыгы» («Свет знания»), «Мөхәммәд – ислам илчесе» («Мухаммад – посланник ислама») дигән китаплар авторы... Гарәпчә, төрекчә, инглизчә камил белгән. Алар ике ул, ике кыз үстерә. Кипрда зур бакчалы, затлы агач өйләре бар.

Энесе Кәрим турында әллә ни мәгълүмат юк. Авыр заманнарда җаннарын, диннәрен саклау өчен һиҗрәт кылган авылдашларыма Аллаһы Тәгалә оҗмахта юаныр дәрәҗәләр бирсен!

Рушания МИНСӘГЫЙРОВА.
Спас районы.

Хөрмәтле укучыларыбыз!
Сездән хатлар көтеп калабыз.
Безнең адрес: Казан, Декабристлар урамы, 2.
e-mail: ssuum@yandex.ru



ФЕЯЛАР ҖИРДӘ ЯШИ

Лилия
ГӘРӘЕВА

«Белоснежка һәм җиде гном» әкиятен укыганың бармы? Андагы гномнарны хәтерлисеңме? Менә минем дә бабам шундый гном булган». Үзенә текәлеп карауларына ул аптырамый. «Ә син ник шундый?» – дип сораучыларга әнә шушы әкиятне сөйли.

«Кызым, – ди аңа әнисе, – син беркайчан да балаларга һәм юләрләргә үпкәләмә. Юләрләр алар авыру, ә балалар – кызыксынучан, алар сине беренче тапкыр күрә».

Җаны ачыла барган саен, Регина миңа тагын да якыная, матурлана, эчке нуры күзләренә күчә дә, бәхет булып елмая. Ул – бик бәхетле.

Бәхет... «Сез бик яшьләр, икегез дә – кеше арасында. Ул йөри дә алмаячак, акылы да сау булмас, калдырыгыз». Яңа гына авырыннан котылган яшь ананы табиблар баласыннан баш тартырга үгетли. Монда берәү дә гаепле түгел, табиблар хатасы да түгел бу. Кәрләлек – ничәнчедер буында кабатланучы генетик тайпылыш. «Кем белә, бәлки, минем бабам чынлап та гном булгандыр? Дөньяда, бәлки, шундый раса да яшәгәндер», – Регинаның бар нәрсәгә әнә шулай юмор белән, могҗизага бәйләп каравы сокландыра. Сокландыра да, уйландыра да.

Саба районының Иштуган авылында яшьтәшләренең атаманы булып үсә Регина Иванова. Әйе-әйе, теге вакытта табиблар, йөри дә, сөйләшә дә алмас дигән кыз үзе инде бу. Балаларны җыеп, урманга кем алып киткән – ул, билгеле. Балык сөзәргә дип елгага барырга да ул котырткан... «Кызым, мине мәктәптә бөтен кеше тыңлый, бары син генә тыңламыйсың», – дип битәрли аны мәктәп директоры булып эшләүче әтисе Рафаэль Федорович. Нишләсен соң, урманболыннарны ярата шул Регина. Әнисе – биология һәм химия укытучысы Светлана Юрьевна һәр үсемлек, һәр бөҗәк, кошлар, җәнлекләр турында шундый мавыктыргыч итеп сөйли, ул бөҗәкләрне табып, дусларына да күрсәтәсе килә.

Аларның гаиләсендә бар да укытучылар: әтисе дә, әнисе дә, әби-бабайлары да... Эштә түгел, өйдә дә бер-берләренә исем белән генә дәшү юк – «Светлана Юрьевна», «Рафаэль Федорович»... Әтисенең әнисе Кәүсәрия Гарифуллина – Татарстанның атказанган укытучысы, Шәмәрдәндә яши. Ә әнисе ягыннан бабасы Кайбычтагы акылга зәгыйфь балалар интернаты директоры, үзе тарихчы була. «Бик миһербанлы, үзенчәлекле кеше иде. Матур итеп гармунда уйнады. Ул уйный, мин биим. Әкиятләрне ничек кызык итеп сөйли иде... Минем әле дә әкияткә ышануыма ул «гаепле» – бабасы турында күңелендә иң матур хатирәләр яши Регинаның.

Безнең мөмкинлекләр чикле түгел,
ихтыяҗларыбыз гына зуррак.

«Ник син Иванова?» – аңа бу сорауны да еш бирәләр. Мөселманча киенеп, татарча сөйләшеп йөргән кызның Иванова фамилияле булуы гаҗәпләндерә татарлар турында мәгълүматы азларны. Укытучылар гаиләсендә генә түгел, чып-чын интернациональ гаиләдә дә үскән кыз әле ул. «Әтинең әнисе Кәүсәрия әбием – татар хатыны, бик дини кеше безнең. Ә бабам Федор – керәшен татары. Иванова фамилиясе бездә аңардан. Ә менә әнием ягыннан әбием – рус милләтеннән, православ динендә. Бабам исә яһүд иде. Бездә беркайчан да кайсыдыр милләтне яки динне өстен чыгару булмады. Әни Кәүсәрия әбиемне бик хөрмәт итте, ул кунакка килсә, иконаларны алып куя иде», – ди әңгәмәдәшем. Регина үзе дә уразасын да тота, гарәпчә укырга өйрәнү теләге дә бар.

Без аның белән узган ел «Татарстан энҗесе» конкурсында таныштык. Җиңү таҗы киде Регина. Балтач егете Рәдис Сабиров белән парлы бию биегәннәре әле дә күз алдында. Матур пар иде алар. Регина – чын әкият кызы, Рәдис исә чын джентльмен... Әллә бер гаиләме, дип пышылдаштылар янымда утыручылар. Рәдис белән алар яхшы дуслар. Гомумән, дуслары күп Регинаның. Мин аның бәләкәй буйлы кешеләр җәмгыяте оештырырга хыялланганын, шундый биш кешене инде тапканын да беләм. «Кешеләр үзләре миңа тартыла», – ул шулай ди. Кайда гына булса да, сез аның ялгызын гына күрмәссез. Боек чагын да очратмассыз. «Миңа үзем булу ошый. Мин язмышка рәхмәтле», – бу аның, буе метрдан чак кына артык булган кызның сүзләре. Әйе, бue бәләкәй аның, ә менә йөрәге-е!!! Оптимистлыгы!!! Тормышны, кешеләрне яратуы-ы!!!

Регина – «Иман нуры» мәчетендә эшли. Мин аның инстаграмдагы сәхифәсен карап барам. Иң өскә: «Фея Регина үзеннән ярдәм көткәннәргә булыша алуына шат» дип язып куелган. Әнә ул күп балалы гаиләләргә азык-төлек илтә. Фото астына болай дип язган: «Фея бүген тагын гаиләләргә ярдәмгә ашыга. Кунакка йөрергә һәм кешеләрне шатландырырга ятам. «Болар барысы да безгәме? Шундый күп!» дигән сүзләрен ишеткәч, кибетләрдә чират торулар да, алган әйберләрне һәрбер гаилә өчен аерым-аерым капларга тутырып, шәһәрнең бер очыннан икенче очына ашыгулар да онытыла». Әнә алар – мәчет хезмәткәрләре, волонтерлар Корбан бәйрәмендә мохтаҗларга күчтәнәч тарата: «Өч көндә 700 гаиләгә ярты тоннадан артык корбан ите өләштек. Мәчеткә ярдәм итүчеләрнең барысына да рәхмәт белдерәбез. Илаһым, барысы өчен дә рәхмәт сиңа». Әнә алар бер төркем балалар белән «Әкият» курчак театрында яисә концертта. Балаларның йөзләрендә – шатлык. Бу мизгелдә алар авыруларын да, сызлануларын да оныткан.
Сез дөрес аңладыгыз, Регина янәшәсендәге балалар авыр язмышка дучар булучылар. Бәләкәй феяның бар тырышканы да шушы сабыйларның тормышына аз булса да яктылык, шатлык, сөенеч алып килү бит инде. Фея дигән исемне аңа балалар үзләре кушкан.
Ә феялар гел яхшы гына булалар. Мәчеткә килүче балаларның иң якын дусты ул. Кесәсендә күчтәнәче, бүләге, планшетында кызык мультигы гел әзер алар өчен. «Кечкенә буйлы булгач, алар мине үзләренеке дип саный. «Син үзең зур, ә үзең кечкенә», – ди-

Фото: Анна Арахамия

Язмыш сиңа лимон бирә икән, син аннан лимонад ясарга тырыш.



■ «Балтач егете Рәдис Сабиров – чын артист һәм бик яхшы дус», – ди Регина.

■ Яшәү ямен тояр өчен күп кирәкми. Сабыйларны ихластан шатландыру да җитә.



ләр», – дип көлә Регина. Әле күптән түгел генә интернет сәхифәсенә бер малай белән төшкән фотосын урнаштырды. «Кешенең матурлык сере» дип атады ул аны. «Бүген Адам исемле искиткеч бер малай белән таныштым. Театрга килеп кергәч, ул исәнләште дә, гаҗәпләнеп, мине күзәтергә кереште (моңа бер дә аптырамыйм. Мине беренче тапкыр күргән балаларның гадәти реакциясе ул). Аннары яныма килде дә: «Сез шундый матур!» – диде. Бу сүзләрдән мин шулкадәр бәхетле идем. Балалар кешеләрне бөтенләй башкача күрә. Кешенең матурлык сере аның кәефенә бәйледер дип уйлыйм. Мин үземнең кызыклы тормышыма куанып бетә алмыйм. Бу тормышны миңа бүләк итүче Илаһыма рәхмәтлемен. Рәхмәт сиңа, Адам. Син – искиткеч малай».

Регина куйган фотоларны карыйм да, игелекнең чиксезлегенә сокланам. «Иман нуры» мәчете инде берничә ел рәттән Дәрвишләр бистәсендәге паркта бик зурлап Ураза бәйрәмен үткәрә. «Узган ел 3 мең кеше килде. Бушлай баллы мамык белән сыйландылар, бәйрәм ризыкларыннан авыз иттеләр, балалар җәнлекләрне сыйпап мәш килде, – дип кызыктыра Регина. – Беренче елны бер генә зоопарк чакырган идек, соңгысында дүртәү килделәр. Аны мөселманнар өчен генә уздырмыйбыз, теләгән һәркемгә капкалар ачык: «Балалар ислам диненең игелеккә өндәвен, мөселманнарның ачык булуын күреп үссен. Шулай булганда, алар исламга төрлечә яла ягуларга ышанмаячак. Мөселманнар безгә бәйрәм ясады, тәмле ризыклар белән сыйлады, бүләкләр өләште, алар берничек тә начар кешеләр була алмый, диячәк», – ди безнең Нияз хәзрәт».

Нагорныйда ачылган «Бәләкәй принц» паркы өчен дә халык «Иман нуры» мәчетенә рәхмәтле. Узган ел анда беренче тапкыр Корбан бәйрәме узган. Яз саен бөтен бистәне, урманны чүпләрдән чистарту өмәсен дә алар оештыра.

Миңа Регинаның тагын бер сүзе бик ошады: «Мәчет ул – игелек үткәргеч, – диде ул. – Без – ярдәмгә мохтаҗлар белән ярдәм итәргә теләүчеләр арасындагы арадашчы. Эшли генә башлаган елларны балаларны берәр концертка йә театрга алып барып булмас микән дип, директорларга хатларны үзем яза идем, хәзер алар үзләре яза. Мин монда эшли башлагач, могҗизаның барлыгына ышандым. Уйлар материальләшә, диләр. Бу, чынлап, шулай. Бер абыстаебыз кассетадагы Коръәнне цифрлаштырып бирүемне сорады. Шуны флешкага күчереп алырга кирәк, минем ул юк иде, сатып алырга да җай юк. Ышанасызмы, икенче көнне үк флешка бүләк иттеләр. Ә берсендә, мохтаҗ кешегә бирегез дип, мең сум сәдака калдырдылар. Шул арада берәү, даруга бер мең сум акчам җитми, дип килеп сорады. Истә калган тагын бер очрак: мәчетнең идәне таш булгач, җәй көне аяк туңа. «Монда киеп йөрергә аяк киеме аласы булыр», – дип уйлап йөри идем, мәчеткә килүче бер апа җылы башмаклар бәйләп алып килгән. Шаккаттым!»

Ә мине исә бу кызның тәвәккәллеге, рухының көчлелеге шаккаттыра. Мәктәпне бик яхшы тәмамлап, берүзе Казанга килә, берьюлы ике вузда югары белем ала. Кесәсендә – Аграр институтының урман хуҗалыгы инженеры һәм психолог дипломнары. Кызганыч, кызының бу шатлыгын әнисе генә уртаклашырга өлгерми. 2011 елда ул мәңгелеккә күченә. Ләкин аның әйткән сүзләре Регина өчен бүген дә тормыш девизы: «Дөнья берәүгә дә җиңел түгел. Сиңа да гел җиңел генә булмас». Яшүсмер чактагы үртәлүләр, ник мин башкалар төсле түгел дип кимсенүләр инде үткән. «Казанга укырга килгәч, кешеләрнең мине фотога төшерә башлавыннан ояла идем. Аннары уйлыйм: ник кыенсынам соң әле, төшерәләр икән, матур итеп елмаерга кирәк!»

Ничек диләр әле, язмыш лимон бирсә, лимонад ясa, диләрме? Бу нәкъ Регинача инде. Узган ел ул «Татарстан энҗесе» конкурсында җиңүче булган иде, быел Төмәндә узасы «Мисс оптимизм» бәйгесендә катнашачак, һәм менә күрерсез – ул җиңәчәк!



Лариса
МАЛИКОВА

Әбиебез безгә беркайчан акыл өйрәтмәде: аның кылган гамәлләрен күреп тәрбия алдык.

МӨҺЕРЛЕ ӘБИЕМ

Мәхрүсә әбием Әгерҗедә яши иде, без – Менделеевскида. Абыем белән мине һәр җәйне каникулга әби-бабай янына кайтарып куялар. Ул вакытта әле бу ике арадагы юл шундый озын, шундый газаплы иде! Ләкин әлеге юлның ахыры бик рәхәт тәмамлана – күмерле самавырда чәй кайнатып (без утырган поезд һәрчак вакытында килә!), бәлешләр пешереп, безне баштарак әби белән бабай – икәү, аннары әби үзе генә көтә иде бит...

Мәхрүсә әбием алар яшәгән озын Димитров урамының управдомы иде. Аның без кызыга торган, ләкин тияргә ярамаган өч әйберсе бар иде – мөһер, телефон һәм счет (вакыты җиткәч, агач төймәләре белән матур тавышлар чыгара-чыгара, әбием мине шунда санарга өйрәтте). Нинди генә гозер белән килми иде халык аңа! Әбиемнең аларга булышу юллары да – төрле-төрле. Хәтта СССРның хатын-кызлар оешмасы рәисенә – Валентина Терешковага хат язып, ирләре сугышта һәлак булган ялгыз әбиләрнең өйләренә су кертүен, фатирлар алып бирүен хәтерлим... Әбинең шушы гамәлләрен күзәтеп, беренче һәм иң мөһим сабакны алдым – проблеманы хәл итү өчен кулыңнан килгәннең барысын да эшләп карарга кирәк. Икенчесе – булдыра аласың икән, кешегә булышырга тырыш!

Гаделлек... Аның асылын аңлаткан өчен дә әбиемә рәхмәтлемен. Каникулда без аңарда дүрт онык җыела идек. Билгеле, гел дус-тату булып тормыйбыз. Колонкадан суны кем алып кайта, тимер караватта йокларга кемнең чираты – низаглар күбрәк шулар аркасында чыга. Ләкин әбиемнең аларны хәл итүнең үз юлы бар. Шобага салу! Ул ялт кына йә бау, йә таяк (кул астына нәрсә эләгә) ала: без шуңа куллларыбызны чиратлап куябыз. Кемнең кулы өстә кала – чират шуңарда. Үпкәләргә дә урын юк, дөрес түгел диярге дә...

Әби безне ачуланмый иде. Аның ике сүзе бар: «хәчтрүш» һәм «әбстрий». Бу сүзләр тәгаен нәрсә аңлаткандыр – аны-сын белмим. Яратып ачулана икән, димәк, «кирәкмәгән эшебез» бик зыянлы булмаган, без – хәчтрүшләр (бераз көлү төсмере дә булганын тоясызмы?), ә инде чынлап та ачуын чыгарсак, без – әбстрийләр.

Төннәрен сызланудан ыңгырашып чыккан кечкенә әбиебезнең тагын бер сабагы (дөресен әйтим, бүгенге көндә ул миңа кайчак комачаулый да) – үзенең эшен кешегә ышанып тапшырмау. Чәй эчкәннән соң табын җыярга, савыт-саба юарга һәм колонкадан су алып кайтырга гына рөхсәт итеlә иде безгә. Бераз үсә төшкәч, кибеткә йөри башладык.



Аһ, әбиемнең бауга эленгән ап-ак урынҗир әйберләре, сөлгеләре, савыт-саба сөрткән киндер тастымаллары... Аларны юарга да әби беркемгә дә рөхсәт итми. Ул ап-ак керләрнең серенә соңрак төшендем: әби суына өч төрле әйбер – сода, «Мальва» һәм порошок сала икән.

Бакчасына да керү тыела. Балаларга гына түгел, олыларга да. Кура җиләге өлгергәч, Ижаудан апалар килә, аларга да әбием: «Кермәгез, рәтен белмисез, таптапсындырып бетерерсез, үзем җыям», – дия.

Ә ул өйгә керә торган сап-сары идән баскычлары! Эх, белсәгез иде, әби аларны юганда ничек кызыгып карап торганымны?! Башта баскычны суга порошок салып, мунчала белән ышкый, аннары чиста су белән юа, аннары инде корыта... Миңа, әлбәттә, булышырга рөхсәт юк. Шул су алып кайтып торсам гына инде... Бу да үзенә күрә бер сабак булган бит! Беренчедән, читтән карап торып, эш тәртибенә өйрәнү; икенчедән, балада ул эшне башкарырга теләк уяту.

Әбиемнең күршеләрен шаккаттырган тагын бер әйберсе бар – бәрәңге базы. Диварлары штукатурланган, сыланган иде аның (хәзер бу гаҗәп түгел инде, ә ул чорда...), бәрәңгесе әрҗәләргә салынган, ә баз идәненә... суккан палас җәелгән. Һәм әби анда аяк киемен алыштырып керә!

Әбием – бик укымышлы, затлы-зыялы нәселдән. Аның кайбер сүзләрен хәзер дә искә алабыз, ә ул аларны үзенең әтиәнисе, әби-бабасыннан ишеткән булгандыр. «Шундый заман җитәр, урманда йөрсәң дә, синең кайда икәнеңне белерләр». (Бүгенге геолокация лабаса!) «Берзаман кешеләр зур биналар корырлар, өйләре биек-биек, ә өреләре сыек булыр». (Монысы ипотекадыр дип көлешәбез.)

Менә шулай уйнап, ара-тирә суга барып, әбине күзәтеп, көн узып та китә. Кич җитә... «Мәхрүсә, ишегалдың, өең мәчет сыман якты. Коръәнне синдә укыйк әле», – дип, әби-бабайлар керә. Әбием, битләре саргаеп беткән калын китапны киштәсеннән алып, кычкырып укый башлый.... Ә күршеләр кермәгән көннәрдә, урындыкка утыра да, кулларын тезләренә куеп, кояш баеганын күзәтә. Һәм... көтә... (Без ул чакта аның намаз вакыты җитүен көтеп утырганын аңламаганбыз, арыгандыр инде дип уйлый идек.)

Әбием... Сине искә алган саен күз алдыма матур, якты сурәтләр килә... Ә сабакларың өчен рәхмәт! Алар минем бүгенге яшәү рәвешемдә, тоткан кыйбламда чагыла, тормышымда килеп чыккан авырлыкларны җиңәргә ярдәм итә.

«МИН МӘХӘББӘТТӘН ТУГАНМЫН...»

Ата һәм бала. Бу икәү арасында бернинди киртә булырга тиеш түгел кебек. Тик тормышта кайчак киресенчә дә килеп чыга шул. Һәм, ни кызганыч, күзгә күренмәс ул киртәне күп вакыт баланың иң якын кешесе – әнисе кора. Әллә белеп, әллә белмичә... Ата кеше исән булып та, бала аның мәхәббәте, яратуы, назыннан мәхрүм булып үсә. «Ә кыз балага әтисенең яратуы тагын да кирәгрәк. Аны гомер буе озатачак ярату ул», – ди Әлмәт Татар дәүләт драма театры актрисасы, Татарстанның атказанган артисты Мәдинә ГАЙНУЛЛИНА. Бәхеткә, ул аны соңарып булса да, татып өлгергән. Ачыктан-ачык сөйләшәбез.

Мин әтиемне беренче тапкыр 18 яшемдә генә күрдем...

Институтта укып йөргән чагым. Актерлык осталыгы буенча дәресләребез Камал театрында үтә. Кызык, күңелле вакытлар! Миннән берничә курска алдарак укыган Рамил Фазлыев (ул хәзер Әтнә театрында режиссер) туган көненә чакырды. Студентка акча гел җитми бит инде – ул Казан Елга портында эшләп тә йөри икән. «Бөтенегезне «Ом»икта Иделгә алып чыгасым, андагы матурлыкны сезгә дә күрсәтәсем килә», – ди. Җыелып киттек. Кызлар белән гөрләшеп табын көйлибез. Әкренләп башка кунаклар да керә башлады. Капитаннар! Дусларым миңа һәрвакыт «Фәритовна» дип дәшәләр. Моны ишетеп калган кунакларның берсе: «Ә бездә Фәрит исемле капитан бар!» – диде. Рамил: «Мин бит аны да чакырдым!» – дигәч, йөрәгем жу-у итеп китте: «Фәрит диләр бит, ул, мөгаен, минем әтидер...» Аннан уйлыйм: «И-и, беткәнмени инде дөньяда Фәритләр!» Әтиемнең Елга портында эшләгәнен, капитан икәнлеген белә идем... «Әйе, безнең капитан Фәрит Әмиров», – дип өстәде теге кунак. Әти бу! Үзе! 18 яшьлек Мәдинә шул мизгелдә меңгә бүленде: бер «килсен иде» дип телим, бер «килмәсә ярар иде» дип... Кунаклар өстәлә торды. Ниһаять, табын янына утырдык – котлаулар башланды. Шулчак яныма бер ир килде дә: «Пойдем выйдем», – ди. «Гафу итегез, мин белмәгән кеше белән беркая чыкмыйм», – дим. Миңа бәйләнәләр дип уйлыйм бит. «Я сказал пойдем выйдем. Нам нужно поговорить», – ди бу тагын. Чыктым. «Больше здесь не появляйся», – ди бу миңа. Ачуым килде. «Кто вы мне, чтобы приказывать?» – дим. «Я имею право приказывать, я твой отец», – ди бу. Гел күз алдымда: «Ом»ик бортына шундый каты итеп кысып тотынган – кулындагы кан тамырлары бүртеп-бүртеп чыккан. Исемә төшкән саен, каз тәннәре кабара... Ә мин... Мин эчтән бу минутта берни кичермәдем, шулкадәр битараф идем. Бернинди сөенеч юк... Ә бит әти белән бу очрашуны ничекләр көттем! Әмма ул очрашу башка төрле булыр дип күз алдыма китерә идем. Кинолардагы кебек... Мин катып калдым. Берни эндәшмәдем.

...Әти белән әни миңа 2 яшь чакта ук аерылышалар. Әнигә ул чакта нибары 21 яшь була. Кияүгә унсигездә үк чыга. Мин аларның мәхәббәт тарихларын бөтенләй белмим дисәм дә була. Әни миңа аны беркайчан сөйләмәде, әтинең дә телгә алганы булмады. Өзек-өзек кенә ишеткәләдем... Әни – Кама Тамагы районы Олы Кариле авылы кызы. Мәктәпне тәмамлаганнан соң Казанга килеп, мех берләшмәсенә эшкә урнаша. Елларда туган авылына, әти-әнисе янына кайтып йөри. Җәйләрен ул чакта Кама Тамагына гел су юлы белән кайтканнар. Ә әти – теплоходта капитан. Ул әнине беренче тапкыр шунда – үзе йөрткән «Ракета»да күрә. Үзеннән дүрт яшькә кечерәк чибәр кызга шунда ук гашыйк була: «Мин барыбер аны үземнеке итәм!» – ди. Ул аңа ничек килеп сүз дәшкән, ничек танышканнар, ничек йөреп киткәннәр, әйткәнемчә, боларның берсен дә белмим. Әни бу хакта хәтта бүген дә искә төшерергә

Мин аның яратуын яңа тоя гына башлаган идем әле.

яратмый. Өйләнешкәч, алар әтиләрнең Елга порты янында ук урнашкан ике бүлмәле фатирларында яши башлыйлар. Мин туганмын.

Исемне миңа әти кушкан. Белсәгез иде исемемнең үземә ничек ошаганын! Мәктәптә укыганда: «Нигә сиңа шундый иске исем кушканнар?» – дип сораучылар да булгалады. Ә мин ярата идем! Андый исем берсендә дә юк иде бит!

Әти, башка капитаннар кебек үк, командировкалардан кайтып керми – еракларга да китеп йөри. Әнидә көнләшү хисе туа. Үзе әйтмешли: «Яшь чак – җүләр чак...» Әти исән вакытта: «Хәзерге акылларым булса...» – дип, җөмләне башлап, шулай күп нокталар белән бетермичә калдырганы булгалады аның... Алар аерылышалар.

Бераздан әни Лаеш районы Имәнкискә авылына кияүгә чыга. Шуңа күрә үз-үземне белә башлаганда минем янда әти бар иде. Юныс әтием. Аны «үги әтием» дип әйтәсем дә килми. Моңа телем бармый... Ул мине үстерде. Яратып үстерде! Минем өчен җанын бирергә дә әзер. Әгәр шундый хәл килеп чыкса, әйтик, миңа бер бөер кирәк булса, ул аны ике дә уйламыйча бирәчәк. Юныс әти миннән бернәрсәне кызганмый, хәтта соңгы сыныгын да бирергә мөмкин.

Авылга күчеп кайткач, мунчада юынырга теләмәгәнмен, миңа шәһәрдәге кебек ванна кирәк, дигәнмен. Юныс әти чуен ванна сатып алган. Идән уртасына куеп, мине шунда юындыралар икән. Шул вакыт такси белән үземнең әти кайтып төшкән. Әни белән мине алырга. «Тәрәзәдән әтиеңне күрдең дә сөенеп, Юныска: «Папа, там мой папа приехал!» – дидең», – дип сөйли әни. Таксист, счетчигын эшләтеп, әтине капка төбендә көтеп торган. Тик әни китмәгән...

1 нче сыйныфка мин Имәнкискәдә укырга кердем. Дәфтәр тышына «Мәдинә Мәхмүтова» дип язып куям, укытучы гел сызып, «Әмирова» дип төзәтә. Елап, әнигә кайтам: «Нигә апа миңа башка фамилия яза?» – дим. Документларда Әмирова булганымны белмим бит... «Сине Юныс әтиең карый, үстерә, ә үз әтиең башка», – диде ул. Әти турында аңа кадәр дә, аннан соң да миңа сөйләмәделәр. Капитан икәнен әйтүдән башка. Аның нинди икәнен дә белми идем – карарга фотосы булмады. Шул көннән башлап әти турында хыяллана башладым... Кинода нинди генә матур ир-ат актер күрсәм дә: «Әтием, мөгаен, аңа охшагандыр», – дип карый идем. Ул бик матур булырга тиеш дип уйлый идем. Әтиемне күргәннән соң, ялгышмаганымны аңладым. Ул нәкъ минем хыялымда йөргән кеше иде...

Мәктәпкә барганда, әти мине җитәкләп бара дип күз алдыма китерәм, аны кочаклыйсым, алдына менеп утырасым килә иде... Әмма әни боларның берсен дә

Мин диплом алгач, әти группабызга бүләк ясады: теплоходында безне Иделгә алып чыкты.



белмәде. Ул миңа әти турында сөйләмәгәч, мин дә аңа ачылмадым.

Без әни белән айга бер мәртәбә Казанга, Елга портына барып кайта идек. Бухгалтериягә, алимент алырга йөргәнбез инде. Елга портында булганда, янныбызга гел бер ир кешенең килергә теләвен хәтерлим. Ул безгә якынайган саен, әни тизрәк мине ашыктырып алып китә иде. «Кем соң ул?» – дип сораганым да булды. «Белмим», – дия иде. Соңыннан гына аңладым – әти булган инде ул... Минем янга килергә теләгән...

Әни Имәнкискәгә биш ятим бала өстенә кайтып керә. Бер уйласаң, герой инде ул безнең.... Юныс әтинең әнисе үлеп китә тә, әтиләре дүрт өй аркылы яшь хатынга йортка керә. Берсеннән-берсе кечкенә биш бала абыйлары кулында кала. Юныс әти белән әни аларның барысын үстерделәр, аякка бастырдылар, укыттылар, башлы-күзле иттеләр... Үз әтиләре күршедә генә яшәсә дә, балалары янына кереп-чыгып йөрмәде, берничек тә булышмады... Әни хәзер шикәр чире белән авырый. Нервлары юкка гына бетмәгән... Ятим балаларга ул каты бәрелә алмый, шуңа күрә гел күбрәк миңа эләгә иде. Җәлләгәннәрдер инде, мәрхүм дәү әтием килеп, мине үзләренә – Олы Карилегә алып кайтып китте. Өченче сыйныфны тәмамлаган елым иде.

Әмма Кама Тамагында озак укымадым. «Инглиз теле өйрәнәсем килә», – дигәч, әни мине Казанга күчерде. Җиденче класска кадәр бер дәрес тә инглиз теле укымавымны белгәч, мине бер мәктәпкә дә алмадылар. 15 нче гимназиядә дә теләмичә ризалаштылар. Әмма сыйныфташларымның барысын да куып җиттем! Туганнарда яшәп укыдым, иртәнге биштә торып, гимназиягә кадәр өч транспортта бара идем. Тик дәү әнинең соңгы – бишенче кызы да кияүгә китте дә, «Су ташырга да кешем калмады», – дип, ул мине кире авылга кайтартты. Олы Кариледә унынчыны тәмамлагач, институтка укырга кердем. Күчеп йөрүләр, авырлыклар аша узулар мине шактый чыныктырды. Кешеләрне танырга өйрәндем. Дөньяга башкача карый башладым. «Син бит яшь әле, нәрсә аңлыйсың?» – диючеләр, минемниләр кичергәнне күз алдына да китермиләр иде. Бернәрсәгә зарланмаска да шул чакта өйрәндем...

...«Ом»икта әти белән бер-беребезгә карашып торган мизгелдә туктаган идем... Ул кинәт йомшарды. «Әйдә, әйберләреңне җый, мин сиңа үземнең теплоходымны күрсәтәм», – ди. Икеләнеп торганымны күреп: «Әллә әтиең икәненә ышанмыйсыңмы?» – дип паспортын чыгарды. Минем дә күңелем икенчеләнде. Туган көн дә онытылды: сумкамны алып, баскычтан аның янына ничек очып менгәнемне сизми дә калдым. Әтинең әнине яратканын ул чакта, беләсезме, кайдан аңладым. Янәшә барабыз, ә әти нигәдер гел арткарак кала. Туктап, аны көтәм. «Атла, атла, минем сиңа карыйсым килә, Гәүдәң әниеңнекенә бик охшаган», – ди. Миңа карый да һаман әнине сөйли. Ә миңа уңайсыз. Ул бит миңа әле барыбер ят иде. Гомумән, әти дип мин аны тиз генә кабул итә алмадым.

Теплоходка кергәч, ул безнең икебез өчен табын көйләтте. Әби белән бабай турында сөйләде. Аннан яныма килеп утырды да, аякларымны үзенең аяклары өстенә куйды. Үзе сөйли, үзе аякларымны сыйпый... Ә миңа шундый уңайсыз – бөтен тәнем куырылып килде. Әти өчен мин һаман да ул кайчандыр белгән 2 яшьлек кызчык идем бугай... Мин бит иркәләнеп үсмәдем – кырысрак тәрбияләделәр. Әйткәнемчә, биш ятим бала арасында әни миңа карата башкача була да алмый иде.

Әти мине шул кичне үк үзләренә алып кайтып китте. Өйдә кеше юк иде – хатыны Югары Осландагы бакчаларында дип аңладым. Без төне буе сөйләшеп чыктык. Озакламый алар мине очрашуга чакырдылар. Хатыны Лена шунда ук мине кочаклап алды. Аның миңа карата мөнәсәбәте гел әйбәт булды – үз кызыдай күрде... Очрашуга алар өчәү килделәр. Сеңлем Алинә моңарчы минем барлыкны белмәгән. Йөрәге чирле дип, аңа бу хәбәрне турыдан әйтергә дә курыктылар. Аңа ул чакта 10 яшь иде. Аерылышкач, әти кабат тиз генә өйләнмәгән әле. Чынлап торып яратса, ир-ат якын кешесен югалтуны күпкә авыррак кичерә шул...

Мин әтиләргә күченеп яши башладым.

Әтине тапканымны башта әкрен генә әнинең үзенә әйттем. Юныс әтинең бу яңалыкны ничек кабул итәсен белмим бит. «Мин хәзер аларда яшим», – дигәч тә, әни бер сүз эндәшмәде. Үпкәләгән сыман борылып кына китте. Әчтән борчыла, сизеп торам – тик берни әйтми. «Сезнең арада нидер булганга минем гаебем юк бит инде, әни. Аның янәшәсендә булырга хакым бардыр. Тиздән барыбер эшкә Әлмәткә китәм», – дим. «Ярый, син зур инде, үзең хәл ит», – дип җавап бирде.

Мин этиләрдә өч ел яшәдем. Ике бүлмәле фатирның бер бүлмәсен Алинә белән миңа бирделәр. Әти беренче көннән үк: «Кызым», – дип дәште. Мин дә: «Әти», – дисәм дә, аның барлыгына тиз генә ияләшә алмадым. Юныс этине кочаклаган кебек кочаклап алырга телим – булмый. Арада киртә тора. Безне аерган 18 ел...

Әлмәткә ул мине машина белән үзе озатты. Бүлмәмә урнаштырып ук китте. Бер елдан кияүгә чыктым. Юк, туема килмәде, анда әни бар иде бит... Туй узуга, Илдар белән мине үзенә чакырып алды һәм «Павел Миронов» теплоходына путевка бүләк итте. Туй сәяхәте булды ул безнең... Каршылаганда әти бер кочак гладиолуслар күтәреп килгән иде. Һаман күз алдымда тора... (Мин студент чакта спектакльләрдә уйнаганда да, ул һәрвакыт чәчәкләр белән килә, әмма аларны сәхнәгә чыгарырга ояла иде.) Аралашып яшәдек, ул безгә кунакка килеп торды. Балалар аны гел көтәләр иде – ул аларны күчтәнәчләре белән сөендерергә яратты.

Март аенда этигә 55 яшь тулды. Юбилеена гаиләбез белән бардык. Хатыны табын әзерләгән. Тик күрәм, эти үз өендә чит кеше кебек. Алар инде бергә тормаган икән... Эти ябыккан. «Ашамыйсыңмы әллә?» – дигәч, «Мин бит картаям, ябыгуым шуңа гына ул», – дип шаяруга борды. Киткәндә, безне машинага кадәр озата төште. «Ял алам да, август аенда сиңа киләм, вәгъдә бирәм», – ди. Ишекне яптым, ә ул һаман кулын таянган җиреннән алмый. Кабат ачтым. Эти тагын теге сүзләрне кабатлый: «Ант итәм, киләм августта», – ди. Ә үзенең ике күзеннән дә шыбырдап яшь ага...
Мин елыйм, ул елый... Бу безнең соңгы күрешү булган...

Августта ул килмәде. Сентябрь, октябрь узды, ноябрь җитте. Без Әмирхан Еникинең «Тормыш корабы» дигән әсәрен сәхнәләштерәбез. Репетицияләр бара. Шулчак эти шалтырата: «Чистайга теплоходны ремонтка алып килдем. Бер көн булам. Зинһар, кил, сиңа әйтәсе сүзем бар», – ди. Ә мине җибәрмиләр! Премьера бит! Андый чакта авырырга да ярамый безгә... «Үзең безгә килеп кун, эти», – дим. «Теплоходны калдырып китә алмыйм», – диде. Бер айдан мәңгелеккә китәсен белгән булсаммы?!.

Премьерага бер көн кала, мине эзләп, театрга Илдар шалтыратты. «Бабай үлгән», – ди. «Урыны җәннәттә булсын», – дип телефонны куйдым. Юныс этинең этисе урын өстендә ята иде, ул дип уйладым. Илдар кабат шалтыратты: «Мәдинә, бабай үлгән бит», – ди. «Аңладым», – дим. «Соң кайт инде, җыенырга, Казанга китәргә кирәк», – ди ул. «Ә нигә Казанга?» – дим. «Фәрит бабай үлгән...» Стенадан шуышып төштем. Ничек үлгән? Ул бит киләм дип вәгъдә бирде миңа!..

Үзендә яман шеш икәнен эти берәүгә дә әйтмәгән. Хәтта Әлфия апасына да. Әтинең ачылып сөйли торган түгел икәнен аңлаган идем инде. Бәлки ул яраткан кешесе белән дә яшәмәгәндер. Барысын да эченә җыйгандыр, шуңа бу чир килеп чыккандыр. Кем белә...

Эти күңелемнән һич китми, аны бик еш искә алам. Искә алган саен, күзләремә яшь тула... Нигә ул һаман да янымда йөри, белмим. Быел инде аңа 63 яшь тулган булыр иде... Минем сәхнәгә тартылуым да аңардандыр.



Эти бик матур итеп гитарада уйнаган, армиягә киткәнче, алар хәтта үз группаларын оештырганнар. Әниләр өендә гел кеше күп булгангадыр, этиләрдә рәхәт иде миңа. Тыныч иде. Чәй эчкәндә чынаякны да тәлинкәгә тавышсыз гына куя белә иде алар. Мин яраткан халәт бу... Өйдә хәзер дә үзем генә калырга яратам: җырлыйм, шигырь язам, хыялланам, идеяләр туа... Кеше күп булган җирдән качасым килә... Сеңлем белән алай артык якынлыгыбыз юк. Ул бит үзе генә үскән, бөтен игътибар аңа булган. Ә аннан кинәт мин табылдым... Эти миңа нидер алганда көнләшүен яшерми иде. Ә этинең миңа да булышасы, мине дә сөендерәсе килде...

Минем берәүгә дә үпкәм юк. Әни болай да күпне күргән. Бәлки, этигә карата үзенең үпкәсе булгандыр. Безне аралаштырмыйча, ул аннан үч алгандыр. Хатын-кызларның бит күбесе шулай итә... Горурлык та булгандыр. Ялгышулар да. Аны бит еллар узгач кына аңлыйсың... «Дөрес эшләмәгәнсең, әни», – дидем. «Булган – беткән», – диде... «Эти» дип хыяллануларымны, әйткәнемчә, ул белмәде. Сөйләргә курыктым, әни яшергәч, мин дә яшердем. Сөйләсәм, ачуланыр төсле иде. Кимсенеп үстем...

Этигә дә бер тамчы үпкәм юк. Ул бит яныма килергә тырышып караган – китертмәгәннәр... Тарткалаша алмас иде – аның тәрбиясе башка. Гаепләп сөйләмим, кемгәдер сабак булуын гына телим. Этинең рухы шат булсын. Без барыбер кайчан да булса очрашачакбыз...

Гөлнур САФИУЛЛИНА язып алды.



Тулысынча сайтыбызда укыгыз.



ТЫН ЕЛГАДА САЛ ТИРБӘЛӘ...



Без гаилә белән сәяхәт итәргә яратабыз. Хәзерге заманда дөнья күрү, илләр гизү өчен шактый зур чыгымнар кирәк, ә сездә биш бала! Һәммәсенә акча каян җиткезеп бетерәсез, дияргә ашыкмагыз. Балаларга онытылмаслык балачак бүләк итү, аларның тормышын маҗаралар белән баету, күңелләрендә гомерлеккә истә калырлык хис-кичерешләр тудыру өчен матди чыгымнар кайчак аның кадәр күп кирәкми дә…
Ничек дисезме? Җавап бик гади:
без диңгез яры эзләп чит илләргә чыгып китмибез. Елгада гына ял итәбез!
Мондый идея ничек тудымы? Хәзер сөйлим.

Лаура ВӘЛИДОВА

Гаиләдә без өч кыз үстек. Әти белән әни балачактан ук безнең өчебезне дә үзләре белән походларга йөрттеләр. Сөйләүләре буенча, алар икесе дә яшьтән үк туризм белән актив шөгыльләнгән. Шуңа күрә дә мондый сәяхәтләр безнең гаилә өчен бик табигый иде. Әнием әйтүе буенча, беренче тапкыр мин палаткада сигез айлык чагымда ук кунганмын. Бөтенләй сабый гына булганмын! Әйе, табигатькә якынлык ул безгә чын мәгънәсендә ана сөте белән сеңдерелгән: урман-кырларда йөрү, әйләнә-тирәне өйрәнү, тереклекне күзәтү... Болар барысы да безгә әти-әнидән бирелгән.

Сәяхәтләр белән бәйле балачак хатирәләре, җылы истәлекләр беркайчан да онытылмый. Мин бу сәфәрләрнең һәрберсен әле дә хәтерлим...

Психология ягыннан карасак та, һәр баланың тормышында уңай хис-кичерешләр калдырган чаралар булу бик мөһим. Шуңа үземнекеләрнең күңелен дә шундый вакыйгалар, тәэсирләр белән баетырга телим. Моның өчен әти-әниемнән алган уңай тәҗрибәне бик еш кулланам.

Инде сүздән гамәлгә күчик. Шулай да, сәяхәткә кая барырга соң? Туристик чараларның күпсанлы төрләре бар. Без исә «сплав»ны – елга буйлап көймәдә яки салда йөзеп төшүне сайладык. Гаиләбездә матур бер гадәт яши: һәр елны җәен өч көнгә Иләт елгасына барабыз. Шушы сәяхәт безгә ел буена җитәрлек көч бирә, үзара мөнәсәбәтләребезне ныгыта, балаларыбызны күз алдында үстереп җибәрә. Иләт – тын гына ага торган елга, шуңа күрә «сплав»ка балалар белән баручылар өчен ул иң кулае.

Иләт елгасы – Иделнең сул кушылдыгы, ул Татарстанда башлана, аннан бик озак Мари Иле буйлап ага, ахырда кабат Татарстанга әйләнеп кайта. Мари Илендәге милли паркның төп елгасы да ул. Аның ярлары тирәсендә хәзерге көндә бер торак пункт та урнашмаган, шуңа күрә елгага бернинди юынтык су да, пычраклар да агып төшми. Аңа бары тик саф сулы көмеш чишмәләр генә коя. (Иләткә коя торган Вонча исемле кечкенә генә елга, дөньяда ук булмаса да, Россиянең Европа өлешендә иң чиста сулы елга дип санала. Анда хәтта бик сирәк очрый торган бәрде – «европа хариусы» дигән балык та яши. Бу балык Мари Илендә, Ярославль өлкәсендә һәм ерак Германиядә Кызыл китапка кертелгән.)

Балалар белән елга буйлап йөзеп төшү нәрсәсе белән уңайлы соң? Беренчедән, урманга, тауга походка чыккандагы кебек, йөгеңне күтәреп барырга кирәкми: аны салга (көймәгә, байдаркага, катамаранга) куясың да агымсу уңаена ашыкмый гына хәрәкәт итәсең. Нәкъ мәгълүм мультфильмдагы теге керпе кебек. Җайлап кына, тирә-юньне күзәтеп, урман авазларына колак салып... Әнә тегендә нindидер кош сайрый, бөҗәкләр безелдәгәне ишетелә, кинәт суга «чупылт» итеп нидер чума... Әй, әтисе шаяра икән лә...

Бөтенесе бер салга кереп утырган гаилә сал хәрәкәт итсен, җайлап кына алга таба аксын өчен берләшә – команда рухы туа. Салны суга төшәр өчен җыйганда

Иләтнең суын күз яше кебек чиста, боз кебек салкын, диләр, ул кышкы суыкларда да катмый.



Автор фотолары

бу эшкә балалар да бик теләп катнаша – әти-әнигә кулдан килгән кадәр ярдәм итәргә тырыша: алар нәрсә эшли, шуны кабатлый. Бу күренешне – гаиләнең сал тирәсендә әвәрә килүен – күз алдыгызга гына китереп карагыз. Тулы гаилә белән бергә булу бәхет бит ул! Мондый сәяхәтләр вакытында син өйдәге вак-төяк эшләргә бүленмисең, телефоннан аерыласың – аны бөтенләй онытасың, юк-бар сүзгә вакыт әрәм итмисең. Әтиләренә мин һәрвакыт: «Җәйнең өч көнен бары тик гаиләңә багышла. Шушы өч көндә балалар сине ел буе күрергә тиеш булган кадәр күрәчәкләр», – дим. Шаяртып әйтәм инде... Әмма бу сүзләрдә хаклык та бар бит. Гадәттә, әти кешеләрнең вакытлары күбрәк эштә уза, бу бигрәк тә безнең кебек ишле гаиләләргә кагыладыр. Иртән иртүк чыгып китә – балалар әле йоклап кала, кич арып, бик соң кайтып керә – кечкенәләр күп вакыт инде яткан була. Балалар әтиләре белән бик аз аралаша, шуңа күрә аларга аның игътибары җитми калырга мөмкин. Ә менә мондый сәяхәтләргә чыккач, әти кеше бик теләсә дә салдан беркая китә алмый: телиме-теләмиме балалар белән аралаша, алар белән бергә тирә-юньне, дөньяны ача. Җәйге көн озын: сөйләшмәгән сүз, җырланмаган җыр, сөйләнмәгән мәзәк, яумаган сорау калмый... Шундый күңелле!

Балалар өчен иң кызыгы – сал өстендә палатка кору. Яраталар шуны! Су өстендә үзенә күрә йөзә торган йорт барлыкка килә бит. Кояштан качып черем итеп алыйм дисәң, рәхим ит! Өйле-өйле уйнарга да менә дигән.

Шушы өч көн эчендә рәхәте җәй буена җитәрлек итеп су коенып кала балалар.









Суның һәрвакыт янәшәдә булуы да алар өчен бик уңай. Шәһәрдә каядыр барып су коенып кайтырга теләсәң, моның өчен башта ярты көн әзерләнергә, юлга әллә никадәр вакыт сарыф итәргә кирәк. Өйдән чыгып пляжга барып җиткәнче кире уйлавың да бар. Ә монда... Менә – син, менә – елга! Нибары бер адым! Балаларның көнозын судан чыкмый яткан чаклары да булгалый. Гадәттә, «су керү тыела» дип кисәтәләр. Ә без, киресенчә, «су кермәү тыела!» дибез. Кайчан ярга чыгасын алар үзләре чамалый.

Иләт – мул агымсулы елга. Суы салкын булганга күрә анда бернинди дә зарарлы бактерияләр, таякчыклар яшәми, шуңа күрә аны хуҗалыкта рәхәтләнеп, курыкмыйча кулланырга мөмкин. Елга суы белән без ашарга да әзерлибез, чәй дә куябыз, шунда юынабыз да.

Безне аеруча Иләт елгасының ак комлы ярлары әсир итә. Мондый чиста комны табу өчен бик тырышып эзләргә кирәк әле. Мин аны бары тик Мальдив утраулары комы белән генә чагыштыра алам. Иләт елгасы ярындагы бу урыннарга кешеләр машина белән барып җитә алмый. Әлеге манзара бары тик безнең кебек табигатькә якын булучылар өчен генә ачыла. Балалар шул комда мәш килә. Менә кайда ул ком терапиясе: телисең икән – биек патша сарайлары, ныгытмалар төзе, телисең икән – комга күмелеп ят. Кояшта җылынган ком тәнгә шифа бит ул. Тамак ялгап алганнан соң, савыт-сабаларны юар өчен дә бернинди химия-сабын кирәкми – ком белән ышкыйсың да ялт итә!

Салда йөзгәндә кайда телисең шунда туктап, ярга чыгып чатыр корасың, ашыйсың, ял итәсең... Аннан кабат җыенып, юлыңны дәвам итәсең: яңа матур урыннар ачасың, көтмәгәндә кемнедер очратасың. Куян чабып уза, бер агачтан икенчесенә тиен сикерә, аяк астыннан гына урман тавыгы, көртлек йөгереп китә, су өстенә бизәк ясап кондыз йөзә... Әлеге искиткеч урыннарның күбрәк милли парк территориясенә караганын әйттем инде.

Бу парк Казаннан 80 чакрым ераклыкта гына урнашкан. Кечкенәдән бу урыннарга еш сәяхәт иткәнгә, биредә миңа һәрнәрсә таныш. Гүзәл табигать, урман күлләре, җиләкләргә бай куе урманнар, сазлыклар... Бу җирләргә халык хәзер ял итәргә күпләп йөри. Еш кына табигатькә карата саксызлык күрсәтәләр, зыян салалар, шуңа күрә паркның күп почмакларына техника белән керү тыела.

Соңгы вакытта без Иләт бистәсеннән дүрт чакрым ераклыкта, елгага якын бер урында – наратлыкта утрак лагерь оештыра башладык. «Иләт Робинзоннары» дип аталган әлеге гаилә лагеренда узган ел инде йөзгә якын кеше катнашты.

Кыргый табигатьтә экстремаль шартларда ял итү – ул, беренчедән, тәүлек әйләнәсе ачык һавада булу дигән сүз. Икенчедән – бер-береңә ярдәмләшү: балалар эшнең ни икәнен үз җилкәләрендә тоя. Монда өйдәге кебек уңай шартлар юк: кранны борып кына су агыза яки газны кабызып кына ризык пешерә алмыйсың. Иң элек учак кабызырга чыбык-чабык,







утын җыясың, су китерәсең. Ата-аналар бу эшләргә балаларны да җәлеп итә. Читтән күзәтеп торучыларга без, мөгаен, кырмыска оясын хәтерләтәбездер: барыбыз да бердәм, бер дулкында, һәркемнең үз шөгыле бар, берәү дә күмәк эштән читтә калмый.

Лагерьга, ким дигәндә, ун көнне багышлыйбыз: алданрак килеп, башта әзерлек эшләре алып барабыз – вакытлыча яшәрлек шартлар тудырабыз. Бераздан халык агыла башлый... Лагерь программасы тәмамланганнан соң, тирә-юньне җыештырып, инде азрак ял итеп, тагын берничә көнебезне монда үткәрәбез. Лагерьга килергә теләүчеләргә яшь ягыннан чикләүләр куймыйбыз: безгә берничә айлык балалары белән дә кушылучылар бар.

«Иләт Робинзоннары»нда балалар күп нәрсәгә өйрәнә: программа бик бай итеп төзелә. Экстремаль шартларда исән калу нигезләре белән таныштырабыз, иҗади мастер-класслар уздырабыз, спектакльләр куябыз... Әмма барыннан да бигрәк балаларга кечкене учак, аның тирәсендәге сихри атмосфера ошыйдыр. Учакта пешкән ризык, үләннәр салып кайнаткан чәй, нарат, мүк җиләге, кара җиләк, башны әйләндерерлек саф һава... Яңгыр ява башласа да куркыныч түгел, телисең икән, кулчатырсыз гына яңгыр астына чыгып басасың. Чыланырга теләмәсәң, чатырлар корылган: керәсең дә яңгыр яуганын ышыктан гына күзәтәсең. Әти-әни, дусларың янәшәсендә. Мондый чакта берни куркыныч түгел... Балалар шушы мизгелләрне аеруча ярата...

Гадәттә, ата-ана баламның өс-башы пычранмасын, өй артык тузмасын дип борчыла. Шуңа күрә улына яки кызына гел кисәтү ясап тора. Ә монда? Монда «ярамый»лар онытыла! Бөтенләйгә! Әнә кызыл балчык, ком – җаның күпме тели, шуның кадәр рәхәтләнеп ауна, буяуларга тәмам батып рәсем ясыйсың киләме – кинән. Әти-әниләр барысына да күз йома. Нигә йоммаска?! Су бит янәшәдә генә: баланы чумдырып кына аласың – ком да коела, буяу да юыла.

Эмоцияләр мөһим дидек, әйе, бу – шулай. Әмма, моннан тыш, бала әле чын тормышка да әзерләнә бит. Ун көнлек лагерьга барганда улым Раянга ике яшь ярым иде. Кечкенә булса да, бала кайбер кагыйдәләрне инде отып алган. Мәсәлән, учак ягар өчен утыннар өеп, ут төрткәч, ялкын үрләп китсен өчен бераз һава җилләтеп алырга кирәклеген сеңдергән. Өйдә уйнаганда гел каяндыр такта кисәге алып учак яккан кыяфәт чыгара. Димәк, бала нәрсәнең ни өчен кирәклеген аңлаган һәм гомерлеккә истә калдырган. Эмоцияләр белән кабул ителгән белем күпкә уңышлырак үзләштерелә диләр.

Җәйге яллар озын кебек тоелса да, килә дә, узып та китә. Бала өчен иң истә калачак кадерле мизгелләр – әти-әнисе белән бергә табигатьтә уздырган көннәр. Санаулы гына булса да, бик кадерле алар. Гомергә истә кала – җанга үтәрлек суыкларда җылыта, авыр чакларда көч бирә торган кичерешләр бүләк итә... Мин шулай саныйм. Ә сез ни уйлыйсыз?

Эльза НӘБИУЛЛИНА әзерләде.

«УЛ КАЙЧАКТА МИННӘН ЗИРӘГРӘК...»



Салават МИҢНЕХАНОВ,
җырчы;
гаилә стажы – 5 ел;
кызы Мәдинәгә – өч ай.

Ир-ат һәм хатын-кыз. Бер үк галәмгә без бит очраклы гына эләкмәгән... Шулай булгач, нигә соң бер-беребезне күп вакыт аңламыйбыз? Гамәлләребезне, теге яки бу адымыбызны, әйткән сүзләребезне... Үзара тартылуны «җиңеп», арага каршылыклар керә дә куя... Ә ир-атлар үзләре бу хакта ни уйлый икән? Сүзне аларга бирик.

1 Иң элек хатын-кызның нәрсәсенә игътибар итәсез: киеменә, буй-сынына, күзләренә, чәченә...

– Кеше 95 процент мәгълүматны күзе белән кабул итә. Аннары колак белән, борын белән... Әлбәттә, башта тышкы кыяфәткә игътибар итәсең. Нәрсә генә дисәк тә, башта киемгә карап каршы алалар.

2 Хатын-кызның кайсы сыйфатларын гафу итәргә була?

– Нәрсә өчендер сине битәрләвендер, бәлки? Тик моңа күп вакыт ир-ат үзе гаепле була. Хатын-кызга ялгыш та бер начар сүз әйтергә, кул күтәрергә ярамый, шуннан башлана... Ул аны гомер буе иренең исенә төшерәчәк, мең кат үкендерәчәк. Ирне исә бу адымга шайтан котырта. Гадәттә, күп очракта салып кайткан чагында шулай ялгыша ул... Гомумән, гаиләдә проблемалар ике сәбәп аркасында чыга дип саныйм, берсе – исерткеч эчемлекләр, икенчесе – хыянәт. Аракы эчү дә, зина кылу да – хәрам. Мәңгелек утта янасын белгән килеш минутлык бу ләззәтләргә ризалашу – җүләрлек.

3 Ә нәрсә өчен бик якын хатын-кызны да гафу итмәс идегез?

– Хыянәтне! Аны ир-ат та гафу итми, хатын-кыз да... Хыянәтне ничек гафу итеп булсын инде?! Ул минем башыма да сыймый. Син яраткан, фәрештә урынына күргән хатын-кыз бу адымга барсамы? Дөресен әйткәндә, бу хакта уйлыйсым да килми... Әйе, бәлки, кичерүчеләр дә бардыр. Менә андый кешеләрнең җавабын тыңлау кызык булыр иде. Ике арада торган бу киртәне ничек узып була икән соң? Тик алар инде кабат гаилә була алмыйдыр...

4 Хатын-кызлар икегә бүленә: ир-атны илһамландыручы алиһәләр һәм өйдә аның өчен комфорт тудыручы хуҗабикәләр. Сезгә аның кайсы якынрак?

– Хатын-кызлар шулай бүленәмени, белмәгән идем... Сәеррәк булу. Минемчә, аларда бу сыйфатларның икесе дә булырга тиеш. Комфорт кына кирәк булса, мин бит өй җыештырырга акча түләп тә кемнедер яллый алам. Буйдак чакта шулай эшли идем дә. Бер хатын-кыз 1 мең сумга фатирымны җыештырып, кием-салымымны юып, үтүкләп китә иде. Ә син яраткан хатын-кыз ул бит башка! Илһамландыра да ул, комфорт та тудыра, кайбер чакта ачуыңны да чыгара...

5 Ир кеше өчен аның хатыны дус та була аламы?

– Әлбәттә! Без Гүзәлем белән беренче чиратта дуслар. Безгә бергә рәхәт. Дустыңа таянырга була. Ул сине беркайчан авыр чагыңда ташламый.

6 Хатыныгызга ничек тәкъдим ясаганыгызны хәтерлисезме?

– Самолетта булды ул. Дөрес, мин уйлаганча ук килеп чыкмады. Гүзәлемнең «Ай-һай, карашларым» дигән клибын күргәнегез бармы? Хәтерләсәгез, анда ике урынлы самолетта очабыз без. Менә шул вакыт тәкъдим ясадым мин аңа. Күктә! Әмма ул минем бер сүземне дә ишетмәде... Аңлавын аңлады – анысын күзеннән күрдем, тик җавабы булмады. Пропеллер тавышы бик көчле булып чыкты. Мин исә анысын исәпкә алып бетермәгәнмен... Аның каравы, кызык итеп искә алып сөйләргә була. Ә танышу... Мин Азнакай мәдәният идарәсендә эшләдем. Ә Гүзәлем – Әлмәтнекендә. Чаралар үткәргәндә җырчыларны да чакыра башладым. Гүзәлем дә җырлый, ул да килә иде. Әмма аңа башкача күз белән каравым Мисырга клип төшерергә баргач булды. Бергә барырга аңа үзем тәкъдим иттем. «Клип төшерәсең килмиме? Оператор төркеме өчен чыгымнарны икегә бүләр идек», – дидем. Ул ризалашты. Тугыз көн эчендә ике клип төшердек. Көне-төне, хәтта йокламыйча да эшләдек. Минем «Җаным белән ант итәм» җырына төшерелгән клипта ул төп герой булды. Ә мин – аныкында. Шунда мин аның никадәр тырыш булуына игътибар иттем. Бу яктан ул минем әнигә охшаган. Безнең яшь аермасы – 13 ел. Минем әти дә әнидән 12 яшькә зуррак. Бәлки, мин бу яктан әтигә охшарга тырышканмындыр. Аннан һәрнәрсәнең үз вакыты – никах сәгате кайчан сугасын Ходай үзе генә белә. Гүзәлемне шулай таптым... Ә тырышлыгы, булдыклыгы, тәвәккәллеге мине Мисырда, чыннан да, шаккатырды! Машина йөртә белми, әмма: «Кирәк!» – дигәч, «Шевроле Импала»га утырды да, китеп барды. Скутер белән дә шулай булды. Беренче тапкыр

утыруы иде, тик «белмим», «куркам», «миннән булмый» димәде – нәрсә кушсак, шуны эшләде.

7 Ир кеше хатын итеп әнисенә охшаган кызны сайлый диләр, шулаймы?

– Ул әнигә охшаган дигән сүзне әйттем инде. Икесе дә ирне ир дип зурлап, гаиләдә ир кеше баш булырга тиеш дип яшиләр. Әни җитәкче урыннарда эшләсә дә, безнең өйдә әти баш иде. Гүзәлемнең гаиләсендә дә шулай булган. Әни белән бик дус алар. Гел шалтыратышып торалар, берәр сәгать сөйләшәләр. Уллар гына үстергәч, әни һәрвакыт кызы булуын теләгән – киленнәрен ул шуңа да якын итә. Аның каравы, барлык оныклары кызлар хәзер.

8 Хатыннары ирләреннән күбрәк мал тапкан гаиләләр бар. Ир кеше бу очракта үзен ничек тотарга тиеш?

– Хатын-кыз үзен табучы итеп хис итеп, өстенрәк тота икән, мондый гаиләдә иргә бик рәхәт булмый инде. Ир кешенең табигате шундый бит – ул гаиләдә баш, хуҗа булырга тиеш. Мин дә Гүзәлемнең телефонында «Хуҗа» дип язылган... Ә хатыны хуҗага әйләнсә, ул ирнең инде, минемчә, өйгә дә кайтасы килми. Йә ул балыкка дип чыгып китә, йә гаражына китеп югала... Мондый гаиләләр танышларым арасында да бар – йортта бөтен нәрсәне хатыннары хәл итә. Үзен, күңелен аңлаган кешене ирнең бу очракта читтә эзли башлавы да бик мөмкин.

9 Гашыйк булуын хатын-кыз башлап үзе белдерүгә ничек карыйсыз?

– Әйбәт карыйм. Ни генә дисәк тә, без барыбер хатын-кыз үргән җәтмәгә эләгүчеләр генә. Күзгә күренмәс ымнарны башта алар җибәрә, үзләренә таба адым ясарга әкрен генә безне алар этәрә... Тик хисләрне беренче булып ачыктан-ачык белдерүне генә кабул итеп бетереп булмый. Минем белән дә булды андый хәлләр. Бер кыз белән шактый дуслашып киттек. Әмма ул моны үзенчә аңлаган: безне инде очрашабыз дип кабул иткән. Һәм ул кинәт үзгәрде. Сөйләшүенең югарылыгына кадәр. Берәү кубызына да биергә җыенмый идем, билгеле... Шуңа да, юк, бу мине канәгатьләндерми, әйдә, саубуллашабыз, дидем. Соңрак аңладым – өендә күреп үскән тәртипне кабатларга теләгән. Ул ир белән хатын арасында шундый мөнәсәбәт кенә була дип белә торгандыр: берәү куша, икенчесе – үти.

10 Хатын-кызларның үзегезнең кайсы якларыгызга игътибар итүне көтәсез?

– Без бит көн саен үзгәрәбез: Гүзәлем дә, мин дә. Хәтта сезгә җавап биргәндә дә күңелемдә ниндидер үзгәрешләр бара: бу сорауларның күбесе хакында моңарчы уйланганым юк иде... Бала тугач, мин аны хәзер бөтенләй башкача кабул итәм. Ул да мине шулайдыр... Көн саен Гүзәлемә кызыбыз өчен рәхмәт әйтәм. Мәдинәне 15 минут күтәреп йөрсәм дә, кулымның җегәре китә, ә ул иртәдән кичкә кадәр аның белән... «Син ничек шулай булдырасың?» – дип аптырыйм. Минем хәлемнән килмәс иде...

11 Ир-атны артык чибәр һәм көчле хатын-кызлар куркыта, диләр. Бу, чынлап та, шулаймы?

– Белмим... Кайдан чыккан сүз бу? Гүзәлемнең нинди көчле икәнен алдарак сөйләгән идем. Мине бит ул, мәсәлән, нәкъ шул ягы белән җәлеп итте дә.

12 Ир-ат белән хатын-кыз икесе ике галәмнән икәне билгеле инде. Кайчакларда аларның бер-берсен аңламаулары шуннан килеп чыга да.

– Шундый очрак булды. Бер аферист аркасында шактый зур акчалар югалттым. Хәзер ул кеше инде төрмәдә утыра... Шактый авыр матди хәлдә калдым. Туган көнем тирәсе иде ул. Иртән уянып күземне ачсам – янымда тартма. Шунда ук аңладым – телефон! Һәм нинди әле! «Шундый кыйммәтле телефон алдым дип кенә әйтмә!» – дим Гүзәлемә. «Әйе, алдым!» – ди. «Нигә?» – дигәнемне сизми дә калдым. «Беләсең бит...» – дип өстәмәдем өстәвен... «Борчылма, мин ул акчаны үзем эшләдем», – ди. Сөендерергә теләве күңелле булды, әлбәттә. Әмма барыбер аңламадым: юрганга карап аякны сузар чакта соң...

13 Хаклы икәнегезне яхшы беләсез, әмма хатыныгызның үз туксаны – туксан, хаклык аның ягында дип саный.

– «Ник син миңа моны әйтмәдең? Моңа игътибар ит әле дип, алдан кисәтә ала идең бит!» – дим кайчак Гүзәлемә. «Әйттем, тик син мине ишетмәдең», – ди ул. Ә бит шул минутта ул миннән акыллырак уйлаган, зирәгрәк булган. Хатын-кызны ишетергә, аның сүзенә колак салырга кирәк безгә кайчакта. Ә иҗатта менә аны күбрәк тыңлыйм. Ул бит миннән яшьрәк, заман сулышын яхшырак тоя. Кайбер вакыт «ВКонтакте»дагы плейлистын карыйм да: «Ул трекларны миңа да җибәр әле», – дим. Җыр сатып алганда да күбрәк аның белән киңәшәм: «Бу җыр ошыймы сиңа?» – дим. Ошаса алабыз, «юк» дисә, баш тартабыз. Клипларны да хәзер күбрәк аңа төшерәбез.

14 Шундый очракны күзаллыйк әле: сез, ачыгып, арып-талып эштән кайтып керәсез, ә өйдә ашарга пешмәгән.

– Эштән кайтышлый мин гел шалтыратып: «Өйдә ашарга бармы?» – дип сорыйм. Кай көнне Гүзәлемнең: «Мәдинә бүген көйсезләнде, мин әле теш чистартырга да өлгермәдем», – дигән чаклары да бар... «Әзерләргә өлгермәдем шул», – дисә, «Нәрсә алып кайтыйм? Син ни телисең?» – дим. Керәм, алам, кайтам. Нишләп шуннан проблема ясыйм, ди? Мин үзем дә пешерергә яратам. Ә хатын-кыз эшләмичә өйдә генә утырса һәм ире арып эштән кайткан җиргә телевизор карап ятса – монысы инде бөтенләй башка мәсьәлә.

Бәйләнергә сәбәп эзләгән кеше исә аны барыбер таба ул: кайткан җиренә ашарга пешкән, табын корылган булса да, булмаса да.

15 Хатын-кызлар еш кына... бүләк сайлауда ялгыша...

– Гүзәлемнең миңа ошамастай бүләк биргәнен хәтерләмим. Ә мин... Мин берсендә 8 Мартка бөтенләй чәчәксез кайтып кердем. Озаграк эшләдек ул көнне, хәтердән чыккан. Үпкәләде... Миңа бик оят булды. Икенче көнне шундый матур чәчәкләр алып кайттым да бит... Тик ул бит инде икенче көнне иде! Моңарчы бездә бәйрәмнәр «бәйрәм» дип түгел, киресенчә, «эш» дип аталды. Яңа елда да, 8 Мартта да корпоративлардан бушамадык. Хәзер инде андый хәл булмастыр – хәләл чаралар алып баруга гына күчтек.



Тулысынча сайтыбызда: www.syuyumbike.ru



Әниләр колагына

Хатын-кызның сәламәтлеге үтә дә нәзберек. Аеруча яшүсмерлек чорында чәчәккә яңа бөреләнгән нәфис гөлне хәтерләтә ул. Кыз балаларның җенси җитлегү вакытында килеп чыгарга мөмкин булган проблемалар һәм аларны кисәтү юллары хакында онкогинеколог, гинеколог-эндокринолог Наталия АЛЕКСАНДРОВА белән сөйләшәбез.

Кыз баланың ана булу бәхетенә бала чагында, яшүсмерлек елларында ук нигез салына. Нәкъ менә шушы вакытта кызларда икенчел җенес билгеләре күренә башлый, ул җитлегү чорына аяк баса. Менструаль цикл башлана.

Әлеге чорда яшүсмерләрнең һәм аларның әти-әниләренең хатын-кыз табибына мөрәҗәгать итүләренең төп сәбәбе – күрем циклының дөрес булмавы. Нормада ул 21 көннән 35 көнгәчә булырга тиеш. Сәламәтлектә проблемалар булса, цикл йә озыная (кайчагында яртышар елга да сузылырга мөмкин), йә кыскара (күрем ике атна саен килә). Аның күләме дә үзгәрергә мөмкин, гадәттә, ул күп килә һәм озакка сузыла (җиде көннән артык).

Күп очракта бу гормональ проблемаларга бәйле. Җенси системаның тиешенчә эшләвен көйләүче орган кешенең баш миендә урнашкан. Ул – гипофиз һәм гипоталамус. Калкансыман бизнең сәламәт булмавы, артык авырлык, шикәр диабеты да менструаль циклның бозылуына китерә ала. Аның сәбәбе авыз-борын куышлыгындагы даими ялкынсыну, ашкайнату системасындагы авырулар, йөрәк чирләре дә булырга мөмкин. Анемия, гәүдә арыклыгы, катгый диета, авыр физик күнегүләр, спортның авыр төрләре белән шөгыльләнү дә күрем циклының бозылуына яки җенси җитлегүнең тоткарлануына бер сәбәп булып тора.

Яшүсмер кызларда күремнең авырттырып килүе дә еш күзәтелә. Ул исә шушы яшьнең физиологиясе белән бәйле. Җенси системаның менә-менә эшли генә башлаган мәле, һәм ул әле тиешенчә формалашып та бетмәгәнлектән, кече оча сөягендә урнашкан органнарда спазмнар күзәтелә. Яшүсмер кызларның аналык муентыгы да җитлеккән хатын-кызларныкына караганда озынрак, авыртуның бер сәбәбе ул да булырга мөмкин. Җенес органнарына якын урнашкан башка әгъзаларның сәламәт булмавы аркасында да эч авырта. Шулай ук умыртка баганасының сәламәтлеге дә бик мөһим. Умыртка баганасы кәкрәйгәндә, кече оча сөяге органнары да теге яки бу якка авышып, кан әйләнеше бозылырга һәм шуның аркасында күрем вакытында авырту сизелергә мөмкин.

Әти-әниләр өчен иң беренче киңәшем: авыртуны игътибарсыз калдырмагыз. Бәлки, баланың эче чынлап та спазмнар аркасында гына авыртадыр. Ләкин кайчагында бу берәр җитди авыру белән дә бәйле булып чыга. Көчле авыртулар кабатланып торса, табибка күренү мәҗбүри.

Яшүсмерләрдә ялкынсыну процесслары да очрый. Яшь кызларда башлыча аскы җенес органнары ялкынсынуы – вульвовагинит күзәтелә. Аның да сәбәпләре төрлечә: сидек юллары авырулары, цистит, тамак-борын чирләре, иммунитет түбән булу, паразитлар... Кыз бала өчен туңу һәм артык эсселәү дә начар. Яшьләр яратып кия торган синтетик тар киемнәр дә яшүсмерләрнең сәламәтлегенә шактый ук зыян сала. Синтетик кием аркасында тән суламый, тар кием кан әйләнешен тоткарлый.

Кыз баланы гинекологка беренче тапкыр 9-10 яшендә күрсәтәләр. Әни кешенең бурычы – баланы физик һәм рухи яктан моңа әзерләү, табибка күренүнең әһәмиятен аңлату. 15 яше тулмаган кыз балаларны гинекологка күрсәтү өчен әти-әнисенең ризалыгы булу мәҗбүри. Кыз балалары булган әниләргә киңәшем: ике арада ышаныч һәм аңлашу булсын. Бала үзен борчыган проблемаларны сезгә ышанып сөйли алганда гына моңа ирешеп була.



ПРОФИЛАКТИКА ОНКОЛОГИЧЕСКИХ ЗАБОЛЕВАНИЙ

**Основное направление клиники – профилактика онкологических заболеваний.
Нами разработаны оптимальные программы ежегодного обследования мужчин и женщин, направленные на раннее выявление начальных стадий онко-патологии, с целью своевременного начала лечения.**

Комплекс «Женский онкоскрининг»
- Консультация гинеколога
- Мазок на степень чистоты и онкоцитологию
- УЗИ органов малого таза
- Консультация онколога-маммолога
- УЗИ молочных желез
- Забор крови + анализ на онкомаркеры (СА-125, СА-15-3, СА-19-9, СА-72-4, SCC, АФП, РЭА)

Казань, Сибирский тракт, 23. Тел.: 8 (843) 215-00-03.
Часы приема: пн.-пт. с 8.00 до 20.00; суббота: с 9.00 до 18.00; воскресенье – выходной.

Лицензия: ЛО-16-01-006069 от 13 июня 2017 года.

РЕКЛАМА

ИМЕЮТСЯ ПРОТИВОПОКАЗАНИЯ. НЕОБХОДИМА КОНСУЛЬТАЦИЯ СПЕЦИАЛИСТА



Әгәр аркаң авыртса...

«Кайбер пациентларыбыз ишектән керүгә: «Аркам авырта, нишләргә икән?» – диләр. Билләрен тоткан килеш, шунда ук могҗизалы сүз ишетергә өметләнәләр. Әмма бар да алай җиңел, гади генә түгел шул», – ди «Остеопат» медицина үзәге белгече, югары категорияле табиб-терапевт Илфат ГАЛИЕВ. Дәвалау алымнарын, нинди дарулар кулланырга кирәклеген сайлау өчен башта чирнең этиологиясен, ягъни аның ни сәбәпле килеп чыкканын ачыклау кирәк. Түбәндә табиб авыртуга китергән төп сәбәпләрне атый.

Аркада барлыкка килгән авыртуларның иң еш очраган сәбәбе – протрузия һәм умырткалар арасындагы кимерчәктә бүсерләр. Бүсер үзе авыртмый, авырту ул умырткадагы нерв очларын һәм кан тамырлары бәйләмен кысканлыктан барлыкка килә. Авыру акрынлап көчәя һәм мускулларның тартышуын – спазмны китереп чыгара. Бу исә гәүдәнең теге яки бу өлешенең хәрәкәтләнүен чикләргә дә мөмкин.

Умырткалар арасындагы кимерчәктә бүсерне ниләр китереп чыгарырга мөмкин:

- гәүдәнең төз булмавы;
- имгәнүләр;
- мускул корсетының көчсезлеге;
- йогышлы чирләр;
- нәселдәнлек.

Табиб-остеопатның бурычы – һәр авыруга дәвалауның аңа гына туры килгән ысулын сайлау. Моның өчен ул авыртуга сәбәпче була алган барлык факторларны да күз уңында тотарга тиеш. Гадәттә, табиб-остеопат чирне организмдагы бер кимчелек, җитешсезлек дип кабул итә. Шул җитешсезлек булган урынны тәгаен табарга, ачыкларга, дәвалау билгеләргә кирәк. Заманча тикшеренүләр күрсәткәнчә, арка авырта икән, гадәттә, ул бер сәбәп аркасында гына килеп чыкмый – алар берничә була.

Умыртка баганасында бүсер барлыгын белгәч, халык медицинасы ярдәмендә генә дәваланырга өметләнүдән шунда ук баш тартырга кирәк: бу очракта аның сәламәтлек өчен зыянлы булуы бик мөмкин. Шул ук вакытта, халык арасындагы «бүсердән хирург пычагы астына ятмыйча котылып булмый» дигән сүз дә дөреслеккә туры килеп бетми. Һәр очракта да алай түгел. Консерватив юл белән дәвалау да авыртуны баса, тукымаларның ялкынсынуын баса, умыртка баганасының хәрәкәтчәнлеген кире кайтара. Бу максатларга исә остеопатия ярдәмендә ирешеп була. Ул йөрү-хәрәкәтләнү аппараты һәм эчке әгъзалар арасындагы үзара бәйләнешне кабат җайга сала ала.

Тәҗрибәле остеопат хәтта ике-өч сеанс ярдәмендә дә озак вакытлар борчыган авыртудан, мускулларда һәм сеңерле бәйләвечләрдәге киеренкелектән коткара, умыртка баганасын, зыян күргән тукымаларны элеккеге хәленә кайтара. Әмма остеопатларга могҗизачы дип тә карарга кирәкми. Әйтик, нык азган сколиозны бер генә табиб та дәвалый алмый. Тик бу – әлеге кешегә берничек ярдәм итеп булмый дигән сүз түгел. Умыртка баганасы тирәсендәге мускуллар белән эшләгән очракта авыруның хәлен җиңеләйтеп булачак.

Табиб киңәше

Аркада авыртулар килеп чыкмасын өчен нишләргә?

- Иң беренче чиратта – гәүдәне төз тотарга тырышырга һәм арка мускулларын ныгытырга кирәк.
- Җәяү күп йөрү, хәрәкәтләнү, гимнастика ясау, йөзү, артык зур булмаган нагрузкалар остеохондрозга һәм аның белән бәйле өзлегүләргә каршы тора алу сәләтен арттыра.
- Туңудан, кинәт бөгелеп, җирдән нидер алулардан сакланырга кирәк.
- Авыр әйбер күтәрергә туры килгәндә, аны бик саклык белән – чүгәләгән килеш кенә күтәреп алырга кирәк: болай эшләү авырлыкны умыртка баганасына тигез итеп бүләргә ярдәм итә.

Лицензия: ЛО-16-01-006617 от 19 февраля 2018 года.
Медицинский центр
ОСТЕОПАТ
г. Казань, ул. Ф.Амирхана, д. 18/41. Тел.: 8-962-559-02-56
ИМЕЮТСЯ ПРОТИВОПОКАЗАНИЯ. НЕОБХОДИМА КОНСУЛЬТАЦИЯ СПЕЦИАЛИСТА
РЕКЛАМА





Фото: Наилә Галиева

Ландшафт дизайны

Ландшафт дизайны, икенче төрле ландшафт архитектурасы – өч юнәлешнең бер ноктада очрашуыннан туган сәнгать ул. Беренчедән, бу – архитектура, төзелеш, проектлаштыру юнәлеше; икенчедән – үсемлекләр дөньясы; өченчесе – фәлсәфә, тарих, чөнки һәр стильнең үз фәлсәфәсе, үз тарихы. Ландшафт дизайнерының максаты – участокны уңайлы да, матур да һәм үзенчәлекле дә итү. Килешәсездер, моңа белем һәм тәҗрибә белән генә ирешеп була. Наилә ГАЛИЕВА – шушы өлкәдә күп еллардан бирле эшләүче практик дизайнер. *(Фотоларда аның эшләре.)* Йорт янында оҗмахка тиң үз бакчаңны булдыру серләрен ул безнең белән дә уртаклашырга булды.



Нәрсәдән башларга?

Ландшафт дизайны кәгазь белән каләмнән, метрлы тасмадан башлана. Иң беренче эш – метрлы тасма ярдәмендә участокны тулаем үлчәп чыгу. Моны көздән эшләсәң яхшырак. Кыш дәвамында участокның планын төзергә, нинди стильдә булуын билгеләп, кирәкле үсемлекләрне сатып алырга вакыт җитәрлек калачак. Көздән өлгермәсәгез, яз көне беренче мөмкинлек белән үк бу эшне башкарырга кирәк. Үлчәгән вакытта участокта булган бар нәрсә картага төшерелә. Йорт ничек урнашкан, мунча, хуҗалык корылмалары, машина куя торган бетонланган мәйдан, сукмаклар – берсе дә игътибардан читтә калмасын. Балалар өчен уен яки спорт мәйданчыгы булдырырга уйлыйсыз икән, картага аларын да төшерегез. Ял итү, барбекю зоналары да исәпкә алынсын. Барбекю зонасын йортка капма-каршы почмакта ясасаң яхшырак. Аны куаклар белән каплап, кеше күзеннән яшерен бер уңай почмак рәвешендә кору әйбәт булыр.

Исәпләргә уңайлылык өчен, картаны 1:100 яки 1:50 масштабында төзү отышлы. Шулай ук көньяк белән төньякны билгеләргә дә онытмагыз. Бу күләгәнең ничек ятуын билгеләү, үсемлекләрнең кайсын кая утыртасын ачыклар өчен мөһим.

Нинди стильне сайларга?

Кайсы стильне сайлыйсын һәркем үзе хәл итә. Бу участокның мәйданына һәм кайда урнашуына да бәйле, хуҗаларның зәвыгына да ярашырга тиеш. Шулай ук финанс мөмкинлекләрен дә исәпкә алырга туры килә.

Инглиз, кытай, прованс, япон, рус утары, колониаль, мавритан стильләре – борынгы тарихи стильләрдән санала. Заманча стильләрдән альп, хай-тэк, минимализм, модернны атарга була. Табигый яки коттедж стилендә корылган бакчалар да бар.

Авыл стиле, ягъни кантри да бик популяр. Бакчаны шушы стильдә корганда талчыбык читән, кое бурасы, арба, агач тәгәрмәч, балчык чүлмәкләр кулланырга мөмкин. Үсемлекләрдән – петуниялар, ромашкалар матур булачак.

Кемнәрдер, бәлки, коры елга темасын үз итәр. Чуерташлардан бормалы «инеш» ясап, «ярларын» су буйларында үсә торган үсемлекләр – саз ирислары, камышны хәтерләтүче кыяклы үләннәр, йомры ташлар белән бизәргә була. Агачларны да шуңа карап сайлыйсың.

Чирәмлек – бакчаның үзәге

Бакчаны нинди генә стильдә корырга теләсәң дә, газонсыз булмый. Еш кына ул композициянең үзәген тәшкил итә. Газонның зурлыгы әле бакчаның планын сызганда ук ачыклана. Гаиләгез белән бадминтон уйнарга яратсагыз, аны зуррак итәргә кирәк, кояшта кызынып, китап кына укып ятарга икән – диаметры 3-4 метр булган чирәмлек тә җитә.

Газонны тоташ таш сукмак кистереп чыкмаса матуррак. Андый сукмак түшәгәнче, адымлысы отышлы – эре плитка яки зуррак яссы ташларны газонга батырып чыксаң, чирәмне кыркыган вакытта да уңай була.

Сукмаклар турында сүз чыккач, аларның бакчаны зоналарга бүлүен дә истә тотарга кирәктер.

Үсемлекләр сайлыйбыз

Теләсә кайсы бакчаның төп бизәге – чәчәкләр – яз гөлләре, күпьеллыклар, чәчәк атучы куаклар, мәңге яшел ылыслылар... Бакча ландшафты белән шөгыльләнә генә башлаучы дизайнерларның яки һәвәскәр бакчачыларның төп хатасы – бакчага берьюлы бик күп төрле үсемлекне берәр-икешәр данәдә генә утыртып чыга. Артык чуар була, бакчаның тәртибе югала.

Иң отышлы вариант – үзегезгә ошаган берничә төрле үсемлекне төркемләп утырту. Бу куакларга да, күпьеллык чәчәкләргә дә кагыла. Сукмак читләтеп бер генә төрдәге һәм бер генә төсле спиреялар утыртып чыгарга була. Ул матур күренә, участокны зоналарга бүләргә дә ярдәм итә. Балалар мәйданын лапчатка белән аерырга мөмкин.

Чәчәкләрне күпереп торган болыт рәвешендә утырту ысулы да матур. Астильба, ромашка, хосталардан торган «болыт»ны бакчаның берничә җиренә утыртыгыз. Шулай иткәндә, бакчаның бөтенлеге сакланыр.

Гөлләр сайлаганда бер мөһим әйберне истә тотыгыз: бакча гел чәчәккә күмелеп утырсын. Иртә язда ул – суганчалы чәчәкләр (лалә, нәркисләр), соңга таба – кыяклы үләннәр, хосталар, мул чәчәкле куаклар, спирея, лапчатка, җәен – күпьеллыклар, соңрак чәчәк ата торган гортензияләр. Аның купшы төрләре ноябрь аена кадәр чәчәк атарга мөмкин. Өстәвенә, алсу төстәгеләре гел үзгәреп тора. Язгы суганчалы гөлләр чәчәк атып бетергәч, яфраклары корып, «йокы халәте»нә китүен дә онытмагыз. Аларны соң «уянучы», эре яфраклы хоста, астильбалар янына утырту отышлырак.

Үсемлекләрне сатып алганда бик игътибарлы булу сорала. Яфракларда берниндн дә пәрәвез, ак кунык, сабакларда, яфрак төпләрендә черек булмасын. Чүлмәктә үскән үсемлекләр яңа җиргә күчереп утырткач, тизрәк тернәкләнә һәм аларны яз көне генә түгел, көзен дә утыртырга була. Ә тамыры ачык килеш сатылганнарын фәкать яз көне генә утырталар. Аеруча җимеш агачларын.

Никадәр генә кызыктырсалар да, безнең киңлекләрдә җылы як үсемлекләре үзләрен рәхәт хис итмәс. Шуңа күрә салкынга чыдам булганнарын сайларга тырышыгыз. Болар 1, 2, 3, 4 нче зонага керүче үсемлекләр.

Ылыслы бакча

Күпләр ылыслы үсемлекләрне ярата. Бакчада ылыслы үсемлекләрдән торган бер почмак булдырып, аны зур ташлар, кәрлә наратлар белән бизәргә була. Хәзер сатуда кыска буйлы декоратив наратлар бар. Алар, күп дигәндә, метр ярым гына булып үсә, кояшлы урынны, комлы балчыкны үз итә. Җәен дә, кышын да матур күренә. Декоратив ылыслы үсемлекләрнең җәен – яшел, көзен сап-сары төскә керүче төрләре дә бар.

Гомумән, бакчага үсемлекләр сайлаганда, аларның яз-җәй көннәрендә генә түгел, кышын да матур булганын сайларга кирәк. Яфрагын койган агачлар да ак кар фонында күркәм бер скульптурадай күренә бит.

Тын почмаклар

Әйткәнемчә, бакча матур гына түгел, уңайлы, җанга рәхәт бер җир булырга да тиеш. Эштән соң утырып ял итәргә, табигатьне тыңларга, баеп баручы кояшка карап хозурланырга без бакчага чыгабыз. Шуңа да берничә урынга эскәмияләр урнаштыру зарур. Аның берсе – тын аулак урынга, берсе йортка яки ерактагы урман-болыннар белән хозурланыр өчен җайлы урынга куелсын. Бер эскәмияне керү юлына урнаштыру яхшы, килгән кунакларга әйберләрен куеп тору өчен дә хезмәт итәр ул. Ә бер урынга, әйтик, канәфер куагы төбенә таган куярга була.

Бакчагызны нинди стильдә корсагыз да, нинди генә үсемлекләр утыртсагыз да, аны ашыкмыйча, уйлап эш итәргә киңәш итәм. Мәскәү бер көндә генә төзелмәгән кебек, ямьле бакча да бер көндә генә барлыкка килми.

Иң соңгы сүз итеп, СанПин нормалары белән дә танышып чыгу мөһимлеген искә төшерәсем килә. Аларны үтәү мәҗбүри.

Үзбәк самсасы



Самса – үзбәк милли кухнясындагы иң популяр ризыкларның берсе. Тәмле һәм туклыклы бу тәгамнең кайчан барлыкка килүе билгеле түгел, ләкин традицион үзбәк кухнясында ул инде үз урынын алган. Самса пешерү ысуллары күптөрле: әче камырдан да әзерлиләр аны, катлы камырдан да. Эчлеге дә төрлечә булырга мөмкин, формасы да. Аны парлы итеп тә пешерәләр, өчне яки дүртне бергә берләштереп тә... Хәер, пешерәләр дип кенә әйтү дә дөрес булмас, самсаны майда йөздереп тә кыздырырга мөмкин. «Әмма иң тәмле самсалар, әлбәттә, тандыр мичендә пешкәне», – ди «Хатын-кыз галәме»нең бүгенге кунагы – Үзбәкстан Республикасының Идел буе федераль округындагы консулы Фариддин әфәнде НАСРИЕВ. Самсаның башка пәрәмәчләрдән аерылып торучы төп билгесе – суган һәм куй мае (думба). Башка ингредиентлары төрлечә була ала, ләкин бу икесенең булуы мәҗбүри.
Билгеле, безнең тандырда пешерү мөмкинлеге юк, шуңа да газ мичендә (утын мичегез булса, шунда) генә пешерәчәкбез.
Иң элек катлы камыр ясап куйыйк.



Камыр өчен кирәк

- 1 кг он (азрак яки күбрәк китәргә мөмкин);
- 0,5 л су;
- 2 йомырка;
- 20 г тоз;
- камырны җәю өчен 200 г үсемлек мае һәм 0,5 кг терлекнең эч мае (бөер мае).

Итле фарш өчен кирәк

- 500 г куй яки тана ите;
- 250 г чистартылган суган;
- 100 г яшь терлекнең эч мае (бөер мае);
- тоз-борыч, зира, уылган кинза орлыгы.



Фото: Анна Арахамия

Эш барышы

- Онны иләп, тау кебек өябез. Бер савытка 2 йомырка сытып, су һәм тоз салабыз, яхшылап туглыйбыз. Онның уртасын чокырлап, әзер сыеклыкны агызабыз һәм төчегә генә камыр басабыз.
- Терлек маен табада эретеп, үсемлек маен кушабыз.
- Камырны дүрт тигез кисәккә бүләбез. Өстен тастымал белән каплап, бераз ял иттерәбез.
- Камырның һәр кисәген юка итеп җәябез. Җәемнәрнең өстен майлап, берсе өстенә икенчесен куябыз. Дүрт катын да бергә конверт сыман төрәбез, аңынчы һәр ягын яхшылап майлыйбыз. Тагын бер кат уклау белән җәеп, кабаттан майлыйбыз һәм бау сыман тәгәрәтеп төрәбез. Эчлекне әзерләгәнче, камырны 15 минутка суыткычка тыгып торабыз.
- Эчлек өчен итне кечкенә шакмаклап турарга яки чабарга кирәк. Эч маен бераз эрерәк итеп турасаң да була. Суганны артык эре итмичә турыйбыз.
- Ит белән туралган суганны кушабыз, тоз-борыч һәм тәмләткечләрне сибеп, яхшылап болгатабыз.
- Камырны 12–14 см зурлыгындагы юка җәем итеп җәябез. Кырыйларын тагын да юкарак итәргә тырышабыз.
- Камыр уртасына 2 аш кашыгы эчлекне салып, самсаны өчпочмак яки квадрат итеп төрәбез. Төргән ягын аска каратып, майлаган табага тезә барабыз.
- Өстен йомырка белән майлап, кыздырган күнҗет яки тмин орлыгы сибәбез.
- Самса 200 градус кайнарлыктагы мичтә 20–30 минут пешә.
- Ашларыгыз тәмле булсын!

Самсаны яшел үләннәрдән дә әзерлиләр.

Кирәк: 0,5 кг башлы суган; 100 г атланмай; берәр тотам укроп, петрушка, шпинат, кинза (үзегез яраткан үләннәрдән генә дә әзерли аласыз); тәменчә тоз һәм борыч.

Суганны – ярымбоҗралап, ә яшел үләннәрне шактый эре итеп турыйбыз. Казан төбендә атланмай эретеп, башта суганны җиңелчә генә кыздырабыз, соңыннан үләннәрне салып, томалап пешерәбез. Үләннең суты күп чыкканлыктан, аның бераз парга әйләнгәнен көтәбез һәм уттан алабыз. Эчлек суынгач, тоз-борыч салып болгатабыз.

Үләнле самсалар 200 градус кызулыктагы мичтә 15–20 минут пешә.



Матдәләр алмашын тизләтү өчен диетологлар көнгә биш тапкыр аз-азлап кына ашап торырга киңәш итә. Ләкин бүгенге тормыш ритмының үз кагыйдәләре. Ыгы-зыгы белән мавыгып, капкалап алу кирәклеген онытып җибәрәсең дә (икенче иртәнге аш яки өйләдән соңгы чәй), кичкә тамак ачып, күбрәк ашала. Без бүген тәкъдим итә торган рийет тамакны җиңелчә генә ялгап алу өчен иң кулай ризыкларның берсе. Рийет – эре текстуралы ит паштеты ул. Аны төрле иттән, хәтта балыктан да әзерләп була. Камилә ДИМӨХӘММӘТОВА исә рийетны тавык итеннән әзерләргә тәкъдим итә.

Рийет

Кирәк:

- тавыкның түш ите, янбаш өлеше һәм ботлары;
- 1 кишер;
- 1 яшел алма;
- 1 баш суган (без кызыл суган кулландык);
- 3 дәфнә яфрагы;
- 5 борчак кара борыч;
- сарымсак;
- тәмләткечләр;
- хуш исле үләннәр (розмарин һәм рәйхан).



Фото: Камилә Димөхәммәтова

Эш барышы:

■ Тавык итен тоз белән ышкып, утка чыдам савытка тезәбез. Шунда ук эре итеп туралган кишер белән алманы, түтәрәмләп бүленгән суганны, сарымсак (без 3 тырнак салдык), дәфнә яфрагы, тәмләткечләрне өстибез. 1 стакан су салып, мичкә тыгабыз. Ул 150 градус кызулыктагы мичтә 3-4 сәгать томалап пешерәбез. Мичтән алганда, ит таралып торырга тиеш. Суы кайнап бетмәсен өчен савытның өстен фольга белән капларга яки су өстәп торырга кирәк.

■ Итне мичтән алып, суынганын көтәбез. Яшелчәләрне һәм алмаларны аерым савытка салып, чәнечке белән изәбез яки блендерда издерәбез.

■ Чәнечке ярдәмендә итне җепселләргә аерып, сөякләреннән аралыйбыз.

■ Издерелгән яшелчәләр белән итне кушып, яхшылап болгатабыз. Теләсәгез, түбәнчә тоз өстәргә була.

■ Әзер паштетны пыяла банкаларга тутырып, суыткычка куябыз. Ул анда атна буе саклана ала.

■ Рийет – бөтен ярмадан пешерелгән ипи яки хлебецка ягып сыйланыр өчен бер дигән ризык. Тәмле дә, файдалы да.

Кучкар. Мәшәкатьле, катлаулы чор. Ләкин тоткан кыйблагыздан тайпылмагыз. Тәнкыйть һәм киртәләр – вакытлыча. «Чәнечкеле тимерчыбыкларны өзеп – йолдызларга!» – бу айда тормыш девизыгыз әнә шул булсын.

Үгезбозау. Акча ягын җайларга шәп кенә мөмкинлек чыгарга тора. Шулай да бу айның энергиясе катлаулы, юк кына нәрсәләрдә дә аяк чалучылар очрар. Планнарыгызны иң якыннарыгыз белән генә бүлешегез.

Игезәкләр. Гадәти генә әйберләрнең гадәти булмаган мәгънәләрен таба торган ай. Ябык ишекләрне ачтырырга тырышмагыз, аларны әйләнеп узу юлларын эзләгез. Ышаныгыз: бу айда әллә нинди көтелмәгән нәтиҗәләргә ирешерсез.

Кысла. Айның беренче яртысы ыгы-зыгылы булыр. Мәшәкатьләр күп өлкәдә сагалый, шуңа да алдан ук үзегезне сабырлыкка өндәгез. Ләкин куанычлы очрашулар һәм көтелмәгән керем дә көтелә.

Арыслан. Яхшылыкка ышанучыларга уңыш ешрак елмая. Бу айда үзегезне бәхетнең тәхетендә дип хис итәрсез – тормышыгызда куанычлы вакыйгалар булыр. Мәхәббәтме ул, күптәнге хыялның чынга ашуымы – анысы мөһим түгел.

Сөмбелә. Нindидер зур бер эш көтелә, хәтта туганнарыгызның ярдәме кирәк булуы бар. Керем белән чыгымнарны кат-кат исәпләргә туры килер. Катлаулы чор булса да, ахыры куанычлы тәмамланыр.

Бизмән. Көтелмәгән бер очрашу ел буена җитәрлек уңай эмоцияләр бирер. Бу айга зур эшләр планлаштыра аласыз, чөнки нәкъ менә шушы айда югары көчләрнең ярдәмен тоярсыз.

Чаян. Көчләрегезнең кимеп киткән чагы. Теләсә нинди яңалыкка сак карагыз. Ялган мәгълүматка ышанып, дөрес юлдан тайпылу ихтималы бар. Элегрәк җибәргән хаталарның калкып чыгуы мөмкин.

Укчы. Авыр ай. Юлыгызда үзегезгә карата начар мөнәсәбәттә булган кешеләр очравы мөмкин. Артык ышанучан сез, төп башына утыртуларыннан сакланыгыз. Бәхәскә керүдән дә качыгыз.

Кәҗәмөгез. Без капчыкта ятмый – моңа тагын бер кат инанырга туры килер. Шуңа да якыннарыгыздан яшереп гамәл кылмагыз. Үҗәтлегегез аркасында нindидер файдалы эштән колак кагуыгыз бар.

Сукояр. Күп нәрсәдә үзгәрешләр булыр. Яңа эш башлар өчен дә шәп вакыт. Моңарчы күп эшләрдә кыюсызлыгыгыз аяк чалып килде. Бу айда исә Марсның йогынтысы бик көчле, ул сезгә тәвәккәллек өстәр.

Балык. Үзегезне тәгәрмәчтәге тиен кебек хис итәрсез. Бөтен эш берьюлы өелгәндәй булыр. Сәламәтлегегезгә зыян салмас өчен, иң мөһимнәрен генә сайлап эшләгез. Ай ахырында иркен сулыш алырсыз.

зирәк кешедән – зирәк сүз

ДУСЛЫК КАЙЧАН СЫНАЛА?

Урмандагы каен төбендә бер бөҗәк – тычкан уты яшәгән. Ул бик тә җырларга яраткан. Кичке шәфәкъның соңгы нурлары наратлар артына төшеп югалганда, ул дөньяның матурлыгы турында җырлаган. Аны яратучылар күп булган. Ләкин ул бер нәрсәне генә белмәгән: урмандагыларны аның җырлары түгел, ә җырлаганда зөбәрҗәттәй балкуы сокландырган.

Көннәрдән бер көнне агач төбе янына бер малай килеп утырган да, карашын батып баручы кояшка текәп, тынып калган. «Матурмы?» – дип сораган аннан бөҗәк, ал шәфәкъкка ымлап. «Матур!» – дигән малай. «Бүген кояш мәмрәп пешкән чия кебек», – дигән бөҗәк. Малай баш каккан. Бу һәр көнне шулай дәвам иткән: бөҗәк җиһанның гүзәллеген җырлаган, ә малай офыкларны күзәткән.

Беркөнне бөҗәкнең зөбәрҗәт ташыдай балкуы беткән. Кайчан гына аны күкләргә чөючe дусларының: «Ул буш пыяла бит хәзер», – дип көлүен ишетү аңа бик авыр булган. Тыңлаучысы булмагач, җырлаудан да туктаган. Ләкин теге малай гына кич саен каен төбенә килеп, аны көткән. Бөҗәк түзмәгән, малай янына чыгып утырган. «Мин сине шундый сагындым. Ник җырламыйсың?» – дигән малай. «Син күрмисеңмени?» «Юк! – дип җавап биргән малай. – Дөньяның матурлыгы турындагы теге җырыңны җырла әле. Син табигатьне шундый матур тасвирлыйсың, бер генә күрәсе иде шуларны». Шунда гына бөҗәк аның дөньяны күрмәвен, тын да алмыйча бары тик аның җырлавын гына тыңлавын аңлаган. «Әйдә, мин сиңа дуслык турында җырлыйм!» – дигән ул, талантына сокланучы булу сөенеченнән балкып. Шушы сүзләрне әйткәндә, ул кабат зөбәрҗәт кебек җемелдәгән. «Дуслык турында беркайчан да җырлаганың булмады бит», – дигән малай. «Моңарчы минем чын дустым да булмаган икән», – дип җавап биргән бөҗәк.

* * *

Дустың өчен үлүе авыр түгел, аның өчен үләрлек дусны табуы авыр.

Эдвард Булвер-Литтон (инглиз язучысы).

Бу дөньяның барлык шөһрәте бер чын дуска торырлык түгел.

Франсуа Вольтер (француз язучысы, философ).

Чын дус син хаклы булмаганда да синең белән була. Хаклы чакта яныңда болай да кеше күп.

Марк Твен (Америка язучысы, журналист).

Хатыны белән тату яшәмәгән кешене дустың итмә.

Пифагор (борынгы грек философы, математик).

Куркак дус дошманнан куркыныч. Дошманнан сакланасың, ә дуска таянасың.

Лев Толстой (рус язучысы, фикер иясе).


Үзенә мохтаҗлыгыңны үзе белеп килгән кеше – чын дус.

Жюль Ренар (француз язучысы, драматург).

«Хатын-кыз галәме» сәхифәсен әзерләүче – Лилия ГӘРӘЕВА







ҖИҢҮНЕ СУРӘТЛӘГӘН ҖИҢҮЧЕ

«Илнең кайсы чорында яшәр идегез?» дигән сорауга җавап биреп, бүгенге көн кешеләренең күбесе торгынлык чорын, ә кайберләре... хәтта Сталин репрессиясе дәверен дә сайлап алдылар. Ә бит бу елларның барысы да таныш булган аңа. Үзгәртеп кору дәверен дә күргән әле ул. Гәрчә, «Күчешләр чорында яшәргә язсын!» дигән мәгълүм гыйбарә аның язмышына да туры килә кебек.

Рәссам Әхмәт Китаев 1925 елда Мордовиянең Татар Юнки авылында туган. Дәү әтисе – бик укымышлы мулла... Себергә сөрелгән гаиләдә үсүче баланың башына нәкъ менә Сталинга хат язу уе тууын гаиләдәгеләр белгәнме икән, анысы инде мәгълүм түгел. Әмма бу хатка җавап йөзеннән килеп җиткән хәрби киемле адәм аларга шуны хәбәр иткән: 10 яшьлек баланың гозере үтәләчәк, ул илнең башка яшь рәссамнары белән бергә махсус интернатта белем алачак. Әхмәт бит инде яшь рәссамнарның Бөтенсоюз бәйгесендә җиңеп чыккан сәләтле укучы да! Шулай итеп, бик озакка сузылачак Бөек Ватан сугышы башланасын халык әле күзаллап та карамаган бер мәлдә, ул башкаланың урта мәктәбендә укый башлаган. Мәскәүнең В. И. Суриков исемендәге дәүләт сынлы сәнгать институтын уңышлы тәмамлап, рәссам булып киткән.

Аның иҗаты – үз чорының сәнгать жанрлары белән тәңгәл. Совет кешеләренең уй-хыялларын ачып бирә торган әлеге тематик картиналардан яктылык, җиңелчә юмор бөркелә! Талантлы рәссамның бөртекләп җыелган әсәрләре исемлеге бик тулы күләмле түгел түгелен, аларның нинди дәүләт музейларында һәм шәхси тупланмаларда саклануы хакында мәгълүматлар да аз. Шулай да иҗаты аша Әхмәт Ибадулла улының тагын бер җитди жанрны үз итеп, күпсанлы портретлар язганын да күрәбез. Ул портретларда зыялы галимнәр, сәясәтчеләр, хезмәт алдынгылары сурәтләнгән. Туры сүзле, кыю, принципиаль, бюрократик киртәләргә, кыенлыкларга бирешмәгән зат буларак, аның холкына сокланучылар күп булган. «Останың иң зур юанычы – татар милләтеннән булган дус-ишләре белән аралашу иде», – дип искә ала аны якыннан белгән Мәскәү зыялылары.


Үз милләте белән чиксез горурланып яшәгән рәссам 1974 елда иҗат иткән иң уңышлы картинасы «Әби белән онык»ның артына «Мәйсәрә исемле» дигән язуны да өстәргә булган. Ә сурәт янындагы гарәп хәрефле язулар өчен тутыкмас металл төсен – алтын төсне сайлап алган. Әлеге картинасы белән ул дәү әниләргә һәйкәл салган! Һәм ул рәссамның иҗат җәүһәре буларак кабул ителә. Композитор һәм, гомумән, матур хатын-кыз Сара Садыйкова портреты нәфис эшләнеше белән шулай ук үзенә җәлеп итә.


«Җиңү белән кайту» әсәрендә исә Ватанны саклап калган каһарманнарның җыелма образы илебез тарихы өчен һәрчак актуаль. Үз гомерен дә җиңүче буларак узган Әхмәт Китаев 1945 елның шомырт чәчәкле язын әнә шундый композиция аша ачкан.

Күренекле рәссам үз чоры рухын оста сурәтләп, югары дәрәҗәдәге сынлы сәнгать әсәрләре иҗат итеп калдырган. Ул – хыялларын тормышка ашыра алган бәхетле рәссам.

Зилә НИГЪМӘТУЛЛИНА









«Автопортрет» фрагменты
«МГУ паркына керү юлындагы сиреньнәр»
«Сара Садыйкова портреты»
«Җиңү яулап кайту»
«Яшьлек мәхәббәтем» («Кәләшем»)
«Әби белән онык» (тәмамланмаган эш)

ӘХМӘТ КИТАЕВ

татмедиа



Язып һәм от!

Телевизор, көнкүреш техникасы, башка күп кенә бүләкләр

Бүләкләр 2019 елның 16 августында уйнатылачак

1 ЯЗЫЛ — 30.06.2019 кадәр «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыятенең кимендә өч басмасына языл (акциядә катнаша торган басмалар белән tatmedia.ru сайтында таныша аласың)

2 ҖИБӘР — язылу квитанцияләренең күчермәсен «Акция» билгесе белән түбәндәге адреска җибәр (телефон номерыңны күрсәтергә онытма!) Адрес: 420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2 яки podpiska@tatmedia.ru

3 ОТ — телевизор, мультиварка, иттарткыч, блендер, йон юрган һәм башка призлар от

Реклама 16+

Акция турында тулырак – tatmedia.ru сайтында. Акцияне үткәрү вакыты: 22.04.2019 – 20.09.2019
Заявкалар 2019 елның 20 июленә кадәр кабул ителә. Оештыручы – «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыяте.

